1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2019 ФЕВРАЛЬ № 2

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ИЛГИЗ ЗӘЙНИЕВ
тормыш кагыйдәләре

ИРЛӘРГӘ КИЗӘНМИК
алар хәзер нигә үзгәрә

МӘХӘББӘТ
ул беркайчан да соңармый

Рәмзия ДОЛГОПОЛОВА:

РУХЫ БЕЛӘН КӨЧЛЕ ХАТЫН-КЫЗЛАРГА СОКЛАНАМ

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Җәүдәт ДӘРЗАМАН

СИНЕҢ ӨЧЕН

Синең өчен һәрчак аяз,
Зәңгәр һава,
Синең өчен сәйлән сыман
Карлар ява.
Сәйлән карлар бар хәятне
Били акка –
Табигатьне сафлык күмә
Синең хакка.
Таң кояшы нурлар сибеп
Көлгән чакта,
Күңелемдә җырлар туа
Синең хакта.
Җырлар илтсен сиңа минем
Назларымны
Илтсен сиңа назлар тулы
Язларымны.
Синең өчен ал гөлләрем
Чәчәк ата,
Синең өчен сайрап туймый
Сандугач та.
Исемең яңгырый бер моң булып
Тирә-якта –
Мин бәхетле бу дөньяда
Син бар чакта.
Елга, тугайлар – синең өчен,
Кырлар, тургайлар – синең өчен,
Җир һәм йолдызлар – синең өчен,
Сөюең калсын минем өчен.

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Тәслимә ханым. 1968 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Анна Арахамия

Җитәкче-баш мөхәррир
Г.И. САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Рамзия Долгополова
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Лариса Маликова

Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды:
08.02.2019 ел
Заказ О-287
Тираж 4709

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



СӨЛӘЙМАН

* * *

Йолдызлы күк,
иләк сыман,
карлар или салмак кына,
Их, үзеңне ак кар итеп хис итәсе!
Карлар булып коеладыр зәңгәр күктән
Ай кызының тәңкә-тәңкә хәситәсе.

Кышның әле көмеш түе – күктә, җирдә,
Ылысларның түбәтәйле, хозур чагы.
Ә йөрәкнең үз фасылы,
Йөрәк сизә
озакламый
Бәллүрләнеп килгән кар өстендә
Умырзая калкачагын.

Фото: Газинур Хафизов



Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА

Февраль

Февраль холкы көйсез кызлар кебек,
Бер көн көлә, бер көн елаca.
Түбәләргә боз сөңгеләр элә,
Кушылып китә буран дуласа.

Ак көртләргә җем-җем нурлар сибә,
Энҗе сипкән сыман учыннан.
Кышның соңгы күз яшьләре тама
Февраль элгән сөңге очыннан.







Безнең тышлыкта

Тормышыңда очраган кешеләргә рәхмәтле була белергә кирәк.

10

Чирмешәннең вице-премьеры
Эльмира Закирова

Заман һәм без



6

Бала табу уен эш түгел...
Чулпан Галиәхмәтова

Җан авазы
Лилия Гәрәева
16



Ирләргә кизәнмик
Чулпан Галиәхмәтова
20

24
Казанга таулар күчерәм дип килдем
Илгиз Зәйниевнең тормыш кагыйдәләрен
Ландыш Әбүдәрова язып алды

ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы



28
Татар феминизмы-2
Ландыш Әбүдәрова

32



Мадам Венера
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш




36
Кышкы күбәләк
Асия Юнысова

Яшәеш

Өмет катыш көтү
Гөлнур Сафиуллина
44

48
Җиз кыңгырау, көмеш моңнар
Роберт Миңнуллин



50
«Хәятем...»
Гөлнур Сафиуллина

Хатын-кыз галәме



58
Чәй эчәргә шекере
Удмурт халкының милли ризыгы

Бетчә — бетмәс чир түгел
Чулпан Галиәхмәтова
60

62
Тиз, җиңел, файдалы



БАЛА ТАБУ УЕН ЭШ ТҮГЕЛ...



Фото: www.pixabay.com

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

«Хатын-кыз тормышындагы иң матур чор – бәби көтү. Мин дә әнә шундый бәхеттә йөздем. Беренче сабыебыз бит! Татлы хыялларга уралып, шул ук вакытта шөбһәләнеп тә көттем мин аны. Әллә шуны тоеп, балам да түземсезләнде: дөньяга иртәрәк килергә уйлады. 34-35 атнада көтмәгәндә төн уртасында суым китте. Әйберләремне җыеп, бала табарга Казанга чыгып китәргә әле вакытым бар иде. Куркуга калдым: тәҗрибәм дә юк, әлеге процессның ничек булачагын да чамаламыйм. Ирем тиз арада район хастаханәсенә «Ашыгыч ярдәм» хезмәтенә шалтыратты. Без яшәгән авыл белән район арасы 30 чакрым тирәсе. Хастаханәдән «Ашыгыч ярдәм» көтеп тормаска, үзебезгә юлга чыгарга куштылар. Безне шәфкать туташы ишек төбенә чыгып ук каршы алды. Кизү торган акушерка карый башлады. Бу вакытта минем кабат соңгы суларым китте. Ләкин акушерка моңа артык игътибар бирмәде кебек. Документларга күз салды да: «Ник монда килдең соң син, юлламаң Казанга бит?» – дип сорады. Вакытыннан алда тулгагым башлануын, беренче тапкыр бала табуым, үзем өчен генә түгел, бала өчен дә куркуым хакында сөйләп торган булам тагын. Акушерка карарыннан кире кайтмады: документларыңны ал да, Казанга бар, янәсе! Әйтерсең, күршедәге терәлеп торган хастаханәгә җибәрәләр. Үз машинабызда ирем белән Казанга юл тотык. Перинаталь үзәккә килеп, ике сәгатьтән соң мин бала таптым. Биш ел буе зарыгып көткән сабыемны Ходай гына саклап калды дип уйлыйм. Төнге кышкы юл бит ул! Әгәр балам дөньяга тагын да тизрәк килергә ашыккан булса... Нишләп беткән булыр идек?! Хәзер баламны куеныма алганда әнә шундый уйлар килә. Интернетта кызлар белән сөйләшкәч, мондый хәлгә юлыгучы бер мин генә түгеллекне аңладым. Без ярый әле вакытында барып җитә алдык, ә барып җитмәгәннәр нишләр?.. Район хастаханәләре бала табасы хатынны әнә шулай җиңел генә урамга чыгарып җибәрергә хаклы микән? Әллә без үз хокукларыбызны белеп бетермибез генәме? Җирлектәге бала табу йортлары эшчәнлеге буенча ачыклык кертергә ярдәм итсәгез иде.»

Бу хат безгә Балтач районы Арбор авылында яшәүче яшь әни Әнисә Һадиевадан килде. Бала табу болай да җиде сират күпере аша үтүгә тиң, диләр. Әлеге анага тулгагы башланганчы ук бик нык борчылырга туры килгән шул. Икенче якның да фикерен белер өчен район хастаханәсенең баш табибы Газинур Дәүлиевкә шалтыраттык. «Ул көнне кизү торган акушерка, табиб дөрес карар кабул итмәгән инде», – дип, үз хаталарын таныды баш табиб. «Әйе, бала табасы хатынны озата барырга тиешләр иде. Әнисә авырын берниндн проблемаларсыз күтәргән. Ана сәламәтлегенә дә, балага да куркыныч янамаган. Кулында юлламасы бар. Ул үз вакыты, үз җае белән Казанга бала табарга барырга тиеш булган. Вакытыннан алда суы китү генә планнарга үзгәрешләр кертү. Район хастаханәсендә КТГ аппараты белән баланың саулыгы бәяләнгән, суы китсә дә, аналык муентыгы ачылмаган булган. Бәлки шуңа да үзен генә Казанга җибәрү куркыныч түгел дигән карарга килгәннәрдер. Бу очракта «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән озату мәҗбүри түгел. Дөрес, әлеге хәл тагын да иртәрәк срокта булса, йә берәр патология табылса, һичшиксез, медицина транспортында алып барырлар иде. Ләкин һәр авырлы хатынны «Ашыгыч ярдәм» машинасында Казанга илтергә кирәк дигән норматив документлар юк. Узган ел, мәсәлән, Балтачта 375 сабый туды. Аларның 65 проценты Казанда бала табу йортларында дөньяга килде. Мин бит аларның һәрберсен дә «Ашыгыч ярдәм» машинасында җибәрә алмыйм. Андый кагыйдә дә, мөмкинлек тә юк безнең. Аларның кулларында юллама булса да, хатын-кызлар консультациясендә һәрвакыт әйтәләр: үзегезне начар хис итә башласагыз, йә суыгыз китсә, Казанга барганчы, район хастаханәсенә кереп чыгыгыз. Анда баланың да, ананың да сәламәтлегенә куркыныч янау-янамау тикшерелә. Соңыннан гына юлга чыгарып җибәрү-җибәрмәү карары кабул ителә. Менә бу очракта гына безнең хезмәткәрләр ялгышкан. Мондый хәлләр кабатланмасын өчен, без профилактик сөйләшүләр үткәрдек», – дип ышандырды баш табиб.

Үз өстенә җаваплылык алып, суы киткән хатынны төн уртасында Казанга ялгызын чыгарып җибәрү өчен тәвәккәллек кирәк. Ярый әле бу очрак бәхетле мизгелләр белән тәмамланган. Киресенчә була калса, ул авыр йөкне күтәреп яшәргә туры килер иде... Аннан соң еламаган балага ими каптырмыйлар дигән гыйбарә дә бар бит әле. Әнисә: «Медицина хезмәткәре озата барырга тиешлеге хакында мин, гомумән, белмәдем. Белмәгәч сорамадым, таләп тә итмәдем», – ди. Күп вакыт без үз хокукларыбызны белмибез икән. Белсәк тә, минем белән начар хәл булмаячак дип ышанып, кул селтибез йә сорарга уңайсызланабыз. Әмма сүз сәламәтлек хакында барганда, моңа бик җитди карарга кирәк. Гомер бер генә бирелә! Үзебезне кайгыртырга өйрәнергә кирәк. Ә моның өчен мәгълүматлы булу мөһим. Авылларда яшәүче башка авырлы ханымнар менә шушындый күңелсез вакыйгаларга тарымасын, хокукларын белсен өчен сәламәтлек саклау министрлыгының акушерлык һәм гинекология буенча штаттан тыш баш белгече, Казанның 7 нче клиник хастаханәсе баш табибының акушерлык һәм гинекология буенча урынбасары Татьяна Шиһабетдиновага мөрәҗәгать иттек. Иң элек Әнисә белән булган хәлләрне сөйләдек.



Татьяна ШИҺАБЕТДИНОВА: *«Әгәр дә хатын-кызның кулында перинаталь үзәккә юлламасы булса, сәламәтлегенә куркыныч янаса, аны алдан ук хастаханәгә салалар».*

– Бала табарга әле иртә булган. Хатта күренгәнчә, барлык нюанслар сакланган. Аны караганнар. Ул вакытта аңа да, балага да куркыныч янамаган. Монда медицина хезмәткәренең озата бармавы гына сорау тудыра. Акушерка вакыт булуга ышанган, күрәсең. Әлеге очрак буенча министрлыкта да, район хастаханәсендә дә тикшерүләр булачак. Әнисә 12 декабрьдә перинаталь үзәктә бәбиләгән, 17 сендә инде аны чыгарганнар. Димәк, бала тапкан хатынның хәле әйбәт булган дигән сүз. Дөрес, сабый алдан тугач, аны балалар клиник хастаханәсенә җибәргәннәр. Бу да норматив буенча.

Татьяна Николаевна, моннан 10–20 ел элек районда яшәүче хатын-кызлар үзләрендә генә бала таба иде. Казанга килеп бәбиләү бик сирәк күренеш булды. Хәзер исә бу гадәти хәлгә әйләнде. Бүгенге көндә республикада перинаталь хезмәтнең ничек оештырылуын аңлатсагыз иде.

– Республикада йөкле хатыннарга медицина ярдәме күрсәтер өчен өч дәрәҗәле система булдырылды. Беренче төркемгә акушерлык патологиясе куркынычы бик түбән булганнар, ягъни район үзәк хастаханәләрендәге 22 бала табу йорты керә. Һәрберсенең кураторы бар. Бу кураторлар акушерлык патологиясенең икенче дәрәҗәдәге бала табу йортлары: Казан шәһәренең сәламәтлек саклау учреждениеләре һәм муниципальара үзәкләр (Чал-

лыда, Түбән Камада, Әлмәттә, Бөгелмәдә, Лениногорскида, Чистайда, Яшел Үзәндә һәм Казанда). Өченче төркемдә – республикада бердәнбер перинаталь үзәк (тагын ике бала табу йорты өченче дәрәҗәгә күчерелергә мөмкин). Сәламәтлеге өчен куркыныч янаган барлык хатын-кызларны алдан ук шунда җибәрәләр. Анда реанимацион-консультатив үзәк эшли. Санавиация, җиһазландырылган медицина транспорты бар. Ул тәүлек дәвамында бөтен республикага хезмәт күрсәтә. Бала табу йортларында гадәттән тыш хәл чыга калса, кизү торучы табибка шалтыратып, санитар транспорт чакыртырга мөмкин. Әгәр бала табучы хатын медицина күрсәтүе буенча икенче дәрәҗәдәге учреждениегә җибәрелә икән, ул вакытта да санитар машинада медицина хезмәткәре озата барырга тиеш. Монысы – гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда гына.

Аңлавымча, район бала табу йортларында сәламәт хатыннар гына бәбили ала. Әмма моның өчен бер кресло белән бер акушерка гына җитә дигән сүз түгел. Тормыш булгач, көтелмәгән хәлләр килеп чыга. Ул учреждениеләрнең торышы нинди? Җиһазлар, квалификацияле белгечләр җитәме анда?

– Әйе, нәкъ шулай. Беренче төркемгә кергән бала табу йортларында ана һәм бала сәламәтлегенә куркыныч янамаганда гына табигый юл белән бәбилиләр. Медицина ярдәме күрсәтү системасындагы беренче төркем, нигездә, йөкле хатыннарны башка дәрәҗәдәге бала табу йортларына җибәрү өчен оештырылган. Хатын-кызлар консультацияләрендә булачак ананың сәламәтлеген күзәтеп, тикшереп торалар. Хроник, экстрагениталь авырулар булган очракта аерым күзәтү астына алалар. Сәламәтлеккә кагылышлы баллар системасы бар. Ахырда, шулардан чыгып, билгеле карарга киләләр: йә перинаталь үзәккә, йә урта дәрәҗәдәге бала табу йортларына җибәрергә, сәламәт хатыннар исә бәбиләргә үзләрендә кала. Әлбәттә, муниципальара үзәкләрдә җиһазландыру яхшырак. Район бала табу йортларында да медицина ярдәме норматив документларда каралган кагыйдәләр буенча башкарыла. Бүген штат тулы булуга да карамастан, табиблар җитәрлек дип кистереп әйтә алмыйм. Мәсәлән, районнарның берсендә җомга көнне белгеч бар иде, кызганыч, яллар арасында көтмәгәндә ул вафат булды. Дүшәмбегә инде район акушер-гинекологсыз калды. Хәзер без министрлыкта шәһәрдән бу районга табиб җибәрү буенча эш алып барабыз. Үзегез беләсез, безнең өлкәдә һәр минут кадерле. Район бала табу йортларында килеп чыккан көтелмәгән очракларны министрлык шунда ук игътибар үзәгенә алып, тиз арада хәл итәргә тырыша.

Татьяна Николаевна, бик күп районнарда бала табу йортлары ябылды...

– Бу күренеш республикада 2016 ел ахырыннан башлап күзәтелә. Чөнки аларда ике атнага бер генә бала туа иде. Бу – беренчедән. Икенчедән, көмәнле яки бала таппкан хатыннарга, яңа туган сабыйларга вакытында квалификацияле медицина ярдәме күрсәтү максатыннан шулай оештырылды бу. Чөнки аларның 65 процентында нинди дә булса патология табыла бүген. Әгәр хатын-кыз икенче йә өченче дәрәҗәдәге учреждениеләрдә бәбили икән, бар да имин төгәлләнү ихтималы 95 процентка җитә. Унбер районда бала табу йортлары ябылды. Ләкин ачыклык кертәсе килә: җирлекләрдә хатын-кыз консультацияләре, гинекология бүлекләре эшли, гадәттән тыш хәл килеп туган очракта бала табу заллары да бар. Анда ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен барлык шартлар да тудырылган. Шул исәптән, тиз арада баланы ярып алу өчен дә мөмкинлекләр бар. Димәк, хатын-кызлар бервакытта да медицина ярдәменнән башка калмаячак.

Соңгы елларда район бала табу йортларында бала тудырганда ана үлеме белән бәйле очраклар теркәлдеме? Тенденция нинди?

– Тенденция артуга яки кимүгә таба дип әйтеп булмый, ул тотрыклы. Узган ел республикада, кызганыч, биш хатын-кызның гомере өзелде. Араларында авырга узып та, исәпкә басмаганы да бар иде. Тулгак башлангач кына ул табибка мөрәҗәгать иткән, тик аңа инде берничек тә ярдәм итә алмаганнар.

Хәзер перинаталь үзәктә авырлы хатыннарны мониторлау буенча эш алып барылачак. Якын районнар Казан хастаханәләренә беркетелә.

Сәламәт хатын-кызлар үз теләкләре белән перинаталь үзәккә бара аламы?

– Һәр кешенең сайлау хокукы бар. Казанга килә икән, аны кабул итәчәкләр, әлбәттә. Тик медицина күрсәткече булмаса, район консультацияләре юлламаны уңга-сулга таратмый. Перинаталь үзәккә иң элек сәламәтлегенә куркыныч янаган хатын-кызларны алалар.

Авырлы хатын үзенә тиешенчә игътибар итмиләр яки хокукым бозыла дип уйласа, кайда мөрәҗәгать итә ала?

– Республикада кризис кичергән йөкле хатыннар өчен махсус алты үзәк эшли. Һәрберсендә юрист, акушерка бүлмәсе бар. Гадәттә, барлык килеп чыккан сораулар хастаханәләрдә үк хәл ителә безнең. Иң мөһиме – үз сәламәтлегеңә җаваплы карарга кирәк. Даими рәвештә хатын-кыз консультацияләренә йөрү зарур. Соңгы срокларда атна саен табибка күренеп торырга, тиешле анализларны бирергә кирәк. Кабул итү вакытларында авырлы хатын-кызларга бала табу хакында да, сәламәтлеге турында да бөтен мәгълүмат аңлатылырга тиеш. Моннан кала, махсус лекцияләр оештырыла. Табиблар норматив документта каралган алгоритм буенча эшли. Сау-сәламәт сабыен кочаклап, бәхетле елмайган әниләрне өйләренә озатып каласыбыз килә безнең.

ГЕОДЕЗИСТ КЫЗ



Геодезия җирлекне өйрәнә торган фән ул. Территорияне үлчәп, рельефларны билгеләп, координаталарны исәпләп чыгарып, карта төзүләр аңа карый. Геологик эзләнүләрдә, төзелешләрдә кулланыла. Хәзер кечкенә йортлар салганда да иң соңгы сүзне геодезистлар әйтә, алар карарыннан башка нигез салынмый. Күпләр геодезиягә бәйле эшләрне хатын-кызлар һөнәре түгел дип саный. Чынлап та, акыл эшчәнлегеннән тыш, ул физик әзерлек тә таләп итә торган хезмәт. Яңгыр-карлар яуганда да, чыдамаслык челләдә дә, зәмһәрир суыкларда, авыр җиһазлар күтәреп, кырда йөрү нәфис затлар өчен түгел кебек. Әлеге стереотипны җимергән бик күп хатын-кызлар бар. Шуларның берсе Зәлия БӘДРТДИНОВА. Ул WorldSkills эшче һөнәрләр буенча бөтенроссия чемпионатында катнаша.



«Тугызынчы сыйныфтан киткәнемә һич үкенмим», – ди Лениногорск шәһәрендәге нефть техникумының 3 нче курсында укучы Зәлия, тыйнак кына елмаеп. Әти-әнисен, туган авылы Керкәлене ташлап китәсе килми аның. Белем алуны үз районында дәвам итәргә уйлый. Табиб буласы килсә дә, апасы артыннан китәргә карар кыла. Нефть техникумының геология һәм нефть, газ чыгу урыннарын күзәтү белгечлегенә укырга керә. Төркемдә егетләр күбрәк, әлбәттә. Ләкин Зәлия бу һөнәрдә ир-атлар гына эшләргә тиеш дип санамый. «Кызлар тырышрак», – ди ул. Уку да җиңел бирелә аңа.

Worldskills хәрәкәтенә кушылуына да апасы Айсылу сәбәпче була. Аның геодезист компетенциясе буенча төбәк чемпионатларында катнашуын күреп, бик кызыга Зәлия. Үзен дә сынап карарга уйлый. Моннан өч ел элек ярышларда катнаша башлый.

– Беренче тапкыр барганда бик курыккан идем. Ул вакытта биремнәр җиңелрәк тә булган икән әле, – ди ул.



Геодезия өлкәсе – техник белгечлек, шуңа күрә бик күптөрле математик, физик дисциплиналарны, география, геологияне колачлый. Интеллектуаль уйлау сәләте дә булырга тиеш дип аңлата Зәлия. Шуңа күрә дә бик тырышып белемен арттыра кыз.

Йокысыз төннәр, әзерлекләр артта хәзер. Төбәк чемпионатын узып, бөтенроссия турына уза. Инде май аенда Казанда үтәчәк VII WorldSkills Бөтенроссия чемпионатының финалында катнашырга әзерләнә. Аңа кадәр әле төркемдәшләре белән Якутиягә барып, кабат үзләрен сынап кайтачаклар. Әлеге хәрәкәттә катнашып, һөнәре буенча камилләшәсе, осталыгын арттырасы килә Зәлиянең.



Туплаган тәҗрибә эш табарга да булышачак дип уйлый Зәлия. Киләчәктә үзен эре компаниянең баш белгече итеп күрәсе килә. Дөрес, аңа кадәр әле күп укырга, югары белем алырга кирәк. WorldSkillsta катнашу исә моңа зур бер адым булачак. Чемпионатка әзерләүчеләр арасында апасы Айсылу да бар. Ул инде хәзер үзе укытучы. Ә әзерлек техникумда парта арасында утыру гына түгел инде. Көннәр буе кырда, авыр приборлар күтәреп йөри (бер тахеометр гына да 5 килограмм чамасы!). «Иләшкәч, аның бер кыенлыгы да юк», – ди.
Бу һөнәрнең өстенлекле яклары да бар: көннәр буе саф һавада йөрисең, табигать кочагында буласың. «Сәгатьләр буе офиста бөкрәеп утыру түгел инде!» – ди Зәлия.

Чемпионатта катнашу өчен белем генә түгел, тәвәккәллек, тиз арада карар кабул итә белү сыйфатлары да кирәк дип саный. Яшьтәшләренә тырышып укырга, ә иң мөһиме – күңелгә хуш килгән, җәмгыятькә файдалы булган һөнәр сайларга киңәш итә.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

PRESSA

ЧИРМЕШӘННЕҢ ВИЦЕ-ПРЕМЬЕРЫ

Тагын килдек Чирмешәнгә. Тагын сокландык. Узган елгы сәфәребез дә әле кичә генә кебек иде. Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Рәмзия ДОЛГОПОЛОВА район үзәгендәге парк-скверлар, яңа төзелгән Боз сарае, Яшьләр үзәге, спорт мәктәбе, Картлар йорты, тагын әллә нинди матур биналар белән таныштырып йөргән иде. «Күрәнсу йортлар – ятим балаларныкы, яшел түбәлеләр – ипотеканыкы, боларында ветераннар яшәячәк... Тиздән яңа мәчет ачылачак. Искиткеч булачак!..» – дип, бар хыялларын да кушып сөйләгән иде. Күр, тирә-якны тагын да ямьләп, балкып утыралар хәзер! Чирмешәнне генә түгел, Рәмзия Шакир кызының үзен дә яңа яклары белән ачтык... Эшлекле. Тынгысыз. Һәркемгә булышырга әзер... Болары – без күргән кичәге Рәмзия иде. Ә бу юлы без аны ихлас, олы йөрәкле, нечкә күңелле, күп сынаулар узган ханым буларак кабул иттек, күңел кылларына кагылып уздык, хатын-кыз матурлыгын, бай эчке дөньясын күрә алдык.

Эльмира ЗАКИРОВА



«Рәмзия Шакировна, сез ни әйтерсез?», «Рәмзия Шакировна, бәлки, болай эшләрбез?», «Рәмзия Шакировнаны күрәсе иде...» Бу исем көнгә ничәмә-ничә кабатланып, кайсы гына килешләрдә төрләнми икән... Сораулар, мөрәҗәгатьләр, киңәш-табышлар... Район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары булгач, нинди генә өлкәләрне колачларга туры килми. Мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау, балалар һәм яшьләр дөньясы, спорт, дин, милләтара мөнәсәбәтләр, социаль проблемалар... Санап кына бетерерлек түгел. Рәмзия Шакир кызын Чирмешәннең вице-премьеры дисәң дә ялгыш булмас. Төнлә уятып сорасалар да, һәр өлкәнең проблемаларын биш бармагы кебек белә ул. Нәрсәләрне яхшыртырга, камилләштерергә икәнен дә, хыялында йөрткән матур уйларны ничек, ни рәвешле тормышка ашырырга кирәген дә...

Ә командасындагы кызларны ул кадерле кешеләрем дип йөртә.



Рәмзия командасы

Ә хыяллар күп, төрледән-төрле. Уйлап тапкан проектларыңны тормышка ашырыр өчен үз тирәңә сәләтле кешеләрне туплый белергә тиешсең. Иң беренче чиратта команда булдырырга кирәк дип күңеленә беркетеп куя ул. Төрле эшләрне башкара ала торган кешеләр булырга тиеш командада. Йә яза, йә кызыклы идеяләр уйлап таба, йә башкаларны көйли-җайлый белә, тиз эшли... Кемдер тынычрак, кемдер салкын акылы белән кайнарракларны суытып җибәрергә сәләтле, кемдер таләпчән, йомшак, нечкә күңеллеләр дә юк түгел... Инде телгә «женсовет» дип кенә кереп киткән хатын-кызлар советы иҗтимагый оешмасының эшен җанландыру зарурлыгы тугач та, районның иң булдыклы хатын-кызларын барлый Рәмзия Долгополова. «Безнең Чирмешән» газетасы журналисты, шаян-шук, позитив, тәвәккәл, оештыру сәләтенә ия Гөлсирә Шәрифуллина оешмага менә дигән рәис! Мәдәният бүлеге начальнигы Ольга Владимировна аз сүзле, әмма бер әйтә – берәгәйле әйтә! Пенсия фонды җитәкчесе, гел елмаеп торучы Лилия Сәүбанова кебекләр дә бик кирәк. Ул Рузиләне кара инде: үзәкләштерелгән китапханәләр мөдире Минхәерова үзе матур җырлый, җитез, ни кушсаң шуны ялт итеп эшләп куя... Шагыйрәләре дә бар: Рушания Әхмәдуллина. Авыл хуҗалыгы академиясендә укыганда ук спектакльләрдә уйнап йөргән. Җыр сүзләре булып китәрлек шигырьләр яза... Бу нечкә күңелле ханым картлар йортына барган саен елап-сыкрап кайта. Социаль яклау бүлеге начальнигы да әле ул: нәкъ кирәкле кеше! Зур эш тәҗрибәсенә ия мәгариф бүлеге мөдире Светлана Әхтәмова, аның урынбасары, исkиткеч җаваплы һәм эшчән Флера Рәхимҗанова... Һәрчак креатив фикерле яшьләр бүлеге мөдире Лена Портнова... Кара, Чирмешәндә бөтен начальниклар хатын-кызлар икән бит, дип елмая ул канәгать калып. Үзенә дә таләпләре югары Рәмзиянең. Әйе, аны көчле, тәвәккәл җитәкче дип беләләр. Әмма характерында романтизм да бар, ихласлык та. Нечкә күңелле. Кешелекле. Гади. Кабинеты һәрчак ачык. Аның турында шулай әйтәләр. Карьера баскычларыннан күтәрелүнең бер генә сере бар – алны-ялны белми ат кебек эшләргә кирәк! Төрле юллар белән күтәрелүчеләр очрый, әлбәттә. Ләкин үзләрен аямыйча эшли белүчеләр дә кирәк шул. Менә шулай чынлап эшли белгәне өчен күтәрелгән ул.

Үзе өчен билгеләнгән алтын кагыйдәләре дә бар. Кергән кешегә хөрмәт белән карарга! Үзеңне дөньяның кендеге кебек тотмаска! Һавалы, тәкәббер булмаска! Җитәкче икәнеңне онытмаска! Иң элек халык мәнфәгатьләрен кайгыртырга! Кирәк чакта кайберәүләрне урынга утыртырга! Гомере буе көчле характерлы, зәвыклы, эрудицияле, тормышта нәрсәгә дә булса ирешә ала торган хатын-кызларга соклана ул шулай. Җыенысы бик җаваплы бит боларның да. Яңалыктан куркып тормыйлар. Бер-берсен тулыландыралар. Район хатын-кызларына кагылышлы чараларны да алар үзләрендәге бар җылылыкны, игътибарны, кадер-хөрмәтне кушып үткәрә белә. Район хакимияте башлыгы белән очраштырыр өчен 8 Мартта, Әниләр көнендә авыллардагы иң лаек әниләрне, апаларны җыялар: һәр очрашуда 100 әр кеше була. Төрледән-төрле хатын-кызларны чакырырга тырышалар. Бүләкләр биреп, чәй табыны әзерләп, күңелләрен күрәләр, игътибар һәм хөрмәт күрсәтәләр. Исәпләп караганы бар Рәмзиянең: меңләгән хатын-кыз район җитәкчесендә кунакта булды инде соңгы елларда! Бар җирдә дә юк мондый матур гадәт. Район башлыгы акча җәлләп тормый. «Алар – үзебезнекеләр, без дә зурламасак, кем зурлар», – ди район башлыгы Фердинант Мидхәт улы Дәүләтшин.

Монысы – йөз-мең мәшәкатьләрнең берсе, бер бөртеге генә әле. Ә уй-хыяллар, башкарасы эшләр – бихисап!

Фото: Анна Арахамия

Чирмешән кызларын матур итеп күрәсе, башкаларга да матур итеп күрсәтәсе килә Рәмзиянең.

Матур киенеп йөрегез!

Авыл тормышында яшәп, маллар асрап, бакчада казынып, кайчак үзләренең матур икәннәрен дә онытып җибәрә бу кызлар. Шуңа да «Сөембикә» журналы редакциясенең «Матурлык подиумы» оештыру турындагы тәкъдимен хуплап ала нечкә тоемлы җитәкче. Чирмешән кызлары болай да матур. Үзләренә килешкән киемнәрне сайлый белергә генә кирәк. Күз алдында чып-чын модельләргә әйләнәчәкләр. Долгополованың үзен менә районда иң матур, килешле киенеп йөрүче хатын-кыз дип исәплиләр икән. Күлмәкләрнең зәңгәре дә, чия төсендәгесе дә, фирүзә, әфлисун төсендәгеләре дә – барысы да килешә аңа. Сәламәт булыр өчен ул... иртән яланаяк карда йөгереп керә, эссе мунчадан чыгып кар көртенә чума. Ә аруларын бетерер өчен чаңгы юлларыннан уза.

– Зәвык, матурлыкка соклану кебек сыйфатлар әтиәнидән киләдер, – ди Рәмзия ханым, балачагын сагынып. – Безнең өй авылда иң матур йортларның берсе иде. Әти – балта остасы. Әни чисталыгы, пөхтәлеге белән өебезне ямьгә күмүче. Ул мендәр япмалары, ул кырт итеп җыелган урын-җир... Ап-ак мич бөтен җирне яктыртып тора кебек. Мич башына инде ялгыш та бер артык әйбер дә куелмый. Тротуар буйлап керәсең – якякта чәчәкләр! Авылда кайткан кунакларны ашка алдыру гадәте бар бит. Сезнең өегез ямьле, ашларыгыз тәмле була дип, гел безне сайлыйлар иде. Яхшы гаиләләр безнең әти белән әни кебек булырга тиеш дип уйлый идем мин. Әйбәт гаилә моделен аларда күрә идем. Әтигә күптән түгел 85 яшь тулды, әни белән бергә 60 ел гомер кичерделәр. Матур яшәгәнгә ул! Әле дә хәтерлим: әти әнигә бик булыша иде. Ә әни бу хакта бер дә сөйләп йөрми. «Серегезне кешегә сөйләмәгез», – дип әйтә иде ул. Бик зирәк хатын! Дәшми кала белә ул! Сабыр. Чәчрәп чыкмый: башта уйлап бетерә. Сүзнең мәгънәсен ассызыклый. Ашыгып сөйләмәскә куша. Әти гаилә өчен җан атып яши. Бөтен тапканы – балалар, өй өчен булды. Матур киемнәрне безгә Мәскәү, Ташкент, Казан, Самаралардан алып кайтырлар иде. Алтын урталыкны табып тәрбияләделәр. «Кешене гаепләгәнче, иң беренче үзегезне күрегез, үзегездән башлагыз», – дия иде әни. Ямьсез сүзләр әйтешеп, кеше көлдерү булмады безнең гаиләдә. Әни – минем өчен хатын-кыз идеалы. Хатын-кыз матур йөрергә тиеш дигәннәре дә әнидән сеңгән безгә. Чирмешәннән Лашманга мотоциклда кайтабыз шулай. Юлда барыбер тузан дип, чалбар, курткадан гына үзебез. «Ямьсез киенеп кайтмагыз авылга!» – дип, әни бер генә әйтте! «Өйдә сәләмә халат киеп йөрмәгез!» – монысы да әни сүзләре иде. Һәм алар гомерлек сабак булды.

Лашман кызы булу – бренд ул!

Мишәр кызы булсын да, үз дигәнен итмәсенме? Тырыш, максатчан, эшчән, үткен, диләр аның турында. «Мин бит Лашман кызы! – ди Рәмзия горурланып. – Скрипкачылар, җырчылар, балта, тимер осталары, бик күп җитәкчеләр, абруйлы кешеләр авылыннан!» Лашман мәктәбе зыялы укытучылары белән дан казанган икән. Һәр баланың эчке дөньясын, сәләтләрен ачу өчен ниләр генә эшләмиләр. Кемдер бии, берсе рәсем ясый, икенчесе җырлый, ә Мөхәммәтҗанова Рәмзия исемле кыз яза! Шигырьләре, мәкаләләре әле «Яшь ленинчы»да, әле «Татарстан яшьләре»ндә басыла. Мәктәптә дә «бишле»гә генә укый. Отряд, дружина советы председательләре булу да килешеп тора үзенә. Казанда педучилищеда укый башлау белән староста итеп сайлап куялар үзен. Ут уйната торган кыз, кыскасы. Каян шундый булган дип аптырыйсы юк, булган кешеләр баласы бит ул. Әтисе Шакир абый да, әнисе Зөлхиҗә апа да берсеннән-берсе акыллы балалар үстерәләр. Энесе Рәис, сеңелләре Зөлфия белән Фәридә дә апаларыннан калышмый. «Мин үзебезнең урам тәрбиясен дә аерып әйтер идем, – ди Рәмзия. – Ярымутраудагы сыман, аерым бер кабилә кебек яши идек бит без. Язларын Сөлчә елгасында су күтәрелеп, басма-күперләрне алып китә дә, урамыбыз бүленеп кала. Шуңа безне атаунықылар дип йөртәләр. Шундый бердәм, тату үзебез. Гайбәт сөйләү, кеше гаепләүләр гел юк. Бер-беребезгә таяныч, терәк булып үстек. Бик бердәм һәм бәхетле идек...»



■ Район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфасына күтәрелгәнче әле районның мәдәният бүлегендә, хакимиятнең оештыру бүлегендә, яшьләр һәм спорт бүлегендә чарлана тагын...



Укытучы эше – күңеленә иң хуш килгәне. Ике дә уйлап тормый, педучилищега китә. Аннары инде Югары Кәминкә мәктәбенә эшкә җибәрәләр. Юк, Рәмзия барыбер дә иҗат кешесе икән. Хыялы әллә кайларга оча, күңел офыклары дөньяларны айкый. Редакциягә шулай килә ул... Кияүгә чыгу, бала туулар... Яшь гаиләне яңа төзелешләр алгысыту... Фермер да, телевидение дикторы һәм алып баручысы да... Алай гынамы соң! Язмыш аңа бик күп сынаулар әзерләп куйган икән бит. Рәмзия сөйләгәннәр – үзе бер хикәя.

Әй язмыш, язмыш...

– Кама Аланында АЭС төзелә башлаган еллар иде. Без – яшь гаилә, Чирмешәннән шунда киттек, кечерәк кенә фатир да эләкте. Эшкә дип китеп, үземә үзем яңа эш уйлап таптым бит. Ни укытырга, ни балалар бакчасына, ни китапханәгә кеше кирәк түгел. АЭС каршында эшләп килүче мәдәният йортына бардым тәвәккәлләп. Түгәрәк алып бара алам, дим, кирәкми, диләр. Татар театры оештыра алам, дим. Эш юк, дип, чыгарып җибәрмәкчеләр. Алай да берсе, керегез әле, дип, кире борды. Оештырып карагыз соң, диләр. Оештырдык! Ничек кенә әле! Театрлар, концертлар белән күрше авылларга да чыга идек әле. Бер-ике елдан атом электростанциясе төзелешен туктаттылар. Ирем Вячеслав Башкортстанга фермер булып китте, артыннан без дә кузгалдык. Бүздәк районында, үзәктән 40–50 чакрым ераклыкта кырда дүрт гаилә яшәрлек бер урынга килеп урнаштык. Мин мәктәптә балалар укыттым. Ирләр алтышар-җидешәр гектар мәйданда көнбагыш, карабодай, чөгендер үстерә, маллар асрыйбыз. Дүрт ел гомер үтте дә китте шулай. Психологик яктан авыр чакны да әйтми кала алмыйм... Улыбыз Дениска 3 яшь, Динарага 6 ай иде. Майның 12 сендә язгы эшләрне тәгәлләп кайттык. Шул көн миңа авыр сынау әзерләгән булып чыкты. Буралар янында бала-чага белән уйнап йөргән Денисыбыз, бүрәнәләр ишелеп, шулар астында калган. Берничек тә коткарып калып булмады: чигәсенә кан сауган иде... Юк-юк, язмыштан зарланмыйм. Никадәр тормыш тәҗрибәсе бирде ул! Гомерлек дуслар табып кайттык!..

Рәмзия ханым бераз тын торды да тагын бер четерекле темага кереп китте.

– Катнаш гаиләләр турында күп сөйлибез хәзер. Ә ул катнаш никах дигәннәрен үз башымнан, йөрәгем аша уздырган кеше бит мин. Кем уйлаган Вячеслав Долгополов дигән рус егетен очратырмын да кияүгә чыгармын дип... Татар мохитендә тәрбияләнеп үскән гап-гади авыл кызы бит мин. Язмыштыр бу. Милләт дип, байраклар күтәреп чыксаң да, язмыш дигән әйбер бар икән ул... Бүген, бу заманда, «үз милләтегезгә генә чыгыгыз, үз кешегезгә генә өйләнегез» дип, чикләр куеп, кысаларга утыртып кына була микән? Кияүгә чыкмаган күпме кызлар, өйләнмәгән никадәр егетләр бар... Ә бит кеше гаиләле булырга тиеш. Берәү дә ялгыз калмасын. Һәркайсы башлы-күзле булсын, балалар үстерсен. Балаларны исә нык иманлы итеп тәрбияләргә кирәк. Үзеңне, телеңне, асылыңны саклап калыр өчен иманың нык булсын икән ул. Хәзер менә уйлыйм да... Иманым, динем нык булганга, үземне хөрмәт иттертә, үз фикеремне, үз сүземне үткәрә алдым. Алай гынамы, Славага кияүгә чыгып, татарлыгым көчәйде генә. Энә биреп, дөя алу дип саныйм моны. Слава башта ук, үземә дә татарча өйрәнергә кирәк булган, дип гел әйтә иде (үз әнисе үлгәч, әтисе татарга өйләнгән). Кызларым Динара белән Маргарита чеп-чи татар кызлары булып үсте. Татар егетләренә кияүгә чыктылар. Динара белән Дамирның – Әмирханы, Айселе үсә, Рита-Маргарита белән Рамил Сөембикә дип исем кушты кызларына.

Слава белән 30 ел бергә бик матур яшәдек. Сизәм: берзаман ул моңсуланып калды, үз эченә бикләнде. Һәм көннәрдән бер көнне ул үз милләте кешесенә тартылуын әйтте. Бездән китүе иде бу аның. Башта бик авыр булды, әлбәттә. Хәзер инде әрнү китте. Мин ачу сакламыйм, үткәреп җибәрә беләм. Үз милләтенә, асылына зарыккан бит ул, дип, Славаны акларлык сүзләр эзләдем. Шушындый чишелеш килеп чыгуга күңелемнән риза да була башладым. Кеше бер генә килә бит дөньяга. Үзе теләгәнчә яшәргә хакы бар аның да. Вячеслав – яхшы кеше. Җайлы, тыныч, төпле. Аерылышкач та дуслар булып кала алдык. Хәзер кода-кодагыйлар белән рәхәтләнеп аралашабыз, оныкларга сөенеп бетә алмыйбыз: ул да, мин дә. Тагын бер әйберне әйтим әле: кайнанам Хәйрия белән әниле-кызлы булып яшәдек, килендәшләрем якын сердәшләрем булды, бүген дә нәкъ элеккечә аралашабыз. Тормышында очраган кешеләргә рәхмәтле була белергә кирәк. Кыен чакларда мин шул кадерле кешеләремә таянам.

* * *

Рәмзия Шакир кызының көне... планеркалардан башлана. Менә хәзер киңәшмәгә кереп китәр. Һәрвакыттагыча, яңа мәшәкатьләргә, яңа бурычларга күмелеп чыгар. Бөтен барлыгы белән кабат ыгы-зыгылы тынгысыз хәяткә чумар. Бер генә мизгелгә ул тәрәзәдән кышкы урамга, ап-ак дөньяга, карга күмелеп утырган агачларга, ак юлларга карап тынып калды. Шул садә матурлык никадәр илаһи көчкә ия: тынычландыра, очсыз-кырыйсыз уйларын бер тәртипкә тезә, бар кыенлыкларны җиңәрлек куәт бирә. Димәк, бар да яхшы булачак!



Фото: Гөлсирә Шәрифуллина

РӘХМӘТ ИЛШАТКА!



Илшат – туган авылы Яшәүченең кадерле бер баласыдыр. Аны һәрчак аерым бер ярату белән телгә алалар. 36 йортлы авылда хәбәр тиз тарала: кайтса-китсә дә, кемгәдер булышса да, җырларын ишетсәләр дә, машинасын күреп калсалар да, сүз гел Илшат тирәсендә бөтерелә.

Эльмира
ЗАКИРОВА

– Бигрәкләр игелекле инде!

– Харисныкылар бит: Юныс белән Фатыйма балалары булсыннар да...

– Быел да Авыл бәйрәмен зурлап үткәрергә җыена ди Илшат...

– Үзе дә булган шул! Кемнәргә генә булышмый Илшат! Кемнәр генә кайтмый да, кемнәр генә кунак булмый Яшәүче Сабантуйларында!

Ә аны ай күрә, кояш ала. Әле генә район үзәге Чирмешәндә иде, кай арада Кармышка сугылган да, Яшәүчегә – әнисе янына кайтып кереп, инде Нурлатына китеп барган.

Авылы, авылдашлары өчен җан атып йөри торган олы йөрәкле, игелекле бу затны аңлар өчен аның инстаграм битендәге тормыш шигаренә генә күз салу да җитәдер: «Яңа туган һәр иртәне изгелек кылудан башлыйк!»

Авылдашлары өчен ул – якын кеше: туган, чордаш, сабакташ. Эшендә – тәҗрибә туплаган җитәкче, Нурлатның «Южная» агрофирмасына караган Киекле авылында сөт комплексын җитәкли. (Эш ярата, кешеләр ярата торган егетне кайда да колач җәеп каршы алалар. Казан ветеринария академиясен тәмамлауга, Зәй районы Чыбыклы авылына «Родина» хуҗалыгының баш зоотехнигы итеп эшкә җибәрәләр. Сөт комбинатында – мастер, сөт комплексында – директор, Әлмәт районы Токарликов исемендәге совхозда директор урынбасары... Кайларда кемнәр булырга гына туры килми.) Күпләр аны популяр җырлар авторы Илшат Харисов дип белә. (80 ләп җыры бар! Альфред Якшимбетов, Илгиз Закиров, Лилия Муллагалиева, Әдис Маликовлар белән иҗади дуслыкта ул). Спорт сөючеләр, көрәш яратучылар өчен дә Илшат Юныс улы үз кеше: көрәшче, Чаллыда «Челны-Бройлер» оешмасында эшләгән елларында «Татарча көрәш» милли спорт федерациясен җитәкләгән спортчы бит ул! Яшәүче халкы өчен генә түгел, тирә-як авылларга, күрше-тирә районнарга үрнәк булырлык Сабантуйлар оештыручы, бүләкләр әзерләүче, үзе шул бәйрәмдә бүләкләр тапшырып, кунакларның күңелен күрүче дә әле ул. Йә, кайда бар ул Сабантуйда үзләрен күрсәткән хатын-кызларга чәшке туннарга сертификатлар өләшү?! Туган көннәрен, юбилейларын белгеләп үткән авылдашларына истәлекле бүләкләр тапшыру?! Тату гаилә булып роза туйларына, бәллүр туйларына, көмеш, алтын туйларына килеп җиткән матур парларны ничек онытмак кирәк: балалар

үстереп, чын мәгънәсендә авылны яшәтүчеләр бит алар, зурларга кирәк үзләрен, дип күңеленә беркетә Илшат. Хәер, энеләре Илнур, Ирек, Илһам, Илгизәр, сеңлесе Гөлшат – абыйларының булышчылары, һәр башлангычын хуплап алалар, бүләкләрне бергәләшеп әзерлиләр. Авылның иң өлкән кешесенә дә, яңа туган сабыена да, ераклардан җирсеп-сагынып кайткан авылдашларга да өлеш чыкмый калмый. Мәет юучы әби-бабайлар бар, ләхет алучылар бар... Кешене соңгы юлга хөрмәтләп озату да савап бит, аларга да рәхмәтләрне җиткерә белергә кирәк. «Иң зур бавырсак пешерүче», «Иң моңлы җырчы», «Иң оста баянчы»... Тагын әллә никадәр «Иң-иңнәр» мәйдан түренә чыгып бүләк ала. Сабантуй күчтәнәчләренең кайберсе турында кызык итеп тә сөйлиләр. «Каян башларына килгән диген: ярышта катнашкан атлар да нәүмиз калмады – берәр капчык солы бирделәр, беренче килгәннәренә ике төргәк печән дә эләкте!» – дип көләләр. Менә шулай кыштан ук җәйгә әзерләнә Илшат. Ә ул оештырган бәйрәмне бар да ярата! Шул кечкенә генә авыл Сабан туена атаклы җырчылар – Резеда Шәрәфиева, Лилия Муллагалиева, Алсу Хәбибуллина, Алсугөл, Закир Шаһбан, Зөһрә Шәрифуллиналар кайтсын әле! Әниләре Фатыйма апа йөгереп кенә йөри. Табыны әзер, кунаклар да өзелеп тормый: берсе килә, берсе китә... Их, янда әтиләре дә булса!.. Бигрәк яшьли китеп барды шул! Әниләре берьялгызы алты баланы тырыш, тәүфыйклы итеп үстерде, алтысы да югары белем алды, тормышта үз урыннарын тапты.

Илшат үзе дә: «Мин бер эштән дә куркып тормыйм, кечкенәдән шулай тәрбияләнгән, – ди. – Ходай Тәгалә нәрсә биргән, шуннан канәгать. Көтү дә көттем, ферма мөдире дә булып эшләдем... Аннары – Сәүдә техникумы, аннары – армия, Томск өлкәсендә чик сакчылары гаскәрендә хезмәт итүләр...»

Һәм шундый җитди эшләрдә эшләүче җитди кеше... шигырь, җыр дөньясында яши! Бәлки, туган ягының искиткеч табигате шагыйрь иткәндер аны? Шушма буена сыенган Яшәүче дүрт яктан да биек таулар белән ышыкланган, ә үзе таба кебек тип-тигез урында утыра! Күлләр, әрәмәләр, тау чишмәләре... Илаһи ул күренешләр ерак-еракларга киткәч, гел төшләргә кереп йөдәтә.

Бәлки, матурлыкка соклана белгән әти-әнисеннән, авылдашларыннан күчкәндер ул сәләт? «Җиде класс белемле әти «Социалистик Татарстан» газетасының авыл хәбәрчесе булып, редакциягә хат-хәбәрләр юллый иде», – дип искә ала бит әнә үзе дә.

Бәлки, бик тирәнгә яшеренгән йомшак күңеле вакыт-вакыт үзен шулай сиздереп куядыр? Шулайдыр, мөгаен, шулайдыр.

«Армиядә чакта минем белән бергә хезмәт итүче дус малайга Башкортстанның Бишбүләк районыннан кайгылы хат килде: унбер бала табып үстергән әнисе фаҗигале төстә бу дөньядан китеп барган. Бик тетрәнгән идем ул чакта. Җанда айкалган хисләр кәгазьгә түгелде. «Әнием шомыртлары» дигән шигырь шулай язылды...»

Ә ул шигырьләр ничек җыр булып китә икән? Кем аларны көйгә сала? Кем башкара?

Илшат Харисовның һәр көне игелекле эшләр белән бизәлгән.

Айгөл БАРИЕВА: «Әнием шомыртлары» дигән шигырьне укыдым да, әллә нәрсә булды: бөтен җаннарым актарылды. Авторын күреп сөйләшәсем, аңа рәхмәт әйтәсем килде. Шигырьне тиз арада Марсель Ивановка бирдем. Аны да дулкынландырган – матур итеп көйгә салды. Мин концертларымда җырлап йөри башладым. Бәхетле язмышлы җыр булды ул. Хәзер дә репертуарымда яңгырый. «Мине беренче булып Айгөл җыр дөньясына алып кереп китте», – ди икән Илшат үзе».

Альфред ЯКШИМБЕТОВ: «Туганымдай якын, кадерле кеше ул Илшат! Бергә шактый җырлар иҗат иттек. Шигырьләрен гади генә итеп яза кебек – ә күңелгә шундук барып җитә! Аңлаешлы, халыкчан. Үзе дә җайлы, ихлас, ялганны белми торган эчкерсез кеше инде. Әйткән сүзендә тора белә, булмастайны вәгъдә итми. Аңа ышанырга, таянырга була».

Лилия МУЛЛАГАЛИЕВА: «Илшат сүзләренә җырлар язу рәхәт. Шигырьләре үзләре үк җырлап тора, шундук истә кала. Җырларымны туплап, «Мин» дигән китабымны чыгарган идем. Җыентыктагы җырларның яртысыннан күбрәге Илшат Харисов сүзләренә иҗат ителгән. Исемнәреннән үк аңлашылганча, күп җырлары авылларыбызга багышланган. Яшәүче, Кизләү, Әнәк, Елгабаш, Әмир, Тубылгытау... Күп инде алар! Илшат һәр авылның тарихы, табигате белән кызыксына, елгакүлләре, таулары, чишмәләре турында яза. Кая барсак та, безнең авыл турында да җыр языгыз, дип калалар. Илшатның туган авылындагы Сабантуй, әнисе – кунакчыл, ягымлы Фатыйма апа һаман күз алдында. Матур яклар, матур кешеләр дип сокланып кайттым Яшәүчедән».

Резеда ШӘРӘФИЕВА: «Молодец кеше ул Илшат! Аны күптән беләм. Без Чаллыдан ук таныш. Шигырьләре күңелгә шулкадәр ятып тора! Беләсезме, машинада «Сөлчәбашым»ны шыңшып кайтам гел. Көе дә, сүзләре дә матур. «Сөлчәбашым»ны кайчак «Наратлы Кичү» дип, үз авылым исемен кушып җырлап җибәрәм. Бу көннәрдә аның әниләргә багышланган бер җырын репертуарыма әзерлим, көе Риназ Әхмәтовныкы.

«Тик күзләрең яшьләнмәсен, әни! / Барсы яхшы, Аллага шөкер!» – дип җырлаганда үз әниемне дә күз алдында тотам.

Синең хәер-фатихалар белән башланган ул безнең юл башы, дип, әнисе Фатыйма апага багышлап язган Илшат аны. Җырдагы бөтен җылылык, ярату, изге теләкләр барлык әниләргә дә барып җитсен иде. Рәхмәт Илшатка!»

Әйе, рәхмәт Илшатка! Якты күңеле, игелекле гамәлләре, изге эшләре, матур җырлары өчен рәхмәт!

ҖАН АВАЗЫ

Мондый хәлләр турында ачыктан-ачык сөйләшмиләр. Тирә-юньдәгеләр өчен ул юләрлек, акылсызлык, башкаларның игътибарын үзеңә юнәлтүнең бер чарасы гына булып тоела. Гаиләдә мондый хәл килеп чыкса, аны яшереп калдырырга тырышалар, хурлык дип саныйлар.



Лилия
ГӘРӘЕВА



Ничек кенә яшерергә тырышма, бу проблема бар. Журналист буларак, мәктәпләргә очрашуларга баргач та калкып чыккалый ул, кайчак әти-әниләр үзләре дә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Кем ничек кенә мөрәҗәгать итсә дә, ул һәрвакыт яшерен була. Кызының кан тамырларын кискәнен яки улын элмәктән кисеп төшергәннәрен берәүнең дә фаш итәсе килми, чөнки шушы хәл килеп чыкканга әти-әниләрнең дә гаебе юк түгел. «14 яшьлек улыбызны компьютердан кубарып алып булмый, – ди әнә бер әни. – Мәктәптә волейбол түгәрәгенә йөри иде, ташлады, укыйсы да килми. Аның яшендә инде кызлар белән кызыксыналар, аңа кызлар да кирәкми. «Имтиханнарны ничек бирерсең соң, дисәң, «Аңынчы яшим дип, кем сезгә әйтә әле?» – дип шаккаттыра», – ди ул, борчылып. Командировкага баргач, «Сөембикә» журналыннан булуымны белеп, бер ханым да үзләренең гаилә серен чишкән иде. «Журналда психолог киңәшләре басыла, безнең хәлгә дә ачыклык кертмәсләр микән?» – дип башлады ул сүзен. Аннары сөйләп китте...

– Моннан бер-ике ел элек кызыбызның теленә Канеки исеме килеп керде. Аның аниме һәм манга жанры белән «җенләнүен» яшүсмерлек кызыксынуы дип кенә карадык, җитдигә алмадык. Өстәлендә аниме геройларының сурәте төшерелгән блокнот, значоклар, наклейкалар күренә башлады. Әлеге персонажлар кумирларына әйләнде. Болар ниндирәк герой соң, аларны карап, ул нәрсәгә өйрәнә дип, ныклабрак кызыксына белмәгәнбез шунда. Бер карар да туяр, дигәнбез. Югыйсә Джузаның үз тәненә зыян китереп, авыртудан тәм табуын сөйләгән иде бит. Мондый гамәлләрнең гөнаһ булуын гына әйттем дә бетердем ул чакта.

Бераздан кызыбызның холкында үзгәрешләр тоя башладык. Бер сүз әйтеп булмый, ваннага керә дә бикләнә. Сәгатьләр буе да утырырга мөмкин, ялына-ялвара, ишекне көчкә ачтыра идем. Анда да башыма шикле уйлар килмәде әле,

яшүсмер вакытта була торган көчеш чорына сылтадым. Чираттагы шундый бикләнүдән соң раковина кырыенда сабы сынык бритва таптым. Аптырадым. Әтиләре кырынганда сындыргандыр да алып ташларга оныткандыр, дидем. Ә кызым озын җиңле күлмәк кияргә гадәтләнде.

Тәнендәге яраларны очраклы гына күреп алдым. Йөрәгем «жу-у» итте. «Кызым, кайдан мондый җәрәхәтләр?» – дигәнемә, кабат күз яшьләре, кабат ваннага кереп бикләнү... Ялына торгач, ачты ишекне. «Кызым, аңларга тырышырмын, акыл да өйрәтмәм, ни булганын әйт. Үзеңне болай газапларлык нинди хәсрәтең бар?» – дим. Күңеленең тулган мәле булгандыр, күз яшьләренә буыла-буыла, айлар буе үзенең нинди хисләрдә януын сөйләде.

Тәүге тапкыр гашыйк булу чоры иде шул. Ошатып йөргән егете башка берәүне яратуын әйткән, дуслары алдында кызыма авыр сүзләр кычкырган... Җан әрнүен әнә шулай тән газабы белән басмакчы булган кызым.

Ул көнне аның белән ярты төнгә кадәр кызлар-егетләр арасындагы мөнәсәбәтләр турында сөйләштек. Минем дә булды ул андый җавапсыз мәхәббәтем. Җанымның ничек бәргәләнүен үзем генә беләм. «Кызым, мине ул вакытта читкә тибәрүче кеше – әтиең. Соңыннан үзе артымнан ялынып йөрде», – дигәнем баламның күзләрендә кабат очкыннар кабызды».

Ләкин әни кешенең борчылуы барыбер басылмаган иде әле. Кызының тагын да хәтәррәк адымнар ясавыннан курка иде ул.

Балаларыбызны мондый үкенечле гамәлләрдән саклап калу өчен әти-әниләргә нишләргә соң? Яшүсмерләрнең сәер гамәлләрен ничек аңларга? Соңыннан терсәкләрне тешләр хәлгә төшмәс өчен, ике арадагы күперләрне баштан ук нык итеп корырга, баланың ышанычын яуларга куша психологлар. Бүген – җәмгыятьтә кыйммәтләр үзгәргән чорда – ул күперләр аеруча нык кирәк.

«Барысыннан да туйдым!» – диюе, баланың ярдәмгә чакыруы.

Бу әнинең җанын телгәләгән хәлләр турында соңыннан психолог белән дә, табиб-психотерапевт белән дә сөйләштем. Аларны игътибар белән тыңлагач, тоннельнең теге башында бераз яктылык күренгәндәй булды.



Саҗидә РУСИНОВА, биология фәннәре кандидаты, педагог-психолог

– Әлеге күренешләр еш очрый хәзер. Бүген бу мәсьәлә аеруча актуаль, чөнки яшүсмерләрне үзләренә кул салырга яки төрле җәрәхәтләр ясарга өндәп, котыртып торучы интернет уеннар, квестлар барлыкка килде. Ул куркыныч төс ала бара. Төрле чаралар белән яшьләрне мазохизмга этәрәләр. Мазохизм механизмы кешенең генетикасында ук бар, һәм бу күренеш күп кенә халыкларның милли культураларына да хас.

Яшүсмерләрне әлеге процесска җәлеп итү өчен тулы бер чылбыр тезелә. Аны оештыручылар шушы чорда балаларның барысын да үзләре тоеп карыйсы килү теләген, көчле тойгыларга тартылуын белеп эш итә. Башта – кызыксындыралар (ә кызыксыну кешенең табигый рефлексы), аннары мавыктыралар, яшүсмер ярдәмендә күбрәк кешене җәлеп итәләр, балада көчле тойгылар тудыралар, аннары инде баш мие кабыгының импульслары бастырыла, баланың үз-үзенә контроле кими, рухы сына һәм, ахыр чиктә, аны чарасызлыкка – фаҗигале финалга китереп териләр.

Бу йогынтыга күбесенчә рухи тетрәнү кичергән, гаиләсендә яклау, аңлау тапмаган яшүсмерләр эләгә. Гомумән, 13–16 яшендә балаларга экстримлык хас. Аның монысы да генетик программа.

Үз-үзләрен тотышлары буенча яшүсмерләрне өч төркемгә бүләргә мөмкин.

Экстремаллар. Аларның гормональ фоны «батырлыклар» кылырга өнди. Мондый балалар бөтен нәрсәне үзләре аша уздырып карарга тели. Кызганыч, җинаятьчеләр дә шушы төркемнән үсеп чыга.

Интеллектуаллар. Аларның билгеле бер омтылышлары, кызыксынулары, белемнәре бар. Болар яхшы нигезгә корылган тулы гаиләдә үсә, һәрнәрсәне үзләре аша уздырмаска кирәген аңлыйлар.

Физик сәламәтлекләре зәгыйфь балалар. Алар авыртуның нәрсә икәнен болай да белә, физик сызланудан гына түгел, җан сызлавыннан да куркалар.

Үсә-үсә, берникадәр тәҗрибә туплап, тиешле белем алганнан соң, яшьләр үз-үзләренә яңадан бәя бирә, нәрсә өчендер яки кем өчендер корбан буласы килү теләге бетә.

Балаларны мондый күңелсезлекләрдән аралар өчен гаилә әгъзалары арасында иң элек дөрес мөгамәлә, әти-әнинең бала алдында абруе һәм балага карата хөрмәт

Селфхарм (үз тәнеңә җәрәхәт ясау) күбрәк хисчән кешеләргә хас.

булу кирәк. Башкаларга, җәмгыятькә, хөкүмәткә карата хөрмәт, ихтирам тәрбияләү дә мөһим. Кечкенәдән файдалы шөгыльләргә җәлеп итү, яңа мөмкинлекләрне күрә белергә өйрәтү, уңышка ирешү юлларын ачыклау, авырлыкларны, һәртөрле проблемаларны чишү юлларын күрсәтү – болар барысы да яхшы профилактика чаралары.



Юрий КАЛМЫКОВ, Республика психиатрия хастаханәсенең «Сердәш 129» медицина-психология хезмәте бүлеге мөдире, табиб-психотерапевт

– Яшүсмерләрнең үзләренә зыян салуы һәрчакта да бу дөньядан китү максатында гына эшләнми. Ният төрлечә булырга мөмкин.

Беренчесе: дөрестән дә, яшүсмер үзенең үлемен тели. Ул моңа алдан ук әзерләнә, дөнья белән хушлашуны планлаштыра. Мәгълүматлар буенча, узган ел Татарстанда шундый алты очрак фаҗига белән тәмамланган, 70 очракта баланы коткарып кала алганнар.

Икенче төре: алдан әзерләнеп тормыйча, үләргә ниятләмәстән, хисләргә бирелеп кенә үз-үзеңә кул салу. Яшүсмерләргә аеруча шушы төре хас. Кайчак уеннан уймак чыгып, мондый гамәлләрнең дә ахыры аяныч тәмамлана.

Өченчесе: күрәләтә шантаж ясау. Баланың дөнья белән хушлашу планы юк, ул үзенә игътибар таләп итә. Бу – аның җан авазы.

Дүртенчесе: паросуицидаль төр. Ягъни тәнне кисеп, җәрәхәт ясау. Бу яшерен эшләнә, аның максаты үлем түгел, ә тән сызлавы аша җан әрнүен басу. Ул күбесенчә импульсив, түземсез кешеләргә хас. Куркыныч ягы шунда: эмоциональ киеренкелекне бетерү өчен ул гадәти нәрсәгә әверелергә мөмкин, яралар да торган саен тирәнрәк ясала.

Психиатриядә тагын Бордерлайн синдромы дигән термин да бар. Монысы рухи чир белән чиктәш санала. Бордерлайн синдромы дигән диагноз куелган кешеләр дә импульсивлар, аларда даимилек булмый: дусларын, шөгыльләрен, партнерларын, яшәү урынын еш алыштыралар. Үз-үзенә тән яралары ясау аларга да хас. Бордерлайн синдромы дарулар белән түгел, психик эмоцияләр ярдәмендә дәвалана.

Кайчак баланың үз-үзенә зыян ясавы холык үзенчәлеге түгел, ә баш миендәге зур булмаган тайпылышлар белән дә бәйле булырга мөмкин.

Иң төп һәм иң беренче сәбәп – гаиләдәге киеренкелек (якын кешеңне югалту, әти-әнинең аерылышуы, үзара аңлаша алмау, тормыш авырлыкларында баланы гаепләү). Җавапсыз мәхәббәт, дуслар белән мөнәсәбәтләрнең бозылуы, укудагы кыенлыклар, имтиханнарны бирә алмам дип курку, әти-әниләрнең өметен аклый алмау шушы адымга этәргеч була да инде. Монда баланың холкы, хисчәнлеге, рухи сәламәтлеге зур роль уйный.

Ничек ярдәм итәргә соң? Бу очракта якыннарының мөнәсәбәте бик мөһим. Баланы яратырга, аны үзен яратуларына ышандырырга, нинди генә хәлдә дә аның таянычы булырга кирәк. Шулай ук дусларының да хәлгә керә белүе сорала. Нindидер мавыгулары, үзенә кызыклы шөгыльләре булса, ул рухи киеренкелекне җиңелрәк кичерә, стрессларга бирешми. Аның холкында шундый үзенчәлекне тойсагыз, психологка, психотерапевтка күрсәтегез. Кайчак яшүсмерләр үзләре дә, әти-әниләре дә психологка барудан кыенсына. Психолог белән аралашуның киләчәктә зуррак хаталардан йолып каласын белсә икән алар! Ул аны кичерешләрен аңларга, үз-үзен дөрес тотарга өйрәтәчәк, килеп туган хәлдән чыгу юлларын күрсәтәчәк.

Баланың рухи кыенлыклар кичерүен сизгер әти-әни күрми калмый. Иң элек аның үз-үзен тотышы үзгәрә, ул йә үз эченә бикләнә, йә елый, ярсый, гел каршы эндәшә, әйткәнне тыңламый, хәтта киресен эшли. Укуында проблемалар башлана, дәресләргә йөрми. Бала үзенә авыр икәнен сүзләр белән дә белдерә: «Бөтенесеннән туйдым! Тиздән миннән котылырсыз! Минем болай яшисем килми!» ише сүзләр – аның ярдәмгә чакыруы. Чын күңелдән сөйләшәсе, аңлашасы урынга, «Сиңа тагын нәрсә ошамый? Без синең өчен дип тырышабыз, ә син?» – дип, әти-әниләр хәлне тагын да катлауландыра гына. Баланың «мине беркем дә аңламый» дигән уе ныгый гына бу сүзләрдән. Мондый очракта ул киңәшкә түгел, кызгануга, хәлен аңлауга мохтаҗ. «Мин сине аңлыйм, хәзер сиңа авыр» кебек сүзләр белән аның ягында булуыгызны күрсәтегез. Кайчак хәтта укудан ял итеп тору да файдага гына. Табиб белән киңәшеп, балага тынычландыра торган дарулар биреп карарга мөмкин. Ләкин ни генә булса да, баланы рухи проблемалары белән ялгызын гына калдырмагыз.

ТАБАСЫ ДА БАГАСЫ



Миңназыйм СӘФӘРОВ, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире

Кыз бала үстерү авырракмы, әллә ир баламы? Бу сорауга дөрес җавап бирү өчен, белгеч яки психолог булудан бигрәк, аларның ике төрлесен дә үстереп карарга кирәктер. Ике кызыбызның ике оныгын үстерешкәннән соң, минем дә бу сорауга үз җавабым бар.


Бу дөньяга беребез дә бар нәрсәне дә белеп тумый. Тора-бара, акрынлап тормыш тәҗрибәсе барлыкка килә. Аннары – акыл. Без дә кызыбыз Гөлназны алып кайткannan соң, барлык яшь әти-әниләр кебек үк, шок хәлендә калдык. Нишләргә дигән сорау бөтен барлыгыбызны биләп алган иде. Андый халәт озакка сузылганда хаос башланасын чамалый идем – эшне тулысы белән үз кулыма алдым. Хистән генә диярлек торган хатынымның, имезүдән кала, бала чүпрәкләре юарлык түгел, биләү биләрлек тә тәҗрибәсе юк булып чыкты. Менә шул чакта эштән кайткан ир, «кая соң монда ашарга?» дигән урынсыз сорауны да куйса, кичәге бәхетле тормышның чәлпәрәмә килүе бик мөмкин.

Авыр эшне ир-ат һәрвакыт үз өстенә алганда гына аның өйдә баш булырга хакы барлыгын үзем үскән патриархаль гаиләдә ныгытып үзләштергән идем. Безнең әти беркайчан да өйдәге эшләрне ир-атныкына яки хатын-кызныкына бүлү ягында булмады – көченнән килгәннең барысын да карусыз эшли иде. Бу тәртипне мин дә бозмаска тырыштым. Бала карашканда да, кызларның катлаулы үсмер чакларында да, акча тапканда да, бүген – өч гаилә бер булып яшәргә мәҗбүр булганда да. Барысын да уртага салып сөйләшү, килешеп эшләү – безнең гаиләдә язылмаган закон. Кызлар моны күреп үсте. Шуңа да бездән бер генә серләре дә булмады. Нәрсәнедер әйтеп бетермичә калганнарын да шунда ук сизенә, тоемлый идек. Мондый чакта берберебезнең күзләренә туп-туры карап: «Әйтеп бетермәдең бит, кызым! Әнә күзләрең шул хакта сөйли», – дибез. Әле бүген дә шулай итәбез. Менә шундый чакта «гаепле» ихлас итеп елмая да сөйли башлый. Егетләр турында сүз барганда да шулай булды. Әниләренә түгел, башта миңа киләләр иде. Аннары кызлар үз этиләренә охшаганнарны эзли дигән гыйбарә дә дөрестер, күрәсең.

Кияүләребезнең икесе дә эшне минем кебек үк ир-атныкына, хатын-кызныкына карап бүлү ягында түгел. Алар да еш кына безнең белән киңәшләшә. Өйдә менә шундый гадәткә әверелгән тәртип булганда баланы тәрбиялим дип азапланасы да юк икән бит. Безнең халык тик торганнан гына оясында ни күрсә, очканында шул булыр дип әйтмәгәндер инде. Сөбханалла, оныклар да шул тәртиптән чыкмаска өйрәнеп килә. Дөрес, дөньяны туздырып (көч күплектәндер!) уйнарга яратучы ир балалардан аерыла кыз балалар. Безнекеләр рәхәтләнеп курчак уйный, бизәнептөзәнеп образларга керә иделәр. Әни мәрхүмә безгә килгәч әйтә торган иде: «Мондый баланы унны да табарга була ул!» Ул безне – алты баланы да, үзе әйтмешли, эш арасында гына табып үстергән. Иң зур борчулары да ничек итеп тамакларын туйдырасы да, ничек итеп өсләрен бөтен итәсе дигән сораудан торган. Урамда гаугага калу яки мәктәптә тәртип бозу, начар билге алу турында сүз дә була алмый. «Атагызга әйтеп җаныгызны алдырырмын, белегез: кемнеке – шуныкы», – ди торган иде әни аяк баскан саен. Мин дә кызларыма шулайрак әйтеп килдем һәм бүген дә әйтәм – телгә керә күрмәгез!

Тәрбия димәктән. Кайберәүләр еш кына бала тәрбияләүне каяндыр укып белгән, ишеткән яки күргәнне балага тукып өйрәтү дип аңлый. Андыйлар еш кына үзләренең бертөрле яшәп, икенче төрле сөйләгәннәрен аңламыйлар, күрәсең. Баланы үзеңнән ерагайтуның моннан да яхшырак алымы булмыйдыр ул. Бүген балалар әллә ниндигә әйләнде дип зарланучылар да, иманым камил, аларның кулына айпад яки телефон тоттыручы – «кит әле, комачаулыйсың», дип, янынннан этәрүче ата-аналар. Дөньяны танып-beləсе килгән сабыйны үз әти-әнисе читкә этәргәндә, ул сабый кемгә барып сыенырга да, кемгә үзенең иң яшерен серен сөйләргә тиеш соң?!

Гаилә ул – тулы бер кечкенә генә дәүләт. Аның, язылмаган булса да, үз Конституциясе, законнары, теле, гореф-гадәтләре, дине, рухы була. Шулай иткәндә буыннар чылбыры да өзелми, вак-төяк проблемалар да күпкә азрак була.



ИРЛӘРГӘ КИЗӘНМИК



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Җәмгыять ирләрнең ирлеген үтерә, дип чаң кага белгечләр. Гүзәл затлар, ярдәм итәсе, таяныч буласы урынга, үзен күрсәтергә тырыша. Бөтен проблемаларны хәл итеп йөреп, тормыш дилбегәсен үз кулларына алалар да, соңыннан «чын ирләр юк» дип зарланалар. Хәзерге егетләрне кечкенә чакта артык иркәләп йә киресенчә, аларның ир башлангычын сындырып үстерсәләр, соңыннан ирдәүкә хатын җәтмәсенә килеп кереп, ир сыйфатларын, бигрәк тә җаваплылыкны тулысынча югалта башлыйлар. Алар шуңа күрә гаиләдән читтә ирлекләрен күрсәтергә омтыла, йә булмаса «эчке эмиграция»гә китә. Тормыш куудан туктап, уйлап карыйк: бу – безнең, хатын-кызларның, иң төп борычы булырга тиеш бит югыйсә. Әллә проблеманың бөтен фаҗигасен аңлап бетермибезме? Табиб андролог-сексопатолог Любовь МУМЛАДЗЕ белән әңгәмәбез әнә шул хакта.

Любовь Саввовна, хәзер югары технологияләр заманы, без интернет колларына әйләнеп барабыз. Шундый зур мәгълүмат агымы булганда мәхәббәткә урын да калмый кебек.

– Иң элек җаннар бер-берсенә кагыла, аннан соң гына – тәннәр. Бездә мәхәббәтне нигәдер секс белән бәйлиләр. Яшьләр әлеге төшенчәләрне бутый. Мәхәббәт – югары хисләр, эмоцияләр. Секс мәхәббәтсез дә булырга мөмкин. Ул – механик күренеш. Ансыз яратып була. Ул ярату гомер буена да сузылырга мөмкин. Мәхәббәтнең асылын рухи яктан үскән кеше генә аңлый. Хатын-кыз ир-атта шундый тирән хисләр тудыра ала икән, бу бик яхшы. Тик мәгълүмат ала торган технологияләр белән бергә кешенең үз-үзен тотышы да үзгәрә. Кызганыч, яхшы якка дип әйтә алмыйм. Тәртип тә, карашлар да, тормыш кыйммәтләре дә үзгәрде. Яшьләр хәзер шуны оныта: гаилә кору өчен социаль яктан өлгергән кеше булу кирәк. Тик хәзер кызларның максаты башкада. Шәһәр урамнарына күз салсак: ир-ат өчен (сүз уңышлы, матди яктан бай булганнар хакында) куркыныч көндәшлек бара. Бизәнү, киенү, йөрү рәвешләрендә дә агрессия бөркелеп тора кызлардан. Ә бу бит бер дә бизәми. Алар шул рәвешле ирләр бик яраткан сыйфат – нәфислекне югалталар. Егетнең кызга карата кызыксынуы өлешчә генә була икән, бер елдан алар икесе ике якка китеп барачак. Шуңа да аерылышу проблемасы безнең Татарстанда актуаль. Теркәлгән һәр икенче гаилә озак та тормый, таркала.

Ә бу нәрсә белән аңлатыла?

– Гаилә коруга җиңелчә генә караудан килеп чыга бу. Элек 25 яшькә кадәр сафлыкны саклау гадәти хәл иде. Хәзер 20 яшьтән соң да кыз булып йөрсәң, көләргә дә күп сорамыйлар. Ул безнең җәмгыятькә мәҗбүри рәвештә кертелгән ят культура. Хатын-кыз җенесен Аллаһы Тәгалә нәрсәгә биргәнен аңлаган кызлар үзләренең асылын саклый.



Фото: www.pixabay.com

Любовь МУМЛАДЗЕ:
«...Хатын-кыз яшьлегендә азып-тузып йөрми икән, кияүгә чыккач, ул һәрвакыт ире артыннан барачак. Бигрәк тә бу җенси мөнәсәбәтләрдә чагыла. Гүзәл затлар ир-атка яраклашып яши. Һәр парның үз биоритмы...»

Заманы шундыйдыр: кызлар – юньле егетләр юклыктан, егетләр акыллы кызлар очрата алмаудан зарлана. Алар арасына, җитмәсә, әлеге дә баягы интернет килеп керә. Яшьләрне виртуаль дөнья үзенә тарта.

– Интернетка бәйлелектән хатын-кызларга караганда, ир-атлар күбрәк интегә. Аларның психоэмоциональ үзенчәлеге шундый. Нәрсә эшли башласалар да, аны көндәшлек нигезендә алып баралар. Ир-ат уен белән мавыга икән – картамы ул, покермы, әллә интернетмы, алкоголизм булмасын – аңарда бәйлелек тиз туа. Ә бу исә башка ихтыяҗларны бетерә. Аңа хатын-кыз да кирәкми башлый. Шундый очраклар бик күп: мөнәсәбәт корыр, танышыр урында айлар буе интернетта утыралар. Бу бит табигый асылыбызга каршы бару! Алар социумнан төшеп калган кешеләр. Җитмәсә, янында аның өчен барысын үтәргә әзер әбисе белән әнисе булса. Бернәрсә өчен дә борчыласы юк, бар да әзер, хәтта урыннан торырга да кирәкми. Ашауны да компьютер янына ук китереп бирәләр. Шуңа өйләнергә дә ашыкмый ул. 30 яшьлек ир-егетләр ата-ана йортыннан китәргә ашкынып тормый хәзер. Ир балада иң элек җаваплылык тәрбияләргә кирәк. Эчкечелекнең дә тамырлары әнә шуңа килеп тоташа. Әлеге социаль күренеш «эчке эмиграция» дип атала. Тормыштан канәгать булмаган көчсез кешеләр, гадәттә, җай чыккан саен стаканга үрелә.

Өйләнмәгәннәре түгел, гаиләле кайбер ир-атлар да, хатыны янына ятып, аны назлар урында, төне буе интернетта утыралар. Моңа без, хатын-кызлар гаепleme?

– Юк, үзләре шундый. Әйттем бит, ир-атларда азарт көчле. Шуңа да, алар һәрвакыт безнеке булсын өчен, бергә үткәргән вакытны кызыклырак итәргә кирәк. Ир-атта хатын-кызга карата кызыксыну туарга тиеш. Көчле затлар бит тумышлары белән аучылар. Бүгенге җәмгыятьтә ир-ат, гомумән, хатын-кыз нигә кирәк миңа дип уйларга мөмкин. Балаларны ул суррогат анадан да таптыра. Берәү кирәкме, өчәүме. Фатир тулы теләсә нинди техника. Ир-ат үзенең көнкүрешен менә дигән итеп оештыра ала. Күп хатын-кызлар шуны аңлап бетерә алмый. Көчле зат үз янында һәрнәрсәгә авыз турсайткан кызчыкны түгел, шәхес күрергә тели. Йөрәгенә сукмак сала алмыйсың икән, күңел ачуны ул теләсә кайдан эзли башлаячак: интернет, автомобиль, чит хатыннардан... Ир-ат өчен проблема түгел бу. Шуңа күрә хатын-кыз серле, зирәк, сыгылмалы булырга тиештер. Шәрык әкияте «Мең дә бер кичә»не укыгыз. Анда падишаһ ни генә кыланмый, ә Шаһрезадә һәрвакыт назлап каршы ала, аңа әкиятләр сөйли башлый. Һәм шул рәвешле падишаһны үзенә карата. Бүгенге хатын-кызларга әкиятләрне мәгънәсен аңлап укырга киңәш итәм.

Хәзерге җәмгыятьтә хатын-кызлар ир-атлар белән ярыша-ярыша яши. «Нигә миңа ир? Барысын да үзем булдырам» дигән фикерне еш ишетергә туры килә.

– Ир-ат белән көрәшергә кирәкми. Кызганыч, Татарстанда шундый тенденция дә яши. Хатыны паровоздан алда чаба: ире алдыннан йөгерә. Җүләркәем, кая йөгерәсең, ник йөгерәсең, сиңа нәрсә кирәк? Ир-атка аннан көчлерәк, каттәрәк икәнеңне раслыйсың киләме? Алай була алмый ул! Карагыз, Нобель премиясе лауреатлары арасында, нигездә, кемнәр? Хатын-кыз ясаганмы савытсаба юа торган машинаны? Тракторны ул уйлап тапканмы? Әллә ракеталарны хатын-кыз очыртканмы? Гүзәл затлар үз функцияләрен онытып җибәрә. Вакытларын да, көчләрен дә мәгънәсезгә сарыф итә. Тирә-якка күз салсак, ир-ат акылы, ир-ат кулы белән булдырылган дөньяда яшибез ләбаса. Шуның өчен генә дә хөрмәт итәргә кирәк аларны!

Шулай да, ни өчен хатын-кыз ир-атның асылын томаларга тырыша соң?

– Ир-атны көч белән җиңеп булмый. Шуңа күрә дә аңа каршы көрәшкән хатын-кыз көтелмәгән адымнарга бара: якынлыктан баш тарта, мыскыл итә. Ятак белән шантажлау – ахмаклык. Әлеге адымга барганчы яхшылап уйларга кирәк. Аның өчен кем син: сатып алырга мөмкин булган фахишәме, әллә яраткан хатынмы? Бервакытта да моның белән ирне тилмертергә кирәкми. Хатыны янында рәхәт икән, ир-ат бервакытта да читкә йөрми. Андый уй башына да килми. Ул көчен башкага – үзен күрсәтүгә, рухи яктан үсүгә юнәлтә. Әгәр дә өйдә тавыш-гауга булса, ирләр муенын боргалый, тирә-якны күзәтә, шәфкатьле хатын-кызны эзли башлый.

Бу, мөгаен, ир-ат физиологиясен белмәгәннән дә киләдер. Нормаль ир-атка, миңа калса, һәрвакыт секс кирәк.

– Алай гына да түгел. Алар 24 сәгать буе шуны гына уйлый! Тик сексуаль конституцияләре төрле булуын да онытмыйк. Сексуаль этика хакында да онытмау зарур. Хатын-кыз үзен ятакта дөрес тота белергә тиеш – өйрәнсен! Мәсәлән, яратышкан вакытта көнкүреш әйберләре турында сөйләшергә кирәк түгел. Ир-атның бөтен дикъкате бер генә әйбергә тупланган бу вакытта! Шундый тәҗрибә үткәргәннәр: ана мәче белән ата мәче якынлык кылганда, алар янына тычкан җибәргәннәр. Ана мәче аны шундук тотып алыр өчен ычкынырга теләгән, ә ата мәче... аңа бөтенләй игътибар итмәгән! Нәрсә сөйләгәнемне аңлыйсызмы? Яратышкан вакытта тычкан тотарга кирәкми!

Любовь Саввовна, сез ир-атлар арасында импотенция арта, ә иң куркынычы – яшәрә дип чаң кагасыз. Бу проблема каян килеп чыкты икән?

– Бу чынлап та шулай. Ир-ат – индивидуум. Зур хыяллары булмаган, үзен реализацияләргә теләмәгән үсмер егет юк. Социум мөмкинлек бирми икән, кемдер бандитлык юлына баса, кемдер «эчке эмиграция»гә китә, йә җайлашып яшәргә тырыша. Матди ягы нык булган, үз-үзенә ышанган ирнең потенциясе дә яхшы. Андый көчле затны басып торышыннан, хәтта башын ничек югары тотуыннан ук танып була. Җәмгыятьтә үзен күрсәтә алмаганнарның тестостерон гормоннары да түбән. Импотентка әйләнү дигән сүз бу. Ә андый ирләрдә яшәүгә дәрт сүнә, аларны бернәрсә кызыксындырмый. Совет чорында да, патша заманында да ир-атка акча эшләргә мөмкинлек бар иде, ул иртәгәсе көне өчен артык борчылмады. Хәзер якты киләчәккә бернинди гарантияләр юк, көн туса, стресс кичерәбез. Ә ул – эрекция дошманы. Акча юк, эш юк, мөмкинлекләр юк, җитмәсә, «булдыксыз», дип, хатыны игәүләп тора. Бу исә ирлек дәрәҗәсенә суга! Монда кабак төше дә, каймак та, хәтта гормоннар кадауның да файдасы булмаячак. Тестостеронның түбән булуы социаль фаҗигагә әйләнеп бара. Өстәвенә, импотенция яшәрә. Хәзер 30 яшьтән яшьрәк ирләрдә дә очрый әлеге авыру. Шул ук яшь егетләрне генә алыйк. Эш таба алмыйча өйдә утыралар. Ә анда – шул ук компьютер, интернет. Акча юк, очрашып йөргән кыз юк, потенция дә юк...

Шунысын да әйтергә кирәк: потенция даими рәвештә якынлык кылганда гына арта. Җәмгыять шушы юлдан барса, тиздән ирләр гормонына кытлык башланачак: мәни илкүләм хәзинәгә әйләнәчәк.

Сез бик куркыныч фаразлар ясыйсыз. 20–30 елдан соң ил белән нәрсә булып бетәр соң алайса?

– Минә шуннан нәтиҗәләр чыгарыгыз. Бетәчәкбез!

Димәк, илнең киләчәге хатын-кыз кулында да булып чыга?

– Бөек Октябрь революциясенә нәрсә китергәнен искә төшерик. Бөтенесе дә Путилов заводы эшчеләренең хатыннарыннан башлана бит. Ирләренә хезмәт хакы бирмиләр, өйдә ипигә акча юк. Хатыннары бунт күтәрә. Моның нәрсә белән тәгәлләнүен барыбыз да беләбез, тик кан коешлар булмасын иде. Без болай да бик аз, бигрәк тә көчле затлар. Уйлап кына карагыз: Россия – үз-үзенә кул салучы ир-атлар саны буенча беренче урында, хатын-кызларга караганда алар 15 елга азрак яши. Сакларга кирәк ир-атларны! Иң элек сәламәтлекләрен кайгыртырга. Авыргач кына түгел, профилактика өчен дә җитәкләп табибларга йөртергә.

Шуны да онытмау зарур: ирләрнең ирлегенә кагылырга ярамый. Хатын-кыз, бернигә карамый, якынлык кылырга һәрвакыт әзер булырга тиеш. Шул вакытта гына ул чын хатын-кыз булачак. Киресенчә икән, ул хуҗабикәгә йә бу тормышта бернәрсәгә әзер булмаган гап-гади түтәйгә әйләнә. Тагын бер нәрсә әйтәм: уңышка ирешкән һәр ир-ат артында зирәк хатын-кыз тора.

Ә СЕЗ ИРЕГЕЗГӘ НИЧЕК ЭНДӘШӘСЕЗ?

Гөлнур
САФИУЛЛИНА



Блогер: www.syuyumbike.ru

Сер булмаса, әйтегез әле, сез ирегезгә кем дип эндәшәсез? Яратып, якын итеп аңа гына әйтә торган берәр сүзегез бармы?

Безнең халык хисләрен бик ачып салмый, сүз саен бер-берсенә «кадерлем» дип дәшми инде ул. (Гомумән, «кадерлем» сүзе татарларда китапта, җырда, шигырьдә генә яши бугай. Югыйсә шундый матур сүз. Кадерлем... «Матур да бит... Тик аны оялмыйча ничек әйтәсең? Артык төче килеп чыга кебек», – дияр бу урында кемдер.)

Тирә-юнемдә яшәгән, үзем белгән парларны искә төшереп утырам әле: кем кемгә ничек дәшә?

Бер танышымның иренә һәрвакыт «акыллым» дип кенә мөрәҗәгать итүен беләм. (Аның иренә бу сүз шундый да туры килә! Хатыны аңа башкача эндәшсә, мөгаен, килешмәс тә кебек.)

Икенче бер танышым иренә «картым» ди. Шундый йомшак итеп, наз белән, иркәләнеп әйтә ул аны. (Ә ире аңа «карчыгым» ди. Юк, юк, карт белән карчык булырга шактый иртә әле аларга. Әмма барыбер ничектер килешә үзләренә болай әйтүләре.)

Хатыны иренә – «әтисе», ире хатынына «әнисе» дип эндәшүчеләр шактый. Җылы, рәхәт сүз... Беренче тапкыр үземә «әнисе» дип әйткәнне ишеткән мизгел һаман да истә...

Матурым... Монысы бигрәк тә күп таралган бугай. (Бер дус кызымның: «Яратмыйм шул сүзне! Бигрәк авылча яңгырый!» – дигәне күңелгә кереп калган. Әмма чит кеше түгел, якының дәшсә, мөгаен, башкача яңгырыйдыр ул. Миңа нигәдер шулай тоела.)

Әһлия апаның мәрхүм ире Гаян абыйга гомер буе «Әйдим» дип әйтүен ишеткәч башладым әле бу хакта сүзне.

Безнең күрше йортта яши Әһлия апа. Бик дини, укымышлы карчык. Ничә керсәң дә, кулында Коръән китабы булыр. Туксанга җитеп килсә дә, биш вакыт намазын, уразасын калдырганы юк. Аның белән сөйләшеп утыру – җан рәхәте. Бу юлы ул ире хакында сөйлисе итте әле.

– Балык Бистәсе районының Солтан авылыннан иде ул. Солдатта вакытта сугыш башлана – шуннан туры фронтка озаталар. Әсирлеккә эләгә... Аннан исән-имин котылса да, үзебезнең якка чыгуга, кулга алалар, төрмәгә утырталар. Заманасы шундый була бит... Төрмәдән чыккач: «Авылда йорт тулы кеше, анда кайтып нишлим?» – дип, читтә урнашып кала. Эшләгән җирендә бер татар кызы белән танышып, аңа өйләнә. Берничә елдан авылга хатынын, кызын ияртеп кайтып төшә. Гаян капканы ачып керүгә: «Гөлҗамал апаның малае әсирлектә булган аның», – дип, тиешле урынга хәбәр итүчесе табыла. Авыл кешесе шулай бит ул, берсенберсе чага... Кабат килеп кулга алалар, Черек күлгә алып китәләр. Бу юлы 25 елга хөкем итәләр...

– «Мин монда шул гомер берүзем ничек яшим?» – дип, хатыны үз ягына кире китәргә булды. Паромга кадәр озата бардым, елый-елый аерылыштык, – дип сөйли иде кайнанам.

25 ел утырмый ул, амнистиягә эләгә. Кайткач: «Көтмәгән, ташлап киткән», – дип, хатынын, кызын кире эзләп бармый. Кабат өйләнә, әмма ул хатыны да авырып үлеп китә.

Мин Дөбъяздан Казанга әнинең әнисен һәм сеңлесен карарга дип махсус күчеп килдем. Кияүгә мине димләп бирделәр. «Теплоконтроль»гә эшкә урнашкан идем, беркөнне кайтсам, өйдә ят кеше бар. Әби: «Кызым, сиңа сүзем бар, – ди. – Менә бу ир сине сорап килгән. Гомер буе безне саклап утыра алмассың, ризалаш», – ди. Кунак ишетмәгәндә миңа пышылдарга да өлгерде: «Кул биреп исәнләште – кулы йомшак. Хатын-кызга начар булырга тиеш түгел ул».

Апа белән икебезне алып китеп, яшәгән җирен дә күрсәтте Гаян. Кабан күленнән тауга менгән урында әйбәт кенә йорт салып чыккан. Сарае, зур гына бакчасы бар. Ул бакчага ни генә утыртмаган! Калырга булдым...

Безнең авылга кайтып, никах укытып, туйлар ясап килдек. Кайнанам бераз безнең белән яшәр дип уйлаган идем, ул да үзләренә кайтырга ашыкты. Өйдә икәү генә калдык... Тартынам, кыенсынам... Ошаганын да белмим, ошамаганын да...

Миннән алты яшькә зуррак бу. Абый дип дәшсәң, яхшы түгел. Үзеңнән шулкадәргә олы кешегә исеме белән әйтергә дә оят.

– Әй дим, – дип дәштем беркөнне. – Мин соң сиңа кем дип әйтим икән?

– Үзеңә ничек җайлы, шулай әйт, – диде дә бетерде.

Бер тапкыр дәштем «Әй дим!» дип, ике тапкыр... Шуннан китте... Тирә-күршеләр, туганнар, бергә эшләүчеләре дә белә иде аңа шулай дәшүемне. «Әйдимең өйдәме?» – дип сорыйлар иде.

Әйдим бик әйбәт кеше булып чыкты. Бик тырыш иде. Акчаны икебез дә яхшы эшләдек, бернигә аптырамадык. Балабыз гына булмады... Анысы – миннән. «Теплоконтроль»дә безне врачлар гел килеп тикшереп торалар иде. Бер хатын-кызлар врачы: «Бала алып кайтырга телисеңдер бит? Кил әле үземә, булышам мин сиңа. Син бәби таба аласың», – диде. Болак буенда иде ул больница. Бармадым шул... Әйдим дә, «Бар», дигән иде дә... «Миңа бит инде 40 яшь. Бала табарга хәзер соң. Аны әле үстерәсе дә бар бит», – дидем. «Бер кечкенә кыз тәрбиягә алыйк», – дип караган идем дә, анысына Әйдим риза булмады.

Гаян абыйның вафатына инде унбиш еллап бар. Әһлия апаның «Әйдим» сүзендә күбрәк сагыну, юксыну хәзер...





Илгиз ЗӘЙНИЕВнең тормыш кагыйдәләре

КАЗАНГА ТАУЛАР КҮЧЕРӘМ ДИП КИЛДЕМ

Илгиз ул – **ТЕАТР КЕШЕСЕ, СӘНГАТЬ КЕШЕСЕ, ИҖАТ КЕШЕСЕ.**

Мин бик гади кебек. Хәтта артык гади дип әйтер идем. Мине белмәгән кешеләр, бәлки, башкачарак уйларга да мөмкин. **ЯКЫННАН БЕЛГӘННӘР ӨЧЕН ГАДИ МИН**.

Ялкаулык белән көрәшеп яшим. **ЯЛКАУ БУЛГАНГА КҮП ИҖАТ ИТӘМ**. Чынлыкта бит ялкаулык һәркемгә хас. Аны җиңгән кеше бар, җиңә алмаганы бар.

Казанга Тукайның «Пар ат»ындагы кебек ашкынып килдем. Соңгы бер-ике елда миңа авылда бик авыр иде. Мәгълүмат җитми, мохит җитми. **БИЛГЕЛЕ, МИН КАЗАНГА ТАУЛАР КҮЧЕРӘМ ДИП КИЛДЕМ**. Әлегә калкулыклар белән генә көрәшәм.

Көннән-көн Казанның да чикләре тарая, ул да зуррак авыл булып тоела башлый. Әмма бер мизгелдә иҗат кешесенең киңлекләре тирә-юньдә түгел, ә күңелендә икәненә төшенәсең. Шул вакытта иҗатның кайда яшәвеңә бәйле түгеллеген аңлыйсың. **ИҖАТ ТИРӘ-ЮНЬНЕҢ ЗУРЛЫГЫ БЕЛӘН ТҮГЕЛ, Ә ЭЧКЕ ДӨНЬЯҢНЫҢ ЗУРЛЫГЫ БЕЛӘН ҮЛЧӘНӘ БАШЛЫЙ**. Гомер буе авылда калып та иҗат итеп була. Безнең илдә кая барсаң да, мохит үзгәрми. Тәҗрибә белән килә торган акыл бу.

Тормышны ике юл белән корырга мөмкин. Берсе – танышлыклар, якташлык, туганлык, шешәдәшлек аша. Бу очракта син чыгышың белән кайдан, нинди гаиләдән булуың мөһим. Икенчесе – сәләтең, тырышлыгың ярдәмендә – бу очракта бары тик синең никадәр тизрәк профессиональ осталыкка килүең генә мөһим. **ҮЗ ҺӨНӘРЕҢДӘ ХӘТТА ДОШМАННАРЫҢ ДА СИҢА ЯРДӘМ СОРАП МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРЛЕК ОСТАЛЫККА ҖИТӘРГӘ КИРӘК.** Татарстанда бу юлларның икесе дә ачык!

Авылданмы син, шәһәрдәнме – барыбер. **КЕШЕНЕ ЗӘВЫК БИЛГЕЛИ. Ә ЗӘВЫК МОХИТТӘ ФОРМАЛАША.** Аның югарысы, түбәне юк, бары тик аерым мохиттә гадәти булып саналганы бар. Әгәр дә син шәһәрдә авыл зәвыгы белән яшисең икән, билгеле, ул сәер булып күренәчәк. Кешенең эчке сыгылмалылыгы булырга тиеш.

Авылда чакта мин тарих белән кызыксынып алдым. Хун казаннарын безнең күрше авыл тирәсендә тапканнар. Мондый нәрсәләр рухландыра. Минем дә шундый бер тарихи әһәмияткә ия берәр сер ачасы килә иде. **УКЫЙ-УКЫЙ ТАРИХНЫҢ ӘКИЯТ КЕБЕК УЙДЫРМА БУЛУЫН АҢЛАДЫМ.** Ягъни биш кешедән биш ел элек нәрсә булуы турында сорасак, биш төрле җавап яңгыраячак. Ә биш йөз ел элек нәрсә булганын каян беләсең? Миңа калса, тарих һәрвакыт бүгенге көн кулында булачак һәм бүген дәүләт өчен, милләт өчен ничек кулай, шулай күчереп язылачак.

Хәзер бөтен нәрсәне сәнгать, диләр. Сәнгать ул – матурлыкка омтылу. Матурлыкны кем ничек күрә – сәнгатьнең хикмәте шунда. **ИҖАТ ТОРМЫШНЫҢ ТӨГӘЛ КҮЧЕРМӘСЕ ИКӘН, УЛ ӘЛЕ ИҖАТ ТҮГЕЛ**. Бөтен нәрсә уйдырма гына икән, ул да иҗат түгел. Синең уйдырмаң – чынбарлыкка, чынбарлыгың уйдырмага охшаса, ул сәнгать була, минемчә.

Куркыныч әйберләр күп булган җирдә иҗат көчлерәк. **ИҢ КӨЧЛЕ ӘСӘРЛӘР РЕВОЛЮЦИЯЛӘР, БӘРЕЛЕШЛӘР, ФАҖИГАЛӘР ВАКЫТЫНДА ТУГАН.**

МИН РУС ҺӘМ ЧИТ ИЛ КЛАССИКАСЫН УКЫП ҮСТЕМ. Пушкин, Чехов, Тургенев, Островский, Шекспир... Ә татар драматургиясен (мәктәп программасыннан кала) Камал театрының телевизордан күрсәткән спектакльләре аша гына белә идем. Яттан белә идем. Казанга укырга килгәнче, профессиональ театрда спектакль күргәнем булмады.

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНА МИНЕ Чиләбе гастрольләреннән кайтышлый **ХӘЛИМ АБЫЙ ҖӘЛӘЛОВ БЕЛӘН ИЛДУС АБЫЙ ӘХМӘТҖАНОВ**ның поездда әдәбият хакындагы әңгәмәләре һәм яттан бер-бер артлы шигырь сөйләүләре **ГАШЫЙК ИТТЕРДЕ**.

Кызганыч, чәчмә әсәрдә иҗат итүче иң көчле авторларыбызның гомере соцреализм чорына туры килгән. **НЫКЛЫ СТРУКТУРА, ЧЫН ПРОФЕССИОНАЛЬ КУЛ БЕЛӘН ИҖАТ ИТКӘН БӨЕК АВТОРЛАРНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕ СОЦРЕАЛИЗМ ИДЕОЛОГИЯСЕ БЕЛӘН СУГАРЫЛУ АРКАСЫНДА ВАКЫТ СЫНАВЫН ҮТМӘСКӘ МӨМКИННӘР.**

Сәнгатьтә «тема күтәрү» дигән төшенчә бар. Ләкин аны еш кына «теманы атап үтү» белән бутыйлар. **ӘЙБӘТ ТЕМА ТАБУ ҺӘМ АНЫ АТАП ҮТҮ ӨЧЕН ТАЛАНТ ТА ҖИТӘ, Ә АНЫ КҮТӘРҮ ӨЧЕН ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК,**

Фото: Анна Арахамия

ҺӨНӘР КИРӘК! Тема күтәргәндә дә бил сындырырга мөмкин.

Милләтчелек бездә бик эгоистик ул. Мәхәббәт – яраткан кешеңнең кимчелекләрен күреп тә ярату, диләр бит. Милләтне дә шулай яратканда гына чын милләтпәрвәр буласың. Кайвакыт шундый күренешне күзаллыйм: **БҮГЕН МИЛЛӘТ БЕТСӘ, ИРТӘГӘ МИЛЛӘТЧЕЛӘР: «БЫЕЛ БЕТӘ ДИП, МИН БЕРЕНЧЕ ӘЙТКӘН ИДЕМ!» ДИП СУГЫШЫРЛАР КЕБЕК.**

Мин өйдә булсам да, эштә булсам да, кабинетым үзем белән. Иҗат кешесенең офисы – аның башында. Ул һәрвакыт эшли. Хәтта ятып торганда да. Иҗат кешесе читтән караганда гына ятып тора, асылда исә ул эшли, ягъни уйлый. Шуңа **БЕРКАЙЧАН ДА, КАБАТЛАП ӘЙТӘМ: БЕРКАЙЧАН ДА ЯТЫП ТОРГАН ИҖАТ КЕШЕСЕН УРЫНЫННАН КУЗГАТМАГЫЗ!**

Шунысы бар: **МИҢА ҮЗЕМӘ ГЕНӘ ДӘ РӘХӘТ, КЕШЕЛӘР БЕЛӘН ДӘ ҮЗЕМНЕ РӘХӘТ ХИС ИТӘМ.**

Өйдә булырга яратам. Миңа гаиләмнең имин булуы мөһим. Болай кайдадыр еракта, урман эчендәге берәр авылда яшәргә дә риза. Хәтта шулай теләр дә идем. Әмма **БАЛАЛАРЫМНЫҢ ҮЗЕМ КЕБЕК АВЫЛДАН ЧЫГЫП КИТЕП, ӨР-ЯҢАДАН БАШЛАУЛАРЫН ТЕЛӘМИМ.** Нәсел һаман бер урында таптана дигән сүз була бу. Ә алар барыбер еракка китәргә телиячәк. Үземнән беләм.

Балалар хәзер бүтән. **ХӘЗЕР БАЛА ТУУГА – ШӘХЕС, Ә БЕЗ ҮСКӘНДӘ ӨЙЛӘНГӘЧ КЕНӘ КЕШЕГӘ САНЫЙ БАШЛЫЙЛАР ИДЕ.**

БАЛАЧАКТАН КАЛГАН КҮҢЕЛ ЯРАЛАРЫ ИҖАТ КЕШЕСЕ ӨЧЕН КИРӘК. Шуның белән карьерасын кора ул.

ӘГӘР МИНЕ КАБАТЛАРГА ТЕЛӘҮЧЕЛӘР БУЛСА, МИҢА БАРЫБЕР БУЛЫР ИДЕ КЕБЕК.

КАРАРЛАР КАБУЛ ИТКӘНДӘ ВАКЫТ НИКАДӘР АЗРАК БУЛСА, ШУНЫҢ КАДӘР ЯХШЫРАК.

МИНДӘ КҮПМЕДЕР ДӘРӘҖӘДӘ АВАНТЮРИЗМ ДА БАР. Мәсәлән, курчак театрына спектакль куярга чакырдылар, мин ризалаштым. Аңа кадәр гомеремдә дә курчак тотып караганым юк иде. Нәтиҗәсе: без аның белән «Алтын битлек»кә кадәр килеп җиттек. Балет куярга чакырсыннар – барам.

Мин, гомумән, болай эшләсәм ярар микән, аңларлармы, абруем төшмәсме, дип, саклык белән генә эш иткән кешеләрне аңламыйм. **БЕЗ БОЛАЙ ДА ТЕАТРДА УЙНЫЙБЫЗ БИТ ИНДЕ.** Кайчак уңышсыз спектакль чыкса, аны милли масштабта фаҗига итеп кабул итәләр. Кара да оныт андыйны! (Спектакль изге төшенчәләрне мыскыл итмәгән очракта.) Берәү дә үлмәде, беркем зыян күрмәде. Ә режиссерга тәҗрибә булды.

Миңа «пьеса язасым килә», дип килгәннәре бар. Яз соң! Аның өчен бернәрсә кирәкми. Каләм ал һәм иске битне чиста ягына әйләндер дә яз. Әгәр дә инде шуннан соң да язу теләгең бетмәсә, инде киңәш сора. **ЯЗЫП КАРАМАГАН КЕШЕНЕ НИЧЕК ӨЙРӘТӘСЕҢ?**

Беренче әсәрләрең башка кешене кабатласа да ярый. **ЯЗА-ЯЗА ГЫНА ҮЗ СТИЛЕҢ БАРЛЫККА КИЛӘ.**

Гөнаһтан куркам мин. **ИҢ ЗУР ГӨНАҺ, МИНЕМЧӘ – КЕШЕ ХАКЫНА КЕРҮ.** Әмма шунысы да бар: үткәннең гөнаһлары бүгенге көнеңне пычратмасын, ди безгә Китап. Мин аны бер пьесамда да кулландым. Тәүбәгә килеп гафу үтенгәч, алга таба яшәү турында ул. Әгәр элекке гөнаһларың киләчәгеңне билгели икән, минә шунысы зуррак гөнаһтыр.

«Интеллигент» сүзе безнең илдә генә бар дип беләм. Җәмгыять дөрес җирдә мондый төшенчә була да алмыйдыр ул. **БЕЗДӘ БИТ КЕШЕЛӘР ҮЗЛӘРЕН АЕРЫП КУЯРГА ЯРАТА. АЕРЫП ДИГӘНДӘ, КҮБРӘК ӨСТЕН КУЯРГА ТЫРЫША.** Бу сүзнең билгеләмәсендә калганнарыннан тыш, «тәрбиялелек» дигән сыйфат та бар. Бүген нәкъ минә шунысы төшеп кала.

ГОРУРЛЫК ҺӘМ ШАТЛЫК ХИСЕН ЕШ БУТЫЙЛАР, МИНЕМЧӘ. Мәсәлән: әти-әниләр балалары белән горурланырга мөмкин, ә минә балалар әти-әниләре белән горурлана алмый, алар шундый әти-әни гаиләсендә тууларына шатлана гына алалар.

Кайбер кеше «мин татар булуым белән горурланам», ди. Әйтерсең лә ул кем булып туасын үзе сайлаган. Син татар булып туган, моны Аллаһы Тәгалә шулай хәл иткән, синең моңа катнашың юк. Ә инде кеше бер милләттән булып, үзен икенче милләттән дип әйтә икән, анысы – хурлык. Балаларыңны татар итеп тәрбияләсәң, аның белән горурлана аласың. Гәрчә анысы да синең бурычың әле. Коточкыч шартларда тәрбияләргә туры килмәсә, билгеле. **МИНӘ МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕҢ СИНЕҢ ТАТАР БУЛУЫҢА ШАТ БУЛСА, АНЫСЫ ИНДЕ ЧЫН ГОРУРЛЫК.**

Минем гел картаясы килә иде. Тизрәк финалны күрү теләге бар иде. Хәзер **ҺӘР ЧОРНЫҢ ҮЗ РӘХӘТЕН ТОЯРГА КИРӘК**леген аңладым.

Бүген дөнья шундый бертөрле. Бөтен нәрсә Кытайда эшләнә. Хәтта чит илләргә баргач, алып кайтыр нәрсә юк. Болай кызык түгел. Һәр илнең, **ҺӘР МИЛЛӘТНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ БУЛЫРГА ТИЕШ ДИП УЙЛЫЙМ.**

Ландыш ӘБҮДӘРОВА әзерләде.

НАХАК СҮЗ



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Нахак сүз – җанны иң яралый торган сүз. Аны ишеткәч, акланырга кирәкме?

– Нахак сүз «бохтан» дип атала. Бар гайбәт, ул кеше нидер кылса, шуны сөйләп йөрү. Гайбәт бик гөнаһлы эш. Галимнәр аны кеше үтерүгә караганда да зуррак гөнаһ, диләр. Ә бохтан – ялган гайбәт, ягъни булмаган әйберне сөйләү. Беренчесе кеше үтерүгә тиң булса, икенчесенең ни дәрәҗәдә куркынычлыгын күз алдына китерү дә авыр...

Бар яла ягу, сүз йөртү. Ул дөрес тә булырга мөмкин, ялган да. Монысын кемдер кайчак кешеләрне кычкырыштыру өчен махсус эшли: берәүне икенчесе каршында начар итеп күрсәтмәкче була. «Ул синең хакта шулай дип әйтте», – ди. Тегесенә дә шундый ук сүзләр ирештерә: аларның араларын боза. Бу да зур гөнаһларның берсе.

Яла ягылган кешегә нишләргә соң? Беренчедән, борчылмаска, тынычланырга кирәк. Икенчедән, үзең шушы юлга басып: «Ул үзе шундый», – дияргә һич ярамый. Өченчедән, мөмкинчелек бар икән, аклансаң да ярый.

Зур галимнәр турында да төрле сүзләр йөрткәннәр. Хәтта Пәйгамбәребез хакында да! Аның хатыны Гайшә хакында да: «Иренә хыянәт итә», – дип сөйләгәннәр. Имам Шәфигый турында начар сүз таралгач, дусты килә дә: «Синең турында шулай дип сөйлиләр», – ди. «Син моңа ышанасыңмы?» – ди имам Шәфигый. Дусты: «Мин үз күзләрем белән шушы эшне эшләгәнеңне күрсәм дә, ышанмас идем», – ди. Яхшы дуслар бервакытта да мондый сүзләргә ышанмый. Нахак сүзләр таралу, шулай итеп, дуслар белән дошманнарны аерырга да ярдәм итә. Сиңа килеп: «Бу эшне эшләдеңме?» диюче начар була алмый, чөнки ул аны башкаларга сөйләп йөрми, үзеңнән сорый. Шиге юк – шуңа сорый. Ниндидер хәбәр килсә, без аны ялган дип кабул итәргә тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә: «Берәр фасикъ (ягъни бозык) кеше хәбәр китерсә, тикшерегез», ди. Аныкы 100 процент ялган, ышанмагыз дими. Тикшереп карауның бер зыяны да юк. Шуңа күрә килеп сораган кешегә үпкәләргә кирәкми.

Имам Шәфигый үзе турында начар сүз сөйләүченең кем икәнен белә һәм аңа күчтәнәчкә җиләк-җимеш җибәрә. Теге кеше аның янына килеп: «Бу бүләкне нәрсәгә бирдең? Синең турында сөйләп йөрүемне беләсең бит», – ди. Имам Шәфигый: «Мин сиңа рәхмәтле, чөнки гөнаһларымны үз өстеңә алдың. Бу бик зур кыюлык», – ди. Синең хакта нахак сүз сөйләүче ул гөнаһларыңны үз өстенә ала дигән сүз: кыямәт көнендә алар өчен ул җавап бирәчәк. Нахак сүз белән бу дөньяда сиңа күз яше китерсә, тормышыңны авырайтса да, теге дөньяда ул синең коткаручың. Шуңа күрә, иманлы кеше моңа дучар булса да, шатлана гына. Кеше үзе хакында нахак сүз ишетә икән, сабыр итсен. Ялганның гомере озын түгел: бер-ике ай сөйләп алалар да, аннары онытыла ул.

Димәк, акланып тормасаң да була?

– Бик җитди очрак икән, аклансаң була. Моны хәзер социаль челтәрләр аша мөрәҗәгать итеп тә эшләргә мөмкин. Тик вак, көнкүреш әйберләр турында сүз бара икән, акланунын кирәге юк. Вакыт һәм кыямәт көне барысын үз урынына куячак. Муса галәйһиссәламнең Аллаһы Тәгаләгә әйткән сүзе бар: «И Раббым, шулай эшлә әле – минем турында начар сүз сөйләмәсеннәр», – ди ул. «И-и Муса, мин моны үзем өчен дә эшләмәдем», – ди Аллаһы Тәгалә. Әйе, аның турында да начар сүз сөйлиләр. Ул моңа юл куя, кешегә сынау булсын ди.

...Хәлиф солтан дигән кеше, халык ничек яши икән дип кала буйлап барганда, урамда аунап яткан бер мәет күрә. «Бу кем, нишләп аны күммисез?» – дип аптырап сорый. «Беребезнең дә кулы күтәрелми, чөнки бу кеше эчкече һәм зиначы», – диләр. Хәлиф гаҗәпләнә, болай булмый, туганнары беләме икән, дип, хатыны янына бара. Хатыны бу хәлне ишетмәгән булып чыга. «Кешеләр аны күмми, шулай-шулай дип әйтәләр, дөресме бу сүзләр?» – ди Хәлиф. «Әйе, ул бөтен эшләгән акчасын аракыга тота иде, – ди хатыны. – Көн саен өйгә аракы алып кайта иде. Алып кайта иде дә, түгә иде. Бүген шуның кадәр кешене хәмер эчүдән коткардым, дия иде. Ә кешеләр аны эчә дип уйлады... Әйе, ул гел фахишәләр янына йөрде. «Бүген күпме акча эшлисең?» – дип сорый. Аннан: «Менә сиңа акча, өеңә кайт», – дия иде. Аннан, бүген фәлән кадәр кешене зина кылудан коткардым, дип кайтыр иде. «Шулай йөрсәң, кеше сине начарга чыгарыр», – дип, күп тапкырлар әйттем. «Күрерсең әле, патша мине үзе күмәчәк», – дия иде ул».

Бу сүзләрне ишеткәч, патша, янында булган галимнәрне җыеп, бу кешене, зурлап, җеназа намазы укып, күмәләр.

Нахак сүз ишеткәч, кеше рәнҗесә, аның бу рәнҗеше төшәме?

– Төшә, әмма рәнҗүдән мәгънә юк. Рәнҗү – ул тәкәбберлек билгесе. Мин моңа лаек түгел дип уйлый кеше, ягъни үзен башкалардан өстен куя. Ә лаекмы-түгелме икәнен кайдан беләсең? Аллаһы Тәгалә генә белүче! Үзен балык йоткач, Нух пәйгамбәр: «И-и Аллам, мин бит Пәйгамбәр, нигә мине болай итәсең?» дими, «Мин залим булдым, начарлык кылдым», ди. Кеше дә башына шундый борчу төшсә, гөнаһларым бар, кичер дип әйтергә тиеш. Бу ситуациядә син мәзлүм – догаларың кабул була торган чак, үзең өчен дога кылып калсаң, файдасы күбрәк булачак. Ә төшәсе рәнҗеш ул болай да төшә. Пәйгамбәребез: «Әгәр бер кеше икенчесе турында нахак сүз сөйләсә, үзе шундый хәлдә булмыйча үлмәс», ди.

ТАТАР ФЕМИНИЗМЫ-2

Сез, хатыннар, үзегез «иптәш» дисез,
Үзегез
Иптәшлектән качасыз;
Кызлыгыгыз күренеп торсын өчен
Күлмәгегезне
Тезегездән ашып ачасыз.

Һади Такташ. «Җырым синңа булсын».



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

1917 елгы революциягә кадәр хатын-кызларны һәм интеллектуаль, һәм социаль-хокукый яктан тиң күреп, аларны укымышлы итүгә һәм сайлау иреге бирүгә ирешкән татарларның «хатын-кыз мәсьәләсе» дә башка бик күп милли мәсьәләләр кебек үк, «чынга ашмаган хыяллар» булып кала. Россия империясендә большевиклар Совет власте урнаштыруга, илдә һәрьяклап тигезләү процессы башлана. Шул исәптән, хатын-кызлар белән ирләрне дә…

Социаль революциядән – сексуаль революциягә

Россия империясендә хатын-кызларның хокуклары Европадагы гүзәл затларныкы белән чагыштырганда болай да үзгәрәк булган: бездә хатын-кызларның хосусый милек хокукы бар, алар тулы хокуклы варис булып кала ала. Хатын-кызлар үзләрен «без – изелгән катлам» дип әйтә алмый, чөнки Россия империясендә азсанлы дворяннар – элитадан кала, күпчелек ирләр дә шундый. Шуңа да патша Россиясендә феминизм хәрәкәте, Көнбатышның «богема феминизмы»ннан аермалы буларак, большевиклар белән бер сафта революцион идеяләр белән рухланып, ирләргә каршы түгел, ә системага каршы көрәшкә чыга. Һәм, ниһаять, 1917 елның мартында кырык меңлек митингтан соң, РСФСРның яңа Конституциясе хатын-кызларга тулы хокук һәм тигезлек бирә. Мондый хокуклар дөньяның бер генә илендәге хатын-кызларда да булмый ул вакытта.

Әнә шул вакытта ир белән хатын бер-берсенә «тормыш иптәше» булып китә.

Ленин моны «чувственный бунт» дип атый һәм «әлеге энергияне большевизмның җиңүенә таба юнәлтергә кирәк» дигән нәтиҗә ясый. Бу турыда инкыйлабка кадәр үк партия съездларында сөйләшүләр бара. РСДРПның III съездында Л. Троцкийга җенесләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең яңа теориясен эшләргә кушыла. 1911 елда Троцкий Ленинга болай дип язган була: «Һичшиксез, сексуаль изү – кешене колга әйләндерүнең төп коралы. Мондый изелүләр булганда, азатлык турында сүз дә була алмый. Гаилә, буржуаз институт буларак, үз-үзен юкка чыгарды. Бу турыда эшчеләргә сөйләргә кирәк...» Ленин аңа җавабында: «...Гаилә генә түгел. Сексуальлеккә кагылышлы барлык тыюлар да бетерелергә тиеш. Безнең суфражисткалардан өйрәнер нәрсәбез күп: хәтта бер җенесле мәхәббәтне тыюны да бетерергә кирәк».

Яңа җәмгыятьтә ир белән хатын мөнәсәбәтләренең нинди булырга тиешлеге турында 1915 елда Ленин үзенең революцион көрәштәшләренең берсе – «кадерле дусты» Инесса Арманд белән дә фикерләшә: ул «мәхәббәт белән пролетар гражданлык өйләнешүен» таләп итүне алга сөрә. «Мәхәббәт ирке» таләп итү, тышкы яктан революцион, ә эчтәлеге буенча үтәдән-үтә буржуаз һәм җәмгыятькә каршы булып тора, ди Ленин.

20 нче еллар башында ук яңа совет җәмгыятендә кайнар бәхәсләр башланып китә. Анда дворян нәселеннән булган генерал кызы Александра Коллонтай аеруча актив катнаша. Алай гына да түгел, ул Европа илләрендә Поль Лафарг, Карл Каутский, Роза Люксембург, Владимир Ульянов-Ленин белән танышып, аларның фикерләрен сеңдереп, Россиягә кайткач, хатын-кызларның «яңа моделен» үз мисалында раслап күрсәтә. Коллонтай бернича тапкыр кияүгә чыга, Россиядә беренче хатын-кыз министр, большевиклар хөкүмәте әгъзасы була. Чиркәүдә укылган никахлы иренең җеназасына барып тормый, аның каравы, үзеннән 17 яшькә кечерәк ире беренче бөтендөнья сугышында Германиягә әсирлеккә төшкәч, аны үлем җәзасыннан алып калу өчен СССРда беренче булып рәсми никахын терки. Бер үк вакытта идеологик эшчәнлек тә алып бара. Аның 1923 елда «Молодая гвардия» журналында басылып чыккан «Дорогу крылатому Эросу!» мәкаләсе комсомол яшьләргә һәм пролетариатка манифест буларак яңгырый. «Мораль рабочего класса, поскольку она уже выкристаллизовалась, напротив, отчетливо отбрасывает внешнюю форму, в которую выливается любовное общение полов. Для классовых задач рабочего класса совершенно безразлично, принимает ли любовь форму длительного и оформленного союза или выражается в виде преходящей связи. Идеология рабочего класса не ставит никаких формальных границ любви. Но зато идеология трудового класса уже сейчас вдумчиво относится к содержанию любви, к оттенкам чувств и переживаний, связывающих два пола», – дип тәмамлый ул мәкаләсен.

Нәкъ шушы вакытта Коллонтайның секс турында «бер стакан су теориясе» барлыкка килә. Әлеге теориянең фәнни нигезе Маркска ук барып тоташа. Маркс өчен гаилә – милеккә варис булу хокукларын йөртүче ячейка. Коммунизмда бернинди хосусый милек тә юк, димәк, ата кешегә улының үзенә охшавы турында кайгырырга кирәкми. Хатын-кызлар ирләр белән бер сафта коммунизм төзи. Ул арада хатын-кыз бала таба, җәмгыять аны тәрбияли. Хезмәт ияләренең өйдә ашарга пешерәсе, кер юасы булмый – алар көнгә өч тапкыр ашханәдә туклана, имеш... Шуңа да сексуаль ихтыяҗлар, Коллонтай уйлаганча, бер стакан су эчкән кебек кенә канәгатьләндереләчәк. «Һәр комсомол үзенең җенси омтылышларын канәгатьләндерә ала һәм тиеш», «Һәр комсомол кыз аңа каршы килмәскә тиеш, югыйсә ул – мещанка» дигән агитация плакатлары чыга ул вакытта... 1920 елда хатын-кызларга аборт ясарга рәсми рәвештә рөхсәт бирелә. Тарихта беренче тапкыр!

Бу чорда «Долой стыд!» дигән шәрәләр оешмасы барлыкка килә. Мәскәү урамнарында шәрә ирләр, шәрә хатын-кызлар күренә башлый. Хатын-кызлар туфли генә киеп, урамга чыгып йөри. Бер кулында – сигарета, икенчесендә – «сумочка».

Ялгыз ана (мать-одиночка) дигән төшенчә шушы вакытта барлыкка килә.

Ә СССРда секс юк!

Чынбарлыкта бер стакан су теориясе утопия булып чыга. Әмма яшь хезмәт ияләре аны хуплап каршы ала. Революцион Россиягә килеп чыккан язучы Герберт Уэллс гаҗәпләнеп болай дип яза: «Социализм җиңгән илдә секс эшләре бик гади икән...»

Әлеге «җенси бунт» һәм 12 шәр кешелек коммуна-гаиләләр, уртак балаларның нәтиҗәсе озак көттерми: ятимнәр, «ялгыз аналар» күбәя, венерик авырулар тарала... Клара Цеткин: «Бу «бер стакан су теориясеннән» безнең яшьләр тәмам тилерде. Ул аларның язмышын җимерә. Аның яклылар, бу теорияне Маркс идеяләреннән, ди. Рәхмәт инде мондый марксизм өчен», – дип яза.

Беренче дөнья, гражданнар сугышы, ачлык илне демографик яктан саклап калу өчен хатын-кызны гаиләгә кайтаруны таләп итә. Маркс белән Энгельсның яңа формациядәге гаилә турындагы идеяләренә нигезләнгән тәҗрибә үз койрыгын үзе тешли.

Шул ук Коллонтайга халык комиссары (хәзергечә министр) вазыйфасын башкарганда, гаилә мөнәсәбәтләренә караган берничә декрет әзерләргә туры килә: «Аерылышу турында», «Гражданнар никахы турында» һәм «Никахтан тыш туган балаларның хокукларын никахта туган балаларныкы белән тигезләү турында»...

1924 елда Я. М. Свердлов университеты нәшриятында «Революция һәм яшьләр» брошюрасында «Революцион пролетариатның 12 җенси кагыйдәсе» чыга.

Хакимияткә Сталин килү белән, 20 нче еллардагы сексуаль революциягә нокта куела. Илне индустрияләштерү башлана. Сексуаль күңел ачуларга көч тә, вакыт та әрәм итәсе түгел! «Гаилә – җәмгыять ячейкасы», «тәртип нигезе – бер хатын белән тормыш» кебек лозунглар кайтарыла. (Лозунглар, плакатлар, агитация – Советларның төп пропаганда коралы һәм үзе бер сәнгать!) Дөрес, Сталин Ленин сүзләре белән эш йөртә.

Сталин Конституциясеннән «Никахны бетерү турында»гы маддә төшеп кала. 1934 елда гомосексуализм өчен җинаять җәзасына тарта башлыйлар, 1936 елда абортлар тыела... «Долой стыд!» оешмасы активистлары репрессияләнә. Яшьләргә сексуаль тәрбия бирү туктатыла. Әйтергә кирәк, 20 нче еллардагы сексуаль революция башкала һәм зур шәһәрләрдә генә таралыш ала. Әмма нәкъ менә шулар яңа дәвергә ишек ача да.

Шулай итеп, СССР драмасының беренче акты тәмам була: «СССРда секс юк!» дигән соңгы реплика белән «тимер пәрдә» төшә.

Азат ителгән хатын-кызлар?

Мәгълүм булганча, 1926 елда Казанда СССРда яшәүче татар хатын-кызлары өчен «Азат хатын» журналы чыга башлый. Журнал рус теленә «Свободная женщина» дип түгел (балачак стереотиплары буенча мин аны нәкъ шулай дип уйлый идем), ә «Освобожденная женщина» дип тәрҗемә ителә. Күрәсең, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә комитеты Секретариатында ул вакытта татар хатын-кызларын Совет Көнчыгышы – Урта Азия белән бутаганнар. Алар өчен 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналы – буржуазия калдыгы, ә татар кызларының пәрәнҗә ябынмавы, күбесенең укымышлы булуы турында, имеш, белми. Хәер, Мәскәүләрдә әле дә бит безне Октябрь инкыйлабыннан соң гына укырга-язарга өйрәнгән дип ышанучылар бар...

Әле 1939 елның гыйнвар санында да «Азат хатын» В. Ленинның 1921 елда Көнчыгыш халыкларының совет өлкәләре һәм республикаларындагы хатын-кызлар бүлекләре вәкилләре киңәшмәсенә котлау сүзләрен кабатлап бастыра. Котлау «Правда» газетасының 10 апрель санында басылып чыга. (Әсәрләрнең 3 нче басмасы тексты буенча басыла. 309 нчы бит):

«Тирән кызганычка каршы, кичектерелмәслек эшләр миңа Сезнең киңәшмәгездә катнашырга мөмкинлек бирми. Кайнар тәбрикләр җибәрәм һәм эшегездә яхшы уңышлар телим. Бигрәк тә көнчыгыш хатын-кызларының алда торган беренче Бөтенсоюз партиясе съездын хәзерләү эшенә уңыш телим, бу съезд, әгәр дөрес әзерләнсә һәм дөрес үткәрелсә, һичшиксез, көнчыгыш хатын-кызларының аңын уяту һәм аларны организацион берләштерү эшендә гаять зур роль уйнаячак».

Бу юлларны укыганда күз алдына «Белое солнце пустыни» (1969) фильмы гына килә. Ләкин мин Зөһрә-Гөлчәтәйләр арасында үземнең әбиләремне күрмим, чөнки Урта Азиядә «Көнчыгыш хатыннарын азат итү» акциясе барган 20 нче еллар башында безнекеләр рабфакларда укый, завод-фабрикаларда эшли, колхоз эшләренә йөри, ягъни җиң сызганып социализм төзелеше сафларына баса һәм большевикларның төп рупоры булган вакытлы матбугатка яза, «Азат хатын» журналын чыгара...

Татарларның зыялы катламы большевикларның гаилә мөнәсәбәтләренә дә, хатын-кызларның яңа моделенә дә хәер-фатихасын бирмәс иде дип уйлыйм. Бу вакытта Исхакый белән Максуди, мәсәлән, мөһаҗирлектә, Бигиев шулай ук эзәрлекләүләрдән качарга мәҗбүр... Шул ук вакытта Арманд, Коллонтайлар Мәскәү белән Одессада тук тормышта яшәсә дә, Идел буенда коточкыч ачлык котырган чор бит әле. Кем әйтмешли, аның кайгысымыни?

Фото: Батрак Фатих кызлары. 25 гыйнвар 1930 ел. «Сөембикә» («Азат хатын») архивыннан.

(Дәвамы киләсе санда.)

ФОТОБӘЙГЕ:
«ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Рушан Хәялиев. Казан.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз.
Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак.
I урынны алачак авторны – планшет, сайтта барган тавыш бирүдә иң күп тавыш җыячак фоторәсем авторын кесә телефоны көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.

PRESSA

Лилия ГӘРӘЕВА

МАДАМ ВЕНЕРА (ЯКИ БЕЗНЕҢ МАДАМ)

Туганнары шулай атый аны. «Безнең мадам, диләр. Югыйсә нинди мадам инде мин, гап-гади бер хатын-кыз...» – дип гаҗәпләнә Венера ханым Шаһиәхмәтова.



Эше шундый аның, үзенә дә, башкаларга да таләпчән булмый хәле юк. Бәлки, әнә шул таләпчәнлегенә күрә «мадам» диюләредер, бәлки, нәзакәтлелегенә ишарәләүләредер... Күпме гомер директор вазыйфасын башкару, кешеләр белән эшләү холкына да үз мөһерен төшерми калмагандыр, билгеле. Юк, юк, барысын да утлы табада биетә торган җитәкче түгел ул. Үзе әйтмешли, камчысы кулында булса, прәннеге – кесәсендә.

Казан уртасында – Кабан күле буендагы «Татар утары»на иртә килсәң дә, кич килсәң дә, Венера ханымны очратмый калмыйсың. «Эш сәгатегез ничәдә башлана соң сезнең?» – дим. «Әллә тагын... Кем исәпләгән инде аны? Иртән күзне ачуга эшне уйлый башлыйм, төнлә дә йокы керми: иртәгәсе көнне планлаштырырга керешәсең. Оныкларым килсә генә дөнья мәшәкате чигенеп тора бераз», – Аким белән Майя исенә төшүгә, дәү әниләренең йөзләре нурланып китә. Хәер, оныклар турында бераз соңрак. Миңа бу нәзакәтле дә, көчле дә ханымның басмадан басмага баса-баса шушы юлны ничек узуы кызыграк. Нинди ул – ресторатор ханым?

– Бу өлкәгә язмыш дулкыны кагып кертте бугай мине. Югыйсә үзем өчен кечкенәдән үк хыял офыкларым ачык иде: сәүдә иде ул. Балачагым искә төшсә дә, гел бер күренеш: әнә без апам белән яфраклар җыеп кайтабыз да үлчәүгә салып үлчибез. Шалт та шолт счет төймәләрен тартып, «товар» бәясен исәплибез, – Венера Габделхак кызы белән балачак хатирәләренә уралабыз. – Шуңа да сигезенчене тәмамлау белән сәүдә училищесына укырга кердем. Аннары – эш, аннары – гаилә, аннары – балалар... Аннары – толлык ачылары... Мин бик иртә кияүгә чыктым... һәм иремне дә бик иртә югалттым. Тормышымның шул авыр мизгелендә иремнең дуслары ярдәм кулын сузды: «Венера, безгә эшкә кил әле. Булдырасың син аны», – диделәр. Ресторан бизнесына беренче тапкыр шулай килеп эләктем. Онытыласым да килгәндер, үз-үземне тынычландырасым да – башаяк белән эшкә чумдым. Администратор булып башлаган идем, бармен да булдым, менеджер да, соңрак директор ярдәмчесе, инде менә – директор. Эшемне авыр булды димим. Сәбәбен дә беләм – яратып эшләгәнгә җиңел тоела ул. Эшкә килгән яшьләргә дә шулай әйтәм: «Яратмыйсыз икән, авыр булачак!» Укытучыларым да искиткеч кешеләр иде шул. Людмила Аркадьевнага гомерем буе рәхмәт хисләре белән яшим. Директор булса да, кухняга кереп, ризыгын да пешерә, менюны да үзе уйлый иде ул. Хәзер менә үзем шулай: бергәләшеп яңа ризык төрләрен уйлап табабыз, аларның атамасын уйлыйбыз.... Менюда «Әтнә» дигән салатыбыз бар. Елкы итеннән әзерләнә, бәясе дә «тешләми», туклыклы да. Без аны үзебез уйлап чыгардык. Ә атамасына килсәк...

Венера ханым белән әңгәмәбезне телефон бүлә. Ә мин күңелемнән аның уйларын дәвам итәм. Донбасста туып, Казанда үссә дә, Венера Габделхак кызы үзен Әтнәнеке саный. Никме? Әти-әнисе шунда туып-үскәнгә, әби-бабасы шунда яшәгәнгә, каникуллары шунда үткәнгә. Әтнә – балачагының һәм яшьлегенең талбише-

ге. Хатирәләре Казан артына күчүгә, үзе дә самими кыз балага әйләнә дә кала.

– Әле дә әбинең мичтә ипи пешергәне күз алдымда. Әнә ул зур чиләктә камыр басып, камырларын саламнан үргән кәрзиннәргә бүлеп-бүлеп сала. Кәрзиннең эче чәчәкле тастымал белән каплаулы. Барысы да истә, әмма кәрзиндә күпереп менгән камырны табага ничек итеп күчерде икән ул? Ул ипинең күзәнәге бытбылдык йомыркасы кадәр булыр иде. Ә тәме! М-м-м... Әби ипигә каймак белән карлыган кайнатмасы ягып бирә. Безнең балачакның пирожноелары әнә шул иде инде...

Җаны талкынганда, йөрәгенә тынычлык табу өчен Камал театрына йөрүен әйткән иде ул бервакыт. Юк, спектакль карау өчен генә түгел, авыл кешеләрен дә сагынып керә ул анда. Ак яулыклы әбекәйләр, түбәтәйле бабайлар, тыйнак авыл апаларына мөнәсәбәте үзгә аның. «Театрга килгәч, алар ресторанибызга да сугыла. Тыйнак кына матур итеп кереп утыралар, менюны карыйлар. Мәтрүшкәле сөтле чәй белән кыстыбый, өчпочмакка заказ бирәләр. Аларның рәхмәте минем өчен әллә нинди мактаулардан да кыйммәтрәк», – ди ул.

Рәхмәт дигәннән, 40 яшендә кабат укырга кергән Венера Шаһиәхмәтова. Бу юлы... психологка.

– Ресторатор эше барыннан да бигрәк клиентлар белән эшли торган эш. Ә алар арасында төрлесе була, безнең эштә иң авыры да шушы инде, – дип аңлата Венера ханым. – Психолог белеме миңа кешеләрне ныграк аңларга һәм алар белән дөрес аралашырга ярдәм итә. Ярый әле укыганмын, дим. Безнең вазыйфа кешеләрне тәмле итеп ашатып чыгару гына түгел бит, алар монда тагын килерлек итеп хезмәт күрсәтү дә. Залга чыгып, кунаклар белән аралашырга яратам. «Татар утары» турында кайдан белдегез?» – дим чит шәһәрләрдән килгән туристларга. «Дусларыбыз әйтте, Казанда булсагыз, сугылмый китмәгез, диделәр. Алар сүзен тыңлап килдек», – диләр. Бу – иң зур бәя инде. Дуслар начарны тәкъдим итмәс. Безнең комплекста теләсә нинди дәрәҗәдәге банкетларны уздыру мөмкинлеге бар. Туган көннәрен монда үткәргән яшьләр соңрак безгә никах мәҗлесен уздырырга килә.

Конан Дойлның әсәрләре белән яшәдем. Кумирым Шерлок иде.

Әле яңарак кына бер төркем кунак килде. «Интернетта сезнең турында бик үк яхшы булмаган фикер язганнар. Кызыксынып килгән идек, ошаттык», – диләр.

Венера ханым күбрәк эш турында гына сөйләсә дә, ара-тирә бүленеп, телефонынннан һаман да шул эше белән бәйле мәсьәләләрне хәл итсә дә, каршымда иң беренче чиратта хатын-кыз утыра. Үз борчулары, үз мәшәкатьләре, үз куаныч-шатлыклары булган хатын-кыз.

– Бу дөньяга килгән һәркем үтәргә тиеш булганның барысын да эшләдем бугай: балалар үстердем, агачлар утырттым, йорт салдым, тик тормадым, ә хәзер инде мин дәү әни. Бүгенге рухи халәтем – дәү әниләрнеке. Ял көннәрендә балаларым килә. Элек елларда чаңгыда чыккан булсам, ә хәзер иң рәхәт ял – оныкларым янында. Көне буе күтәреп йөрсәм дә туймыйм мин алардан. Яшь вакытта үз балаңның үскәнен күрми дә каласың, бәлки, шуңа да балдан татлыдыр ул бала баласы?! Олы оныгымның теле ачылып килә. «Улым, дәү әнине яратасыңмы соң?» – дим. «Юк!» – ди. И-и, шуңа да ничек күңелем булганын белсәгез... Көлмәгез, көлмә, ул әле берәүгә дә яратам дип әйтә белми бит. Киленнәремә дә әйтәм: «Балаларның балачагы бер генә, аларга күбрәк игътибар бирегез», – дим. Пешеренергә бик яратам. Аптырыйлар, көне буе ресторанда йөреп, әле син пешерәсең дәмени, диләр. Улларым килсә (ә алар икәү минем), мин кухняда – алъяпкычлы әни ролендә. Мин пешергән ризыкны әллә каян таный тагын үзләре.

Дөресен генә әйткәндә, ризык никадәр гадирәк булса, шуның кадәр тәмлерәк бит ул. Чит илләргә барсам, ресторан-кафелары буйлап китәм: нәрсә пешерәләр, аны ничек итеп бирәләр... Әйтәм бит, эш күңелемә сеңгән инде ул минем. Ләкин зарланмыйм. Тормышым тагын бер кабатланса, анысында да нәкъ шушылай яшәр идем.

Венера ханымнан алма бәлеше рецепты

Кирәк:
(бер табалык)
- 150 г атланмай;
- 60 г шикәр комы;
- 70 г кибет каймагы (майлылыгы мөһим түгел);
- 200 г он.

Эчлек өчен:
- 700 г кабыгы әрчелмәгән каты яшел алма (ул пешкәндә изелми);
- 80 г шикәр комы;
- 60 г атланмай.



Камырны басып, ике өлешкә бүләләр: 300 г камыр – бәлешнең аскы катына, 150 г – өстенә. Алманы кабыгыннан әрчеп, төшләрен алалар һәм уртача калынлыкта телемләп турыйлар. Туралган алмаларны камыр өстенә матур итеп тигезләп тезеп, шикәр комы һәм эретелгән атланмай сибәләр. Бәлешнең өстен каплап, май, он һәм шикәрдән валчык ясап сибәләр. Алма бәлеше 160 градуслы мичтә 35–40 минут пешә. Табынга кайнар килеш, пломбир белән бирелә.



«Аның өчен иң мөһиме: эчкерсезлек, садәлек, хәтта гадилек. Әмма хисләрдә – төгәллек, тирәнлек. Әсәрләрдән бик тә кешелекле, нечкә җан сулышы бөркелә...»
Хәбир Ибраһим шигырьләрен тәнкыйтьче Мансур Вәлиев әнә шулай бәяли. Ә бу шигырьләр әйтерсең шагыйрьнең көндәлек битләреннән күчкән. Җылы, хисле, сораулы һәм өндәүле... Хатлар, багышлаулар белән тулы... Һәрхәлдә, адресатына да, укучыларыбызга да ошар ул шигырьләр.

Хәбир ИБРАҺИМ

ХАТЛАРЫҢНАН КӨЙМӘ ЯСАП...

* * *

Кызыксыну уяталмас көн кичергән
җылы ояң,
Кызык миңа гүзәл эчке дөньяң.

Ул бүленгән йөзәрләгән,
меңәрләгән кисәкләргә,
Шуңа күрә мөмкин түгел аны
үлчәп-исәпләргә.

Шуңа күрә сине эзли,
сиңа гына тарта күңел,
Беләм ләкин бу дөньяда
сине аңлау мөмкин түгел.

Көндәлектән шигырьләр

* * *

Көннәр буе чыкмыйм өйдән.
(Йөрәктәге әрни ярам!)
Сиңа ишек ачкан көннән
Мин көндәлек алып барам.

Ә син шундый матур дәштең,
Син елмайдың күргәч мине! –
Язып алам һәр сүзеңне,
Язып барам һәрбер көнне.

Кайсын язам шигырь белән,
Шашып чиксез зур бәхеттән;
Кайсын сиңа, килү белән,
Укыйм алып көндәлектән.

Кинәт шундый моңсу була
(Мин язарга иренмәдем!) –
Күзләреңә яшьләр тула,
Сүз дә дәшми иреннәрең...

Чөнки
шундый шигырьләрем.

* * *

Сүрән генә балкый урамнар.
Кечке авыл.
Урам тын калган.
Сулар тонган, туңган улаклар.
Болдырларга тутырып кар салган.

Без киләбез икәү урамнан.
Кыюсызмын...
каушап сүз алам.
Әйтерсең лә сабый бер бала:
Үзем сөйлим, үзем оялам.

Ходай безгә нинди сөенеч биргән!
(Качсын җаннан тормыш
ваклыгы!) –
Күзләреңә кар бөртеге кунган,
Күзләреңдә сөю шатлыгы.

Итекләргә кар иярә барды...
Бәхет артты.
Чатта тукталдык.
Кочаклашып бераз торгач,
карлы
урамнарга кереп югалдык...

* * *

Шушы микән тирән ялгызлык?
Төннәр озын.
Күзләр караңгы.
Күзләр генә иңли алмастыр
Синең белән безнең араны.

Күрешү өчен күп гамәлләр кордым:
Утта яндым, туңдым салкында.
Юлларыңа басып карап тордым –
Иске йортның өске катында.

Син керәсе ишекләрне яптым,
Беркем дә юк – күктә ай гына!
Синең өчен кешеләрдән качтым,
Синең өчен баттым кайгыга.

* * *

Ф-кә

Май аеның офык ямен
Беренче күрәм.
Бу төндә мин кем өчендер
Вакытсыз үләм.

Төннәр бүген нинди якты –
Йөрәктә ялкын.
Нигә шулай ерактагы
Йолдызлар якын?

Күрешергә ара ерак,
Читен, һай, читен!
Синең йөзне хәтерләтә
Алсу күк чите.

Күм син җирне, җылы язым,
Чәчәккә, назга –
Матур төннәр бүләк ит син
Миннән ерак кызга.

* * *
Тышта буран.
Тәрәзәгә
Чиертә буран зәхмәте.
Үкерәдер, сызгырадыр,
И Ходайның рәхмәте!

Тыңланам мин, уйланамын,
Тик нигәдер эч поша...
Уйларыма бер дәва бар,
Ул да булса юл гына.

Кар-буранга баткан иске
Каралты-йортым, курам...
Бар дөньяны каплаган күк
Бу юләр, юньсез буран!
Зилзиләгә колак салып,
Дусларга бәхет юллыйм.
Яшь аралаш ерактагы
Мәхәббәтемне уйлыйм.

Ул соң хәзер нишли икән?
Ул да ялгызы микән?
Әллә моңаеп утырамы,
Әллә җыр җырлый микән?

Әллә ул да нурсыз айның
Җемелдәвен күрәме?
Әллә ул да кар-буранның
Тын алуын көтәме?

Әллә ул да минем кебек
Талчыгамы, арыймы?
Әллә соңгы шәмгын ягып,
Юл ягына карыймы?

Тышта буран. Тәрәзәгә
Чиертә буран зәхмәте.
Үкерәдер, сызгырадыр –
Юк тын алган сәгате.

* * *
Авыл.
Клуб.
Фойе.
Бильярд.
Матур гына җәйге төн иде.
Бильярд сугам инде ничәнче кат,
Тик уенда күңел юк инде.

Клуб шаулый,
Клуб гөрләп ята.
Кыза шунда чатта...
домино.
Бер-берсенең клуб данын сата,
Бер-берсенең төшә җанына.

Тик мин генә никтер читтә калам,
Күңелем яңа көйләр ишетә.
Бәхетемне суккан шарга куеп,
Бертуктаусыз карыйм ишеккә.

Син керүгә кинәт юкка чыкты
Бу тамаша.
Ходай кызганды.
Күз алдымнан кинәт юкка чыкты
Дөньяның бу төпсез зинданы.

Безгә монда калу кирәк түгел,
Иярчене җирле гавамның.
Мин бит бала әле үзем дә...
Онытылганмын,
сине күреп атның
Сөрелеп аккан җансыз күзендә...

* * *
Юк, мин белмим соңлаганың!
(Яза алмам синең юлдан!) –
Биш көнгә бер килә хатың,
Ун көнгә бер – телеграммаң.

Без күрешкән авыл ерак –
Күбәләкле җәйгеояң...
Син су алган кизләү,
улак
Тылсымына җирсү тоям.

Күз алдымда: август төне,
Калган салам, ялан кырлар...
Буш саламда – икмәк исе,
Баш очында – синең куллар...

Ачыла алмыйм.
Мондагылар
Һәр сүземнән кычкырып көлә!
Бу җиңелчә дошманлыклар,
Каршылыклар каннан килә.

Авырлыгын бу дөньяның
Үз өстемә алу белән,
Сиңа тугры калуымның
Бу кадәре каннан килә.

Тик тынгысыз юләр башым
Читкә сөйри мине һаман,
Ерак юлга... һәлакәткә...
Ахры, шундый безнең заман.
Төшләремдә – август төне,
Без хушлашкан күксел урман.
Ачуланма,
әгәр мине
Яздырсалар синең юлдан.
* * *
Син борчылма, мин югалмам,
Саклыйм язган хатларың.
Мин аларның һәрбер сүзен,
Һәр җөмләсен ятладым.

Минем тормыш ярый болай,
Сагыш, кайгы җитәрлек.
Йөрәк каны белән язган
Һәрбер хатың...
истәлек.

* * *
Хатларыңнан көймә ясап,
Мин суларга агыздым.
Һәм соңыннан, кызык өчен,
Күз яшьләрен тамыздым.

Язын сулар ага тулып,
Хатларыңа – олы юл!
Суга җәелә, сагыш булып,
Синең язмаң,
синең кул...

* * *
Менә китәм инде,
Менә китәм.
Тәрәзәңә яфрак сибәрмен.
Көн дә йөргән көзге тар урамга
Исемеңне язып үтәрмен.

Менә китәм инде,
Менә китәм.
Язмыш иртән юлга куганда –
Җан җылысы эзләү кирәк түгел,
Җан җылысы тулы урамда.

Менә китәм инде,
Менә китәм.
Бер кайтырмын әле, билгеле.
Җиргә ятып синең өянкеләр:
«Синме бу?» – дип елар шикелле.

Менә китәм инде,
Менә китәм...





Асия ЮНЫСОВА

КЫШКЫ КҮБӘЛӘК

(Хикәя)

Мин кышны яратам! Ак булганы өчен. Йомшак булганы өчен. Миһербанлы булганы өчен. Бер ул гына Җирнең бөтен каралыгын, шакшысын, бернинди ямьсез сурәтләр булмагандай итеп, пакьли дә куя. Йөрисең ваемсыз гына, садәлеккә сөенеп.

Язны да яратам. Вәгъдәләр муллыгы өчен. Ашкындыра белгәне өчен, мәхәббәт барлыгына ышандыра алганы өчен. Ул да ак чәчәкләре белән алдалый белә бит. Җәй инде шул ак чәчәкләрдән чыңлап торган чынбарлык ясый. Күшеккән күңелләрне дә җылытып, юатып, кинәндереп яшәтеп ала.

Көзме? Анысы муллык, туклык, канәгатьлек! Көзне сагышлы фасыл диләр. Юк сүз! Сагышланмый адәм баласы көз аенда. Үтәлмәгән өметләрен уйлап ямансулый гына. Яз айларындагыча тилереп, иләсләнеп түгел, акылын алдан җибәреп, янәдән гашыйк була... Кеше шул фасылларны ялгап, матур итеп яшәп калу өчен тырыша. Өметләнә!

Хәзер менә дөньяда Кыш тантана итә. Гашыйклар көненең кыш уртасына туры килүе генә мәзәгрәк. Әлеге дә баягы, Кышның миһербанлы булуында түгел микән хикмәт. «Уйнагыз, шаярыгыз, юри генә яраткан булыгыз. Ә мин бөтен давыллы хисләрегезне, ак бураннарыма төреп, истәлеккә алып калырмын. Ак кулъяулыкка төргәндәй итеп кенә йөрәк түрегезгә салып куярмын», ди бугай.

Әлегә кыш. Аклыктан күз камаша. Сәяхәтче кар бөртекләре ялкауланып кына, явар-яумас кына, юка болытлар арасыннан кышкы тәртипне күзәткән Кояшка иркәләнеп кенә, керфекләремә килеп куналар. Кумыйм аларны. Үземне гүзәл бер Кар кызыдай тоеп, җитез адымнар белән мәктәпкә барам. Башкалар узган семестр азагында үтәп бетергән педагогик практика җәһәтеннән дәресләрем бар иде. Мәктәп белән тулай торак арасы җәяү барганда

ярты сәгатьлек юл инде ул. Университетка да, юлымны бераз гына урау итеп, шушы урамнан узып йөри торган идем. Биек йортлар арасында адашып калган агач өйләре белән авыл урамын хәтерләтә ул. Агач өйләрнең тәрәзәләре минем сукмагыма якын гына. Ә минем бер «гөнаһлы» сыйфатым бар. Тәрәзәләргә карарга яратам. Кем яңа челтәр элгән, кемнең яран гөле чәчәк аткан, кемнең ак песие тәрәз төбендә битен юып утыра – барысы да кызык миңа. Соң ул челтәрләрне кеше күрсен өчен эләләр, гөлләрне кеше күрсен өчен үстерәләр ләбаса! Матурлык күренсен өчен!

Тәрәзәләр артындагы дөнья кичен – лампаларга (лампочкаларга диясе килми) ут элдергәч, серле дөнья булып әверелә. Челтәр пәрдәләрнең бизәкләре аша шәйләнгән дөньяда гел бәхетле кешеләр генә яшидер сыман. Бик тә, бик тә үрелеп эчкә карыйсым – шул дөньяны шыпырт кына күзәтәсем килә минем. Кызык, бәләкәй чакта үз өебезнең тәрәзәсеннән үрелеп караганда да тоя идем мин ул серлелекне. Күрәсең, «юк», «ярамый» дигән чикләү – арада пыяла корылган булу шулай тәэсир итә торгандыр.

Таш өйләрнең тәрәзәләре биек. Агач өйләрнеке кул сузымында гына. Бер өйнең сыңар тәрәзәсе сыкылы була. Гел карап үтәм. Трамвай тәрәзәсе кебек карлы тәрәзәгә эчтән кемдер сурәтләр төшерә. Яңа ел алдыннан чыршылар, аю, куян сурәтләрен абайлаган идем. Бүген менә тәрәзә бүлкәсе йөрәк рәсемнәре – валентинкалар белән бизәлгән. Димәк, ул йорттагы кемдер өчен Гашыйклар көне инде чын бәйрәм! Кемнеңдер йөрәге алгысый, ашкына, мәхәббәтне үз йөрәгенә уздырырга әзер икәнлеген сиздерә. Кыз баладыр инде. Аның халәтен аңлап, елмаеп куйдым. Ул «кемнеңдер» кем икәнлеген чамалыйм да бугай. Беркөн мин тәрәз күзендә – бозы эрегән түгәрәктә рәссам Константин Васильев картинасыннан фрагмент күреп калган идем. «Күздә» башына ак шәл япкан, кулына янып торган шәм тоткан кыз сурәте. Карашы сөйгәне кайтасы юлга төбәлгән. Үсмер кызның образга керүе инде бу дигәнрәк уй йөгереп үткән иде башымнан. Хыялый кыз. Имеш, ул да шәм яндырып егетен көтә! Андый татлы халәт кыз баланың кайсында юк инде ул?

Җитмәсә, бу Гашыйклар көне дигән яңа бәйрәм яшүсмерләр йөрәгендәге яшерен серләрне ирекка чыгару өчен бер әйбәт форсат булды. Мин практика уза торган мәктәп тә бүген гөр килә торгандыр. Сигезенчеләрем бер атна элек үк почта тартмасы элеп куйганнар иде инде. «Кемнән кемгә хат барганын почтальон гына белә...» Тик «минекеләр» әлегә берданбер кешедән хат көтүгә караганда, кемгә ничә хат килгәнен санау белән ныграк мәшгуль. Арада чын гашыйклары да бардыр инде аның. Тик гомуми ыгызыгы аларына да яшерен калырга, бәллүр хисләрен аярга булыша.

Уйлаганым рас килде. Мәктәп гөж килә. Укытучылар да, чын педагоглар роленә кереп, дилбегәне бушата төшкәннәр. Бүген катылык күрсәтү ярсыган аргамакны тыярга тырышу белән бер булыр иде. Миңа куратор укытучым бик тиз йомыш тапты. «Бүген күргәзмә дәрес бирү отышлы булмас. Алия сеңлем, синең сыйныфыңдагы бер кызны өендә генә укытабыз. Башка фәннәрнең укытучылары биремнәрен эшләтеп кайтты инде. Татар әдәбияты буенча җыелып килгәннәрен сиңа тапшырам. Ул кыз шигырьләр дә язарга ярата. Бик нечкә күңелле бала. Бүген ул, мөгаен, мәктәптән хәбәр көтә торгандыр. Сыйныфташлары вакыт тапмаслар. Алай да, Диләрәгә дигән хатлары булса, ала кит әле. Бик чибәр бала ул. Бәлки берәрсе аңа да «гашыйклар хаты» юллар. Күңеле үсеп китәр иде. Көзге якта бик теләп мәктәпкә йөри башлаган иде дә бит... Йөрәгенә операциясе уңышлы узганнан соң, ата-анасы да башка балалар белән аралашуын теләгәннәр иде дә бит... Беренче сыйныфтан өйдә генә дәресләр алган бала коллективка кереп китә алмады. Бала-чага аяусыз да була белә бит ул. Кайсыдыр төртеп җибәргән. Хәлсез кыз егылган. Йөрәгенә куелган мотор кебек нәрсәсе ярый әле бөтенләй үк ычкынмаган. Була иде хәлләр. Бар дөньяга яңгырый идек. Әйе, аздан гына харап булмый калдык. Мәктәп ишегалдындагы эскәмиядә яткан җиреннән күреп алып, «ашыгыч ярдәм» чакырттык. Хәзер инде менә кызны өенә йөреп укытабыз. Исән калганына сөенә-сөенә йөрибез инде. Иренмибез. Өлгереше әйбәт. Бик яхшы бала ул, кош баласы кебек. Юк, өф итсәң тузгырга торган тузганак кебек! Аны яклыйсы, җилдән дә саклыйсы гына килеп тора. Бер баргач, сеңлем, син аның яныннан китәргә ашыкма инде. Бик тә кеше тансыклый ул. Синең бер атналык практикаңа «плюс» куярбыз».

Куратор укытучымның шундый мәгънәле булуы, Диләрәгә (кызның исеме шулай икән) карата кайгыртучан игътибары миңа да тәэсир итте. Сыйныфка кагылып чыктым. Кызга хат юк икән. Әллә ничек уңайсыз булып китте. Нәүмизләнеп калыр инде. Диләрә торган йортның адресын алуга ук тәгаен белә идем инде: теге – бозда күз уелган тәрәзә – аның тәрәзәсе!

Миңа ишекне Диләрә үзе ачты. Шул үзе! Әйе, шул кыз! Иңендә дә шул ук ак шәл. Күзләре зәп-зәңгәр. Зәңгәр чәчәк! Алай дисәң, аксыл бөдрә чәчләре тузганакныкы сыман икән шул. Зәңгәр күзле тузганак чәчәге була микәнни соң?! Өф дип өреп карасам, бөдрә чәчләре, юк, кыз үзе дә, ап-ак нур бөртекләре сыман, тузгып очып бетмәс микән?.. Берьюлы әллә ничә төрле чагыштыруга сәбәп булган кыз сизгерлеге белән таң калдырды. Уйларымны укыгандай, ишекне ачканда ук үзе белән кызык итеп кенә таныштырып куйды:

– Диләрә түгел, Күбәләк мин. Кышкы күбәләк. Ак шәлемнән күбәләккә охшыйм бит, әйеме. Ә мин Сезне беләм. «Син» дип эндәшсәм ярармы? Без бит танышлар... Чәчләреңә кар яуган. Ай, бигрәкләр дә килешә икән үзеңә! Туңмадыңмы, Алия апа? Кулла-



рыңны җылытыйм әле. Аякларыңа җылы оекбашымны кидерим әле. – Диләрәнең көтелмәгәнчә якын итеп кайгыртуыннан, үз итеп сөйләшүеннән беркадәр югалып калдым. Әйтерсең, аның янына укытучысы түгел, туган апасы килгән. – Алия апа, мине танымыйсыңмыни? Оныттыңмыни? Диләрә бит мин! Очкычта бергә очтык. Аннары диңгездә бергә ял иттек. Син бит Камиләнең апасы. Ә мин Диләрә. Диләрә мин! Ә син хәзер минем укытучым булгансың икән...

Исемен кабат-кабат әйткәч, мин аны исемә төшерергә тиеш дип уйлый инде бу кыз. Диңгезгә барулар биш ел элек булган иде бит инде ул. Ә минем күз хәтерем бик үк әйбәт түгел. Хәтерлим мин бер Диләрә дигән кызны. Тик миңа ишек ачкан патша кызларыдай гүзәл зат белән шайтан таягыдай арык кыз бала арасында уртаклык таба алмый гына йөдим. Бер тын күземне йомып, биш ел элек булган көннәргә кайтып киләм...

...Ташлыкта бер чуар кош сикеренә. Сиртмә койрык бу. Әллә сиртмә сыйракмы? Русчасы трясогузка. Кош озын сыйракларында тирбәлеп, чуер ташлар арасыннан җим эзли. Шул арада бер тамчы су табып, аны йотып җибәрә. Чуар канатлары белән җилпенгәләп йөгереп китә. Тоттырмый да үзе, өркәк тә түгел. Нигәдер ташлыкны ярата. Озын торыклары аңа таштан ташка сикереп йөрү өчен уңайдыр инде. Аклы-каралы чуар кошчыкны бер кызның тотып аласы килә. Кыз белән кош бик охшашканнар иде. Кыз да озын, арык аяклы; юка, җиңел гәүдәле. Хәрәкәтләре дә таштан ташка сикергән кошныкы кебек – тирбәнешле.

Кошчыкка кыз белән уйнау ошады. Ул, берни булмагандай, янәсе кызны күрмәгәндәй бер рәвеш ала да, кыз шатланып учларын сузуга, канатларын җилпәзә ясап, ике-өч адымга арырак сикереп куя. Кыз тагын ауга чыккан песи адымнары белән кошка якыная. Кошчык тагын – пы-ры-х!

– Әнием, күрдеңме син, мин әле генә бер чуар кошны тота яздым. Бик матур кош иде ул. Тоттырмады. – Кош белән әбәкле уйнаудан сулышы капкан кызыкай әнисе янына килеп чүгәләде.

– Диләрә кызым, балам минем, йөгереп йөрмәскә тырышсаң иде. Ярамый бит инде сиңа. Беләсең бит инде ярамаганын. Әйе бит, беләсең бит?

– Беләм... – Кыз күндәм генә башын ия, боегып кала.

– Белүең әйбәт инде анысы. Әйдә, янәшәмә сөлгегә ят та диңгезне күзәт.

Ә мин аларны күзәтәм. Кыш буе өйдә яисә хастаханәдә ятып иреккә зарыккан бер баладыр инде бу дип уйлыйм. Диңгезнең иркенлеге, җиләс һавасы бик рәхәттер инде аңа.

– Килгән көнне үк сине суга кертсәм, әтиең рөхсәт итәр микән? Шалтыратып карыйк әле.

Чибәр хатыны белән кызын ялга җибәрсә дә, дилбегә өйдә калган әти кулында икән. Кесә телефоны ерактан торып идарә итү өчен бик кулай нәрсә бит ул.

Гаҗәеп ягымлы һәм чибәр кызына берничә елдан тиңдәш булырдай ханымның – Диләрә әнисенең «юк» дигәнгә болай да карышмаган кызына диңгезгә керү өчен ерактагы әтидән рөхсәт сорап тору кадәресе минем бу икаүгә карата дикъкатемне көчәйтеп җибәрде. Ирексез икән болар...

Диңгез буенда агач ятакларда янәшә ятканда сүзләр ялгана торгач, күп серләр ачыла төште:

– Икебез дә «әти кызлары» без. Ирем, мәктәп тәмамлаганымны көтеп алып, сәгате-минуты белән өйләнде миңа. Бер егеткә дә гашыйк булырга өлгерми калдым. Дөньяга ирем күзлеге аша гына карыйсы дип, аның ихтыярына буйсынып яшим. Бөтен хатыннар да шулай яши дип беләдер идем. Менә ялга килгәч тә әле башта аңа менюны телефоннан укыйм, аннары гына аш сорап алабыз. Ирем кушканны гына. Менә ун ел инде шулай. Кызым Диләрә йөрәк чирле булып туды. Нәселдән килә торган чир, диделәр. Ирем ягыннан. Тагын бер бала табу турында уйларга да куркам. Анысы да чирле булып туса дип инде. Ирем табиб минем. Үзенең клиникасы бар. Матди яктан интекмибез. Кызым әтисен миннән ныграк ярата. Тәкатьсезләнеп ярата. Әтисе дә аның өчен үлеп тора. Мин исә олы кыз сыйфатында яшим. Юк, юк, эшкә йөрим мин. Анысына мең шөкер! Ә менә Диләрә мәктәпкә йөрми. Өйдә генә укытабыз. Шуңа күрә мәктәп якын булсын – укытучыларга килеп йөрергә уңай булсын өчен кызым белән дәү әнисе янында яшәп торабыз. Оныгы хакына минем әнием эштән китте. Үзебезнең иркен, матур фатирыбызга кунакка гына барабыз. Диләрәнең гел шунда яшисе килә дә бит... Ирем бездән шунда «ял итә». Ул ничек хәл итсә – шулай инде безнең...

Исемә төште теге диңгез буе. Бала-чаганың судан чамасыз курыккан Диләрәне җитәкләп су читенә алып килүләре дә, кызның, арыклыгыннан оялып, тырпайган кабыргаларын яшерергә тырышып, бөрешеп килүләре, алай да йөзеп карарга бик теләве дә искә төште. Бик тә, бик тә башка балалар кебек буласы – уйныйсы, йөзәсе, биисе килә иде аның. Талпынып карый да, хәлсезләнеп, әнисе янына килеп утыра. Аның җилкәсенә борынын төртеп, нәүмизләнеп кала. Гүзәл (ханымның исеме килбәтенә тәңгәл иде) яшереп кенә кызына дару каптыра. Пышылдашып алалар. «Әнием, мин дә сәламәт булырмын микән? Бүтән балалар кебек чума-чума йөзәрмен микән?» «Менә, кызым, көзгә инде йөрәгеңә операция. Барысы да әйбәт булыр. Әйбәт табиблар килә Мәскәүдән, ди бит әтиең».

Шулайрак икән кызның хәлләре... Бер көнне диңгез буенда очрашкач, Гүзәл: «Без иртәгә китәбез. Алданрак китәргә булдык. Кызымның хәле сагайта. Әтисе кайтырга куша», – диде. Шуннан соң югалтыштык. Телефон язылган кәгазь дә әллә кая булды. Менә бүген үскән, тәмам бер чибәргә әверелгән Диләрә миңа ишек ачты. Садәлеге, ихласлыгы, гаҗәеп ягымлылыгы шул ук.



Рәсем: Наталья Васильева

Бик якын кешеләр кебек чөкердәшә башладык. Минем – укытучы, Диләрәнең укучы икәнлеген дә уйламадык. Диләрәнең дәү әнисе укытучы килүгә пешереп калдырган сыйлар белән сыйланып чәй эчтек. «Әле бүген тагын бер кунак – әтием киләчәк! – диде Диләрә. «Әтием» сүзен әйткәндә кызның балкып китүләрен күрү үзе бер рәхәт. – Мин әтиемне әниемнән дә ныграк яратам. Әнием үпкәләми. Алия апа, телисеңме, әтием килүгә әзерләп куйган җырны сиңа да җырлап күрсәтәм. Алсу җырлый аны. Ул да әтисен минем кебек яратадыр».

Кыз почмакта торган синтезатор янына йөгереп барды. Үзенә үзе музыка белән ярдәм итеп, көчсез, әмма мөлаем аһәңнәр белән җырлап җибәрде:

Минем әткәй көн дә эшкә китә,
Арып кайта аннан кичләрен.
Елмаю итеп алып кайта
Шәфәкъларның алсу төсләрен.

Әткәй, әткәй, аннан башка тагын
Кем бар шулай бала бәгырьле...

Кушымтага җиткәч, Алия тын гына елап җибәрде. Тик барыбер җырны дәвам итте:

Әткәй, әткәй көн дә эшкә китә,
Йолдызларны кайта ияртеп.
Йолдызлар да йоклап китә сыман,
Әткәемнән әкият сөйләтеп.
Кояш сыман әткәй...

Бу урында кызның тавышсыз елавы чынлап елауга әверелде: «Минем әткәй белән бергә яшисем килә. Әбиемнең бу агач өендә, бозлы тәрәзә артында яшисем килми минем. Үзебезнең өйгә кайтасым килә. Әнием: «Безгә анда кайтырга ярамый», – ди. Нигә микән? – Кинәт кыз яшьле күзләрен миңа төбәде. Зәңгәр күлләргә, күз яшьләрен кысрыклап, өмет тул-



ган иде. – Алия апа, ә син миңа берәр хат алып килмәдеңме? Мин үзем унҗиде хат язып җибәргән идем. Дамир булса да язгандыр инде. Хатларны кереп алырга онытткансыңдыр инде, әйеме?»

Миңа бик тә кыен булып китте. Кызның күңеле алгысыган иде. «Сиңа хат юк иде», дияргә ярамый иде. Һич ярамый. Иртәгә бер-ике хат оештырып алырбыз, бүгенгә бүтән җавап табарга иде бит. «Диләрә, мин сыйныфка кагылганда почта тартмасын ачмаганнар иде әле. Әлбәттә, бардыр сиңа хат!»

– Алия апа, нигә миннән: «Ник елыйсың?» – дип сорамыйсың. Минем бит сөйлисем килә... Әтием килгәнгә шатланмыйм мин бүген. Ул иртән шалтыраткан иде инде. Миңа альбом арасыннан әнием белән «Язылышу кәгазен» табып куярга кушты. «Берәүгә бүләк әзерлисем бар», – диде. Ул берәүнең кем икәнен дә, өебезгә нигә кайтырга ярамаганлыгын да сизенәм мин. Миңа операция ясаганнан соң палатама гел кереп йөргән шәфкать туташы белән үбешкәннәрен күрдем мин аларның. Мескен әнием. Мин дә үлсәм, бөтенләй ялгыз кала инде ул! Ничек итеп әтиемне бирми калып була икән? Ә, Алия апа! Өйрәт, син бит укытучы кеше!

Кызның хисләре тузгыган иде. Кыланышлары эзлексез иде. Бая гына моңланып җырлаган кыз инде миңа кылана-кылана бию ритмнарын күрсәтә башлады. Матур бии икән. Ул да булмады: «Шигырьләремне укып карыйммы?» – дип, дәфтәрен актара башлады.

«Төнге мизгелләр,
Урамда яңгыр.
Минем өстәлдә
Шәм генә яныр.
Төнге мизгелләр!
Мин сездә яшим.
Төнге җырларым...
Соңгы көйләрем...»

Ялгызлык, өметсезлек, чарасызлык хисләренә манылган «олылар» шигырьләреннән тәмам төшенкелеккә бирелмәсен әле бу кыз дип, Диләрәнең дикъкатен бүтән нәрсәгә җәлеп итмәкче булып, тәрәзә янына килдем. Ачыш ясаган шат тавыш белән өй эчен тутырдым:

– Менә ни өчен сезнең тәрәзәгез гел бозлана икән! Аңладым мин бу хикмәтне! Эчке каты ачып куелганга күрә ул! Өйдән килгән җылы һава белән тыштан бәргән суык кушылып, боз пәрдәсе хасил итә икән лабаса! Үзем эчтән генә уйлап куйдым: Диләрә яшәгән дөнья да шул – җылылык белән суыклык аралыгында лабаса!

– Анда минем күбәләгем яши. Күрәсеңме, Алия апа, ул иң җылы почмакка сыенган да җәйгә кадәр ял итә. Миңа бит барыбер тәрәзәне ачарга ярамый. Салкын тия. Миңа да, Күбәләккә дә салкын тия! Бозланган тәрәзә ошый миңа. Боз өлгегә сурәтләр төшереп, мин тышкы дөньяга «хатлар» язам. Әнә бит, аларны син дә «укыйсың» икән. Миңа күңелле булып китте. Көннәр җылынгач, тәрәзәне ачарбыз да Күбәләкне җәйгә, болыннарга очырырбыз!..

Мин урамга чыкканда дөньяга кышкы эңгер эленгән иде инде. Мине тәрәзәнең бозы эрегән түгәрәгендә шәйләнгән зәңгәр күз озатып калды. Ә мин көн дә йөргән таныш урамны таныр-танымас рәвештә иләсләнеп, тулай торакка таба атладым. Әйе, кыш яз түгел ул. Кыш вәгъдәләр бирми. Юатмый да. Кыш ул – мәгънәсе минем телемдә генә аңлашыла торган Сагыш фасылы. Кыш ул – минем телемдә генә сиземләнә торган Моңның үзе! Ак кар көртләренә ягылган зәңгәр Сагыш, зәңгәр Моң!

Бу урамнан икенче көнне үк үтеп булмады. Практикага йөрисе юк хәзер. Университетка да трамвайда элдерәбез. Нәүрүзләр узгачрак кына, боздан арчылган таныш тәрәзәдән эчкә үрелеп карарга җөрьәт иттем. Диләрә күренсә, кереп чыгарга иде исәбем. Өй эчендә кеше йөргәне беленми. Күбәләк тә әллә кая киткән. Болыннарга очарга иртәрәк лабаса...

Шулай гомер уза торды. Бервакыт трамвай тукталышында чәч бөдрәләре гел Гүзәлнеке кебек бөтерелеп торган, килбәте, буй-сыны белән дә Диләрәнең әнисен хәтерләткән берәүгә игътибар иттем. Тәгаен шул үзе дисәм... Бу яшь хатынның йөзенә бөтен вөҗүден биләп алырлык хәсрәт иңгән. Йөрәгем жу-у итеп китте. Гүзәл дә мине таныган икән. Үзе минем яныма килде:

– Диләрәбез үлде бит. Гашыйклар көнендә – үзенә 14 яшь тулган көнне үлде. Ул көнне Сез дә килеп киткәнсез икән. Туган көне икәнлеген әйтмәгән идеме? Әйтмәгәндер... Бик тыйнак бала иде шул. Әтисе киләсе булгач, мин дә эштән ашыгып кайтмадым. Без бит инде ирем белән бергә түгел идек. Фатирыбызда ул яшь хатын белән торып ята иде инде. Ә Диләрә һаман: «Кайтыйк, өйгә кайтыйк», – дип йөдәтә. Унбиш минут саен шалтыратып тордым. Әтисе килгән. «Язылышу кәгазен» сорап алган. Сизгер бала бөтенесен аңлаган инде. Бик елаган, ялынган әтисенә, өйгә алып кайт, дигән. Бервакыт кызым өй телефонын да, кесә телефонын да алмый башлады. Коелып төштем. Бөтен эшемне ташладым да, туган көне белән котларга дип алган чәчәкләремне, бүләкләремне кочаклап, өйгә йөгереп кайттым. Диләрәм диванга сузылып яткан, янына курчагын яткырган. Чәчәкләрем аның өстенә коелды... Үлгән иде инде. Әтисе кызының кырыгына да килмәде. Әтисен югалту хәсрәтеннән генә үлде кызым. Әтисе генә гаепле.

Диләрә үлгән... Димәк, без икенче көнне кызга юллаган хатларны укып та куана алмый калган. Кичеккәнбез.

Тукталышта – бөтен кеше карап торганда Гүзәл белән кочаклашып елаштык. Мин киттем. Чибәр һәм хәсрәтле хатын ялгыз басып калды. Ул бәгырькәйнең хәзер кызы да, ире дә, өе дә юк! Ундүрт яше тулган көнендә дөньядан киткән кызын уйлап мәңге сагышланыр инде ул. Сагыш елның һәр фасылында да сагалый.



Укучым мине кичерсен, урамда очраган теләсә нинди карчык-кортканы «әбекәй» дип яза торган журналист халкын аңламыйм. Дөньясында бер, ул бердәнбер дип табынырлык әбиләре булмаган, димәк, аларның. Олыгайган карт-корыга әби дип эндәшик. Ә Әбекәй – Әнкәй сүзе кебек үк кадерле, изге ул.

ӘБЕКӘЙ

Роза КАМАЛЕТДИНОВА

Әбекәем – газиз әбием бар иде бит, дип уйлыйм да көрсенәм. Бай рухлы кабатланмас шәхес иде ул. Тик кем генә белгән кадерен! Ул – бердәнбер! Әткәй ягы Мәрьям әбине белмим, мин туганчы ук гүр иясе булган. Мулланур бабай Ишнең аръягыннан яшь хатын алып кайта. Үги әбигә без дә үги идекме, ачык чырай күрмәдек. Бабыкай үзе дә кырыс-кырку адәм иде. Сугышта яраланып, кулсыз кайткан улына – безнең әтигә дә исе китмәгән: янәсе, ни эшкә ярый хәзер?

Ә менә Маһинур әбекәй – әнкәйнең әнисе, дөньяда бер мәрхәмәт, игелек иясе иде. Исемне белеп кушканнар аңа, ай нуры сыман моңсу иде ул, ә күңеле – якты. Моңсулыгы... Буй җиткергән гренадердай дүрт улыңның өчесен сугыш йотсын, ә дүртенчесе – Лотфулласы һәр яз саен ачыла торган яра белән кайтсын да... Олы кызы Сара – әнкәем дә Канаш ягына окоп казырга киткән җирдән тиф ияртеп, аяк-кулларын өшетеп, гомерлек чир алып кайта. Чыкмаган җаны гына бар иде, диләр. Бетмәс-төкәнмәс ул кайгыларга ана йөрәге ничек түзгәндер?!

Язмыш күп сынауларга дучар итсә дә, бәхет читләп үтмәгән мине дә! Иркә-назга тиенеп, әбекәемнең җылы кочагында кадерле бала булып үсүем бәхет түгелмени?! Һич шөбһәсез, бик ярата иде ул мине. Чирле әнисе карый-тәрбияли алмаган зәгыйфь җан иясенең олы мәхәббәткә, соңгы юанычка әйләнүе гаҗәп тә түгелдер! Бер-бер артлы дөньяга килгән күп баласына бирергә өлгермәгән чиксез яратуы нарасый онык өлешенә насыйп булган икән, моннан кемгә ни зыян? Акыл-тәрбия бирергә тырышуы табигый. Тегеләй бул, болай, дип, туп-турыдан суктырмый ул, читләтеп, мисаллар белән, күңелгә үткәзеп аңлата белә.

Кыз балага акыл бирүче – кырык, кырык беренчесе – чыбык, дигәне дә хәтергә уелып калган. Әбекәйне мисал итеп, Туган апа да сабак бирергә маһир: «Кара аны, әбиеңне ачуландырма! – дия. – Әштер-өштер эшләгән эшне сөйми әбиең. Берчак ашык-пошык кына идән сөртеп чыккан идем. Кулың җитмиме, почмакларга кермәгәнсең, диеп бидрәне тибеп аударды. Елый-елый, ышкып юам идәнне!» Акыл сатумы бу, кисәтүме – белгән юк. Югыйсә идән асты – авыл базы тулы бәрәңге. Әбекәй сулы чиләк аударыр идеме? Ышанмыйм. Әмма бу үзенчә тәрбия алымы булгандыр. Онытма, дип, гротеск эшкә җигелгән. Кызым, сиңа әйтәм, килен, син ишет, дип күперткән Туган апа. Авыл кешесенең яраткан ризыгы – токмачлы аш. Ә токмач басу, җәю, нәзек-нечкә генә итеп кисү осталык сорый торган четерекле эш. Эшкә өйрәткәндә әбекәй ипле йомшак теле белән ерактан уратып сөйләргә ярата: «Кыз бала – кеше кешесе ул. Үсәрсең, яратып кияүгә чыгарсың, кайнанаң, рәхмәтле бәндә булсын, һәр эшеңне күзәтеп, бәя биреп тора бит инде.
Кер юсаң да, аш-су әзерләсәң дә гаеп табу кыен түгел. Һай, бер дә эшкә өйрәтмәгән моны ни әбисе, ни әнисе, дисә, ояты безгә бит аның!»

Гомерлек һөнәр итеп язучы, журналист һөнәрен сайлавыма да әбекәйнең балачактан сөйләгән әкиятләре сәбәпчедер, мөгаен. Моңлы иде ул, эче тулы моң-зар булса да, кесә төбен чыгарып селки торган карчык түгел иде. Сугыштан кайтмаган улларын кызганып, сагынып зар елаганын хәтерләмим. Кышкы озын кичләрдә кабадан җай гына йон савасава, ә кайчакларда зырылдатып орчык биетеп туйгач, үзе дә сизмәстән, «җыру» сузарга тотына. Дәрес караштырган булып, чынлыкта китапханә китабын тизрәк укып бетерергә тырышып, янәшәдә утырам. Йөрәккә үтәрлек моң сискәндерә, ручка-каләм алам. Гомер ишетмәгән сүзләрен язып аласы иде. Әбекәй, кабатла тагын, дип ялынсам да, беркайчан да бер үк мөнәҗәт-җырны ике тапкыр көйләми ул. Күзен тутырып, аптырап карый: хәтерләми?! Сагышмоңнан яралган, гаҗәеп тирән мәгънәле җыру, көйле бәет-шигырь, мөнәҗәтләр үзәк бәгыреннән кайнап чыккан хис кенә бит. Халык иҗаты, җыр китапларын күпме актарып та, ул көйләгән җырларны тапмадым. Язып ала алмавым аяныч! Җаны, күңеле белән шагыйрә булган бит әбекәем!

Укый-яза белгәндер ул, һәрхәлдә, гарәпчәне таный иде дип гоманлыйм. «Йосыф» китабын яттан көйләгәне әле дә хәтердә. Елап тыңлаганым да истә.

Бик динле, намаз-ниязлы иде дип мактанасым килми. Күрсәтеп намаз укый торган заман түгел, атеизм, дәһрилек чәчәк аткан еллар бу. Үзең генә бел, дип, бисмилла, догаларны ул өйрәтте. Намазын да калдырмагандыр, шәт. Иелепбөгелеп укый алмый, бүсере зур. Пычак астына ятмыйм, дип, операциядән баш тартты. Ә уразаны калдырмавы хак, монысына үзем шаһит. Тәрәзәләргә калын пәрдә корылган, почмак якта чәй өстәле әзер. Ничек түзәсең, самовар җырлый башлауга, күземне ертып торып утырам.

Әбекәй сынап: «Түзәрсеңме? Уразага керү – бер хәер, бозсаң, гөнаһысы күп», – дияр иде. Мәктәптә, озын тәнәфестә, бала-чага авызына тәмле күмәч кисәге каптырып «ураза боздыручы» атеистлар бар иде. Кыңгырау чылтырауга, чыгып чабам. Кайтып, өйдә ашап киләм, янәсе. Сәкедә ике-өч минут утырып хәл җыям да дәрескә йөгерәм. Рамазан аенда ураза тоту... яшәү дигән сүзгә тиңдәш ул!

Замана балалары әбиләрен Дәү әни, Зур әни дия. Яшерен-батырын түгел, минекеләр дә дәү әни ди. Әниләрнең зурысы яки кечесе буламы?!

P. S. Әбекәйнең сурәте күңелемдә генә сакланган.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Кадерле Сөембикә редакциясе! Мин – өч баламның әнисе һәм алты оныгымның әбисе. Җанымны кая куярга белми бәргәләнгән бер мизгелдә:

Бер елыйсы иде үкси-үкси, / Җирне тырмап, кочып җиһанны... / Юк, ярамый, күз яшьләрем белән / Яраларымын газиз баламны... – дигән шигъри юлларны ак кәгазь битенә төшердем дә, уйга калдым. Узган ел минем өчен үзгә булды. Авыр димим, алай әйтергә ярамый, Аллаһы Тәгалә авыррагын бирер, диләр. Әмма бербер артлы килгән хәсрәтләр аяктан ега язды... Соңгысы – октябрь аенда улым Ленарның хуҗалыгында янгын чыгып, мизгел эчендә мал-мөлкәтсез, яшәр урынсыз калуы бигрәк тә ачы хәсрәт булды... Ялкын телләре кыска гына вакыт эчендә барысын да ялмап алды, тырыш хезмәт белән табылган бар нәрсә көлгә әйләнде... Балаларым, өч оныгым өстендәге киемнәре белән кыш алдыннан урамда басып калдылар... Күрәчәктер инде, балаларым, онykларым исән бит, дип Ходайга шөкер иттем. Ә эчтә ут кайный, әйтерсең лә янгын йөрәккә күчте. Урамнардан үтеп булмый, көннәр суык, башкаларның балалары җылы өйләрендә, ә минекеләр?! Ярый әле шәфкатьле кешеләр, ярдәм үзәкләре кием-салым белән булыштылар, балалар мәктәпкә йөри башлады. Улым да, килен дә, үз хәлләренә кайтып, эшкә йөриләр, Аллага шөкер! Ходай гомерләрен бирсен! Уй-хыяллары тормышка ашсын! Ә иң беренчесе, иң мөһиме – өйле булу! Халык «Өй салуның ние бар, чутлыйсы да, мүклисе», дисә дә, йорт салырга күпме чыгым кирәген чамалыйбыз, бигрәк тә бүген бәяләр чиксез күтәрелеп торганда. Бурасын әзерли башлады инде улым. Аны ничек өй итеп чыгар?! Ул өч бала кайчан үз өйләренә кайтып утырыр?! Ничек булышырга?! Бездә андый зур акчаларның булганы да юк, булмас та... Мин үзем биш китап авторы, Татарстан һәм Удмуртия Язучылар берлекләре әгъзасы булсам да, даими язып торсам да, минем керемем юк... Чарасызлыктан башлар чатный башлый, балага килгән авырлык иңнәрне ныграк баса, йөрәкне катырак телә шул...

Югаласы килә уралыплар / Су буенда ап-ак томанга... / Юк, ярамый! Балам ничек багар / Мин булмаган шыксыз дөньяга?!

Хөрмәтле редакция хезмәткәрләре! Сезгә язуым, күңелемне бушатуым өчен, ачуланмагыз, зинһар! Сезнең журналны укучылар арасында да шәфкатьле, мәрхәмәтле җаннар, игелекле затлар, яхшылык кылырга ниятләп йөрүче адәм балалары бардыр... Бәлки, балаларыма кемдер ярдәм кулы сузар?!

Мин сезгә Ленарның адресын, телефон һәм карта номерын җибәрәм. РТ Агрыз, ул. Ленина, 99. Асмандияров Ленар Мирзанурович.

Телефон: 8 965 62 04 251. Сбербанк картасы: 5336 6900 3101 0913.

Әлфирә НИЗАМОВА.
Әгерҗе районы, Исәнбай авылы.

Бала үстерү бик кыйммәткә төшә торган «рәхәт» хәзер. Хәер, ул беркайчан да җиңел булмаган.

Бүген бөтен нәрсәгә акчага гына корылган заманда, бала табыгыз, дип никадәр генә үгетләмәсеннәр, башында акылы булган кеше тагын берне алып кайтканчы, мең кат уйлый. Табу гына түгел, үстерәсе дә бар шул аларны. Кечкенә балалары булганнар балалар бакчасына түләүләрнең зурлыгыннан зарлана. Төрледән-төрле түгәрәкләр өчен дә түлисе. Атна саен әле спектакль, диләр, әле фокуснигы килә, диләр... Мәктәпкә кергәч, билне тагын да кысыбрак буарга туры килә. Китапдәфтәрләр, мәктәп формасы, шул ук спектакль-концертлар... Боларына юл чыгымнары да өстәлә.

Мин бер нәрсәне аңлый алмыйм: шәһәр транспортында йөргән өчен нигә балаларга бернинди дә ташлама юк? 7 яшьлек баланың акча эшләргә бармаганы билгеле ләбаса. Пенсионерларга да бар ташлама, ә менә балаларга һәм студентларга – юк. Әле без Казанга килеп, укырга кергән елларны шәһәр автобусларында йөрү өчен «школьный» һәм «студенческий» дигән айлык билет саталар, ул шактый арзан була тор-

ган иде. Ике меңенче еллар башыннан бетерделәр аны. Хәзер мәктәпкә баручы балалар да, студентлар да эшләгән кеше белән бер үк бәяне түләп йөри. Олы кешегә эшкә генә барып кайтасы, ә балаларга төрле түгәрәкләргә дә йөрисе бит әле. Гаиләдә ике бала мәктәптә укый һәм ул белем йортына транспорт белән йөрисе булса, әти-әнигә каравыл кычкырырга гына кала. Үзегез исәпләп карагыз: мәктәпкә бару-кайту өчен генә дә ике балага көн саен йөз сум акча кирәк. Ярый ла бер генә транспортка утырасы булса?

Укучы балаларга шәһәр транспортында ташлама бер бездә генә юк. Улымның класстташы узган ел Мәскәүгә укырга китте. Андагы студентлар безнекеләрдән «бәхетлерәк» икән, укучылар һәм студентлар өчен 395 сумлык юл картасы бар, шуның белән теләсә кайсы транспортта, теләсәң күпме йөри аласың, ди.

Моны ишеткәч, башка шәһәрләрдә ничек икән дип кызыксынган идем, баксаң, күрше өлкәләрдә дә андый ташламалар бар икән бит. Мәсәлән, Уфада транспорт бәясе кайсы оешманың автобусына утыруга карап, 18 һәм 20 сум булса, студентларга ул – 13, ә укучы балаларга 10 сум. Самарада да балаларны «кыерсытмыйлар»: укучылар өчен 560 сумлык айлык юл йөрү карталары каралган. Аларда олы кеше өчен транспорт бәясе быелның гыйнварыннан 28 сум булган. Укучыларга һәм студентларга исә 14 сум 60 тиен ясаганнар. Екатеринбургта да балаларга ташлама ясау мөмкинлеген таба алганнар. Аларда да укучы балалар өчен юл карталары ташлама белән сатыла. Аларда бар, бездә – юк. Югыйсә алар да, без дә бер үк илнең гражданнары.

Ләйсирә ЗӘЙНУЛЛИНА.
Казан шәһәре.

Яшел Үзән шәһәрендә гомер итүче Хәмдия апа Абдулхакова – Яшел Үзән районындагы туган авылым Бакырчыда якын күршебез.

Үземне хәтерләр вакытта ул инде тормыш корырга җыена иде. Җәйнең иң матур көннәрендә алып китте аны Ринат абый. Капка төбенә җыелган бала-чагага конфет чәчкәне әле дә күз алдында. Аннан аларның бер-бер артлы ике кызлары туды...

Хәмдия апаны бик белми дә идем әле ул вакытта, чөнки мин туганда инде ул 13-14 яшьлек үсмер кыз булган. Ә менә әти-әнисе Әхмәт абый белән Хәлимә апаны һәм әбисе Сара әбине яхшы хәтерлим. Сара әби гел безнең әбиебез янына керә иде (алар икесе дә дини гыйлемлеләр). Ике әбинең тыныч кына сөйләшеп утыруларын, бергәләп дисбе тартуларын, дини китапларын алмашып, фикер уртаклашуларын хәтерлим. Сара әби күчтәнәч итеп гел хөрмә җимеше алып керә иде. Аңа бу җимешне Мәскәүдә яшәгән кызлары җибәрә иде бугай. Әбием исә: «Балалар, бу – җәннәт җимеше», – дип, безгә дә авыз иттерә. Минем бүтән бервакытта да мондый тәмле җимеш ашаганым булмады кебек (балачак хатирәсе булганга микән).

Хәмдия апаның әти-әнисе гомер буе колхоз хезмәтендә булдылар. Тырышлык, хезмәт сөючәнлек аларның төп сыйфатлары иде. Авыл җирендә күршеләрең туганнардан да якын бит ул! Шырпың бетсә дә, утың сүнсә дә күршеләргә йөгерәсең. Авырлыгыңны да, кайгыхәсрәтеңне дә алар белән бергә күтәрәсең. Әти-әниемнең Әхмәт абый һәм Хәлимә апа белән (барысы да мәрхүмнәр, сүзем дога булып барсын!) бик тату яшәве күңелемдә якты хатирә булып саклана. Ялгыш кына да сүзгә килгәннәрен, берберсенә авыр сүз әйткәннәрен хәтерләмим.

Хәмдия апа тормыштагы авыр хәсрәтне беренчеләрдән күтәрде. Ире Ринат абый белән ун елга якын гына гомер итеп калды алар. Ринат абый яшьли гүр иясе булды. Тач әтиләренә охшаган кызларын җитәкләп, авылга кайтып йөрүләре күз алдында Хәмдия апаның. Ире вафатыннан бер ел узуга, кайнанасына бер-бер артлы инсульт була. Бала хәсрәте кичергән әни кеше урынга кала. Хәмдия апа 36 яшендә толлык ачылары кичереп, бүгенге көнгә кадәр егерме ел буе урындагы кайнанасын карый. Өстәвенә, әбидә әле шикәр чире дә икән. Әти-әнисен олы юлга озаткач, авылдагы төп нигезнең дә ел әйләнә җылысын сүндермичә саклый. Аны гөлбакчага тиң тота. Җәйге айларда кайнанасын алып, шунда кайта. Кызларын аякка бастырып, матур итеп кияүгә биреп, бүген дүрт оныгына дәү әни дә әле ул.

Берсендә мин аннан: «Каенсеңлегез әнисен беразга булса да алып китәме соң?» – дип сорашкан идем. «Былтыр бер-ике көнгә алып киткәннән соң, әнинең хәле авырайды, синең белән хушлашасы килә, дип, мине чакыртты. Казаннан Яшел Үзәнгә кайтып җиткәнче хәлсез әни күзләрен ачты. «Әнкәй, син мине күрүгә тереләсең икән», – дип көлгән идем. Хәзер менә, Аллага шөкер, ул көннән соң да елдан артык вакыт узды», – ди Хәмдия апа.

Хәмдия апа Абдулхакова лаеклы ялга чыкканчы «Серго» заводында хезмәт куйды. Илле бише тулуга ялга китте. Ял дигәне оныклары белән мәш килү, көннән-көн олыгайган авыру кайнанасын карау, җәй буе авылда җиләк-җимеш, яшелчә үстерү, нигезне яшәтү.

Хәмдия апаның бервакытта да төшенкелеккә бирелгәнен, зарланганын күргән юк, гел елмая, тормышны яратып яши. «Күршеләр, кайттыгызмыни, сез кайткач, күңелле булып китте», – дип, безнең дә күңелебезне күтәрә әле ул. Олы йөрәкле, сабыр, мөлаем Хәмдия апа мондый яшәү көчен каян таба икән дип хәйран калам.

Пар канатлы санаулы еллары ядкарен саклап, дистә еллар буена иренең әнисенә олы ихтирам күрсәтеп, чын хатын-кыз булып кала алган Хәмдия апаны «Иң олы йөрәкле хатын-кыз» дип, зур-зур сәхнәләргә менгереп, матур тапшырулар әзерләп, меңнәрчә кешеләргә үрнәк итеп күрсәтеп булыр иде.

Гөлназ ИСМӘГЫЙЛЕВА.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA

– Их, тор идең дә, китеп бар идең ул!.. Мәдинәнең иң зур хыялы бу. Ничә тапкыр уйлады икән инде ул аны? Бер сәгатькә ничә тапкыр, бер көнгә, бер атнага, бер айга? Ә шушы унике ел эчендә ничәмә-ничә мәртәбәләр кабатлавын санасаң? Өмет белән дә әйтелгәндер ул, әрнеп, ачынып, өзгәләнеп тә... Тирә-юньдәгеләргә ишетелерлек итеп кычкырып та, Ходайга гына барып ирешерлек итеп – эчтән генә дә.

ӨМЕТ КАТЫШ КӨТҮ

Гөлнур САФИУЛЛИНА

...Җәйнең иң матур вакыты, егерме дүртенче июнь була ул. Кемдер аша әтисе белән әнисенең икәү бакчага бәрәңге төбе өяргә чыкканнарын ишетә дә, апаларына ул көнне тизрәк хәбәр сала Мәдинә: «Кайтып, булышып килергә кирәк!» Кичке якта, дүртләр тирәсендә генә кузгалалар. Биектау район үзәгеннән аларның туган ягына – Теләче районы Олы Мишә авылына кадәр сәгать ярымлык юл. Күмәкләп тотынгач, бәрәңге бакчасын гөл итеп китәргә өлгерергә тиешләр. Иртәгә дүшәмбе – һәммәсенә дә эшкә.

– Кайтып җитеп булмады шул...

Алар утырган машина Пановка авылы янында юл читенә төшеп каплана. Аңарчы өч тапкыр әйләнергә өлгерә. Саклану каешын эләктермәгән Мәдинә машина тәрәзәсеннән очып чыга. Бу юл фаҗигасенең шаһитлары аның туп шикелле җиргә бәрелә-сугыла тәгәрәп барып, ниһаять, туктавын күргәч: «Аһ!» – дип куйганнардыр.

– Унике метр читкә тәгәрәгәнмен... Ул минутларда бөтен тирә-юнемне ап-ак итеп хәтерлим. Аннан туктадым. Сулап булмый! «Ничек тә сулый башлыйсы иде!» – дип ятканым истә. Сулап җибәрдем... Рәхәт булып китте... Ул арада кеше җыелды. «Тора алмыйм, булышыгыз әле!» – дим. Ал футболка кигән бер хатын: «Кагылмагыз! Аны кузгатырга ярамый!» – дип, барысын да туктатты. Икенче машинадагы апалар, тәгәрмәч тишелеп, аны алыштырырга тукталып, арттарак калган иде – алар килеп җитте. Барысы да елый. Нишләргә белмиләр...

«Ашыгыч ярдәм» машинасы аны Питрәч районы үзәк хастаханәсенә алып китә. Иң беренче караудан, беренче рентгеннан соң ук кизү торучы табиб: «Сеңлем, без сиңа булыша алмыйбыз, Казанга озатабыз», – ди. Кабат «Ашыгыч ярдәм» машинасына күтәреп чыгалар. Мәдинә җыр

суза: «Сау булыгыз, дуслар...» Аны озатырга чыккан хирург: «Бу ханымны аякка бастырмасак, гөнаһ булыр», – ди...

– Авырту сизмәдем... Умыртка баганасы сынгач, аяклар шунда ук тоймаска әйләнгән...

Башта бер операция ясыйлар: умыртканың меңгә чәрдәкләнгән ике баганасын берәмтекләп җыялар. Бер атнадан кабат хирург пычагы астына яткызалар: вакытлыча гына куелган пластинаны алыштыралар.

– Мин бик сабыр кеше. Авария булгач та, операцияләргә кадәр дә, аннан соң да сыңар күз яшемне дә чыгармадым. Янымдагы кешеләргә авыр булмасын дип тырыштым.... Аларның берсенә дә еларга рөхсәт итмәдем: «Өстемә карап күз яше түгеп тормагыз», – дидем. Авыру кешене кызганырга, жәлләргә ярамый аны. Югыйсә җебеп төшәргә дә озак түгел. Якыннары шундый авыр хәлдә калган кешеләргә мин гел бер сүзне кабатлыйм: «Иң яхшысы – игътибарын читкә юнәлтергә тырышыгыз», – дим...

Елауны ул соңракка калдыра. Өйгә кайткач, ялгызы булганда. Кеше юкта...

Ике аякның икесе дә аны тыңламаска әйләнә. Туры да басасылары килми, атлап китәселәре дә... Ә йөрергә кирәк! Барысы да истә... Палатада бер караваттан икенчесенә кадәр булган беренче өч адым. Аннан – беренче тапкыр коридорга чыгу. Ун адым булдымы икән ул, әллә унбиш үкме? Ике яктан ике кешегә тотынып, чакрымнарга сузылган ул адымнарның бер ягына барып җиткәч: «Инде ничек кире кайтырга?» – дип куркып калу. (Сер дә бирәсе килми бит әле!)

– Аяксыз калдым дип беркайчан уйламадым. Әле дә ул уйны башыма кертмим!

Ул хастаханәдән чыкканда август ахыры була инде. Култык таяклары белән көчкә өйгә узган Мәдинәне кызлары Динара белән Эльмира: «Кайтуың белән, әни!» дигән зур плакат язып каршы ала. (Мәдинә ирексездән чыккан күз яшьләрен сиздермичә генә сөртеп ала: «Алар бәхетенә исән калганмындыр...») Икенче көнне кызлары – укырга, ире эшкә чыгып китә. Өйдә берүзе генә кала.

Мәдинәнең ул көннениләр кичерүен күз алдына китерү кыен түгел.

Ул – Биектау Мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе. Үзе дә сәхнәдән төшеп тормый: бии дә, җырлый да. Гел халык арасында, гел уртада. Аңа нибары 40 яшь.

– Күрәчәк арттан этә, диләрме әле? Мин ул елны ашыгып, ашкынып эшләдем. Хәтта үзем дә моны сиздем. «Хәерлегә булсын», – дип тә әйткәләдем... Аерым бер участокта бакчабыз бар иде. Ул язны шул бакчаны берүзем казып чыктым. Зөфәр кич эштән кайткан да шалтырата: «Син ашарга кайтасыңмы соң бүген?» – ди. «Белмим шул... Монда бераз гына калды», – дим. «Ничек бераз гына калды?» – дип аптырады ул. Казыганмын да казыганмын, үзем дә сизмәгәнмен. Өлгереп калыйм дигән кебек эшләдем...

Һәм болар барысы да үткәндә кала. Ул – дүрт стена арасында. Читлектә дисәң дә була... Ә алда... Анда ни

«Син гомергә шулай калдыңмы?» – дип сорап, җанны телгәләүчеләр бар.

булыр? Нәрсә көтә аны? (Дөрес, эшенә чакырып киләләр. «Килеп алырбыз, китереп куярбыз – ярты көнгә булса да ризалаш», – диләр. Зөфәре: «Шушы хәлендә Мәдинәне ире эшкә чыгарган дип әйтерләр», – дип каршы төшә. Кеше арасында җиңелрәк булыр, хәсрәте онытылыр, дип уйламагандыр инде... («Хәер, үземә дә ышанып бетмәдем», – ди Мәдинә.)

Моңарчы дус дип санап йөргәннәрнең барысы да диярлек томан кебек эреп юкка чыга. (Сиңа килгән сынау кайчак шулай тирә-юнеңдәгеләрне дә сыный!) Дөнья бер бүлмә белән чикләнә. Чакрымнарны адымнар алыштыра.

Яңача яшәргә өйрәнергә кирәк була.

– Көне буе өйдә берүзем. Ашыйсы килгән чак та була. Халат кесәсенә ике йомырка салам да, плитәгә китәм. Суыткыч янынннан кире әйләнеп килгәнче, йомырка пешеп чыга... Коляскага утырмадым. Бер хезмәттәшем өр-яңаны алып килгән иде. «Мин гарип түгел! Алып кит! Күзем күрмәсен!» – дидем.

Ә бер көнне бер йомыркадан гына токмач җаеп карарга булдым. Кызлар: «Әни, кайчан үзең пешерә башлыйсың инде? Синеке тәмле була иде», – диләр. Балаларны сөендерәсе килә бит... Басуын бастым, инде ничек кисәргә? Хәзер әнә берьюлы җидешәр йомыркадан баскан чакларым бар... «Ай Аллам, кайлардан тотындым?!» – дидем ул чакта.

Гел бер бүлмә буйлап кына әрле-бирле йөрү бик туйдыра, ялыктыра. Беренче тапкыр кызлар бүлмәсенә кадәр барып җиткәнемне онытмыйм. Бусага аша аягымны күтәреп кερә алдым. Шундый зур вакыйга булды бу! Ул бүлмәдәге тәрәзәдән бакча күренә. Карадым да, кычкырып-кычкырып еладым. Җирдә эшлисе килә... Җир җимертеп эшлисем килә!

«Беренче тапкыр»лар ул чакта бихисап була.

Беренче тапкыр идән юып карау. Чиләккә берничә генә чүмеч су сала да, тәвәккәлләп тотына. («Берзаман артыма борылдым да: Һай, бигрәк күп бит әле. Ничекләр бетерим икән?» – дим».)

Беренче тапкыр тезләнеп түтәл ясап карау. Йөрәк түзми! («Монысы бер ел узгач булды. Тезләрем кичкә кызарып шешеп чыкты ул көнне».)

– Әни шалтырата да: «И-и, сызланасыңдыр инде, балам...» – дия иде. «Минем бит бер җирем дә авыртмый, әни, аякларым гына йөрми», – дим. Телефонны куям да, елыйм аннары... Үзем генә калганда елау һәм җырлаулар күп булды инде... Без Зөфәр белән Мәскәү янында яшәгәндә таныштык, шунда өйләнештек. Балалар анда туды. Ул – Битаман авылыннан. Туксанынчы елларда анда завод ябылды, эш бетте дә, туган якка кайттык. Зөфәр шуннан бирле Казанга

Фото: Анна Арахамия

Хәлемнең ниндилеген читләргә түгел, кайчак өйдәгеләргә дә белгертмим.



Мәдинәгә әлегә гел таянырга кирәк: йә таякларга, йә якыннары иңенә.

барып эшләп йөрде. Бөтен тормыш үз өстемдә иде. Мин бу хәлгә тарыгач, Зөфәргә Казандагы эшеннән китми чара калмады.

Иң авыр чакта якыннарыңа таянасың: иреңә, балаларыңа, әти-әниеңә, туганнарыңа... Мәдинәнең дә төп ышанычы гаиләсе була. Килене фаҗигагә юлыгуга кайнанасы Фидания: «Ташламыйсың! Мәдинәнең үзен генә калдырмыйсың!» – ди улына.

– Зөфәр мине болай да ташлап китмәс иде. Тәрбиясе башка аның... Өч ай саен реабилитация үзәкләренә дәваланырга йөри башладым – кызлар гел әтиләре белән калды. Анда ятканда нинди генә язмышлар белән очрашмадым. Ташлыйлар... Ирләр – хатыннарын, хатыннар – ирләрен... Гөлназ белән танышканда, мәсәлән, ул әле аягын шудыртып кына йөртә иде. Машина бәреп киткән аны. Зөфәр мине ялга гел өйгә алып кайта иде. Бер шулай ялдан соң өйдән килсәм, Гөлназ: «Ә мин таягымны ташладым! Иремә әйтмәдем әле – сюрприз ясыйм!» – ди. «Әйт, ул да сөенсен! – дидем. – Үзеңә сюрприз ясый күрмәсен». Кайдан телемә килде, дип, соңгы җөмләм өчен бик үкендем. Гөлназ соңыннан өеннән шалтыратты: «Синең сүзең дөрескә чыкты. Башта мин йокларга ятмыйча өйгә кайтмый башлады. Инде менә ике бала белән әниләргә үк китереп куйды», – ди.

Һәрчак терәк булырдай ахирәтләрен ул тернәкләндерү үзәкләрендә таба (Монда һәрберсе синеке кебек кайгыны үз башыннан кичергән – алар сине бөтен кешедән яхшырак аңлый. Мамадыштан Гөлфия – шундыйлардан. Аны исерек килеш участковый бәрдерә. Юлда да түгел, тротуарга чыгып!); ә кемдер өчен үзе терәккә әйләнә (Яшел Үзән егете Әмир аны әле дә яхшы хәтерлидер. Чыгарылыш кичәсе көнне юл фаҗигасенә очрап имгәнгән бу яшь егетнең өметсезлеккә бирелүен, берни эшләргә теләмәвен ишетеп калган Мәдинә апасы аны сискәндереп, уятып җибәрердәй сүзләр таба. «Гомерең буе коляскада утырып калырга телисеңме-ни?» – ди. Соңрак Әмирнең баскычтан үзе менүен күрү искиткеч зур шатлык була!)

Унике ел. Бу елларның һәрбер көне яшәргә тырышып, «менә бүген», «менә иртәгә әйбәтрәк булачак» дип узган.

Беренче тапкыр таяксыз басып тору. Бик аз – бер генә минут! Әмма тотынмыйча! Ул көнне кичергән шатлыкның зурлыгын үзе генә белә – шуңа онытмый.

Таш кебек авыр тоелган аякны күтәрергә өйрәнү. Моның сөенечен аякта йөргәннәргә аңлатып буламы?!

Аннан иренең кул арасына керүләр башлана. Өйдәге эшләрне эшләү турында әйтмим әле – алары шулай тиеш кебек бит аның. Иркәләнү, мескенләнү аның холкында түгел. Ничек тә акча эшләргә омтылуын искә төшерүем. Берничә ел элек сабын кайнатырга өйрәнә: мәшәкатьле эш, әмма бәйрәмнәрдә сатыла бит! Сату дигәннән, нәрсәгә генә алынып карамый ул: косметика да сата, савыт-саба да, дару үләннәре дә... Зөфәренә җиңелрәк булсын дип тырышуы. Дәва эзләп кая гына мөрәҗәгать итсәләр дә, барысы да акчага барып төртелә бит. Дикуль үзәгеннән: «Әйе, сез безнең пациент. Килегез, көтәбез!» – дигән җавап килгәнгә дә инде ун елдан артык. Анда бер ай дәвалану 325 меңнән артык торганын белгәч, бу уйдан шунда ук баш тарта Мәдинә: аякка басу өчен үзәктә ким дигәндә ярты ел ятарга дигәннәр – ул кадәр акчаны кайлардан аласың?

Ә вакыт бара. Сәхнә костюмнарын таратып бетерсә дә, үкчәле туфлиләре тора аның. Көтәләр... Иң зур хыялы һаман да шул – таяксыз йөрү. Элеккегечә йөрү. Соңгы вакыт күңелендә тагын бер өмет кабынган менә: диагнозы язылган документларны Кытайга җибәргән булганнар. Андагы табиблардан хәбәр инде килгән. Вакыт бик күп узган, терелергә өмет 10 проценттан артык түгел, дигәннәр. 10 процент! Мәдинәгә аның берсе дә җитәр иде! Әгәр барып булса, әгәр өч йөз мең акча тапсалар... Юк, алты йөзне! Нинди дер нәтиҗәгә ирешү өчен ике ай дәваланырга кирәк, дигәннәр бит. (Төшендә ап-ак самолетка утырып очуын ул үзе шушы сәфәргә юрый!) Ә нигә аңа шушы могҗизаны бүләк итүче кеше (яки кешеләр) табылмаска тиеш әле?!

...Алар өенең сайгаклары йорт хуҗаларының аяк тавышларын, әлбәттә, күптән таныйдыр. Динара белән Эльмираның буй җитеп, туып-үскән ояларыннан инде канатланып очуын да белеп торалардыр. Соңгы вакыт өй тутырып тыпыр-тыпыр ике оныкчабып йөрүенә сөенәләрдер. Мәдинәнең кайбер көнне сөяп куйган култык таякларына карап, уенын-чынып кушып: «Иртәгә кагылмыйм мин сезгә! Торам да йөреп китәм!» – диюен дә ишетәләрдер. Төшләрендә үзенең йөгерүен, биюен күрүе дә сер түгелдер. Алар да көтәдер... Хуҗабикәнең бер бүлмәдән икенчесенә җил-җил атлап, тиз-тиз басып узуын көтәдер. Биегән кебек итеп кенә!

АТА-АНА ХАКЫ ДИП...

Замирә РӘҖӘПОВА-КУПРИЯНОВА, сценарист, режиссер, телевидение хезмәткәре

Монда һәркем үзенчә хаклы кебек. Әни кешенең бала алдында хакы зур, ул аны табып үстерә, тәрбияли. Икенче яктан, ирне дә аңлыйм. Ул бернинди дә начарлык эшләми, үзенең бурычын үтәп, ата-анасының хәлен белергә генә бара. Өченче яктан, хат авторын да аңларга була. Иренең әти-әнисе алдында гына түгел, балалары алдында да бурычы бар бит. Әни кешенең хакы ничек кенә зур булса да, бу очракта ул хаксызлык күрсәтә. Үз хакын хаклатып, атна саен килүен сорап, баласына авырлык тудыра. Аның мондый шартлар куюы баласының хокукларын чикли, минемчә. Улының бит башка вазыйфалары да бар. «Киләсең!» – дип фәрман биреп, ирeген чикләп, әни кеше аны хатыны алдында кимсетә дип уйлыйм. Кеше сүзе белән йөргән ирне безнең халык җебегән, дип атый. Әни янында рәхәт, билгеле, ләкин бу дөньяда башка төрле рәхәтлекләр дә бар бит әле. Шул ук гаилә белән киного бару, әби-бабай янына кайту... Баласын чынлап яраткан әни үзе үк: «Улым, кодагыйларга да кайтыгыз, гаиләң янында бул», – дияр иде. Ирнең әнисе сүзен тыңлавы да күбрәк тавыш чыгудан курыккангадыр, мөгаен.

Ирем белән гаилә коруыбызга 15 ел. Ул – Казан егете, әти-әнисенә бер кыз, бер малай үскәннәр. Өйләнешкән генә елларда алар белән бергә яшәдек. Үз фатирыбызга күченеп яши башлауга ук кайнанам шарт куйды: һәр шимбә-якшәмбене ирем алар янында уздырырга тиеш икән. Менә инде ничә еллар шимбә җитсә, иртән торып җыена да, әти-әнисенә чыгып китә. Югыйсә алар әле җиргә җиткән карт белән карчык та түгел. Ара-тирә балалар белән мин дә ияреп барам. Кайчак ачуым да килә: ял көннәрендә бергәләп кибетләргә чыгасы була, балаларны каядыр алып барасы...

Н. ХӘКИМОВА.
Чаллы шәһәре.

Исрафил НАСЫЙБУЛЛИН, «Арча хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире

Мин бу мәсьәләгә дин күзлегеннән карыйм. Үземнең дә кызым һәм киявем бар. Кызым кияүгә чыкканда ук кисәтеп куйдым: «Кызым, хәзер син ир хатыны, аның сүзеннән чыкма. Һаман безгә кайтыйк дип тә тинтерәтмә, ирең ягына кайтырга тырышыгыз», – дидем. Кияү – күрше авыл егете. Аллага шөкер, үзләренә кайткач, безнең дә хәлне белеп чыгарга өлгерәләр.

Шәригать буенча, хатын-кызга үз әти-әнисенең хәлен белергә бару өчен иренең рөхсәте кирәкми, ул бу турыда хәбәр генә итәргә тиеш. Бу аның хокукы һәм бурычы. Әти-әнисенә ярдәм итеп, ир кеше дә үз бурычын үти. Никахка кадәр ата-ана өстендә бала хакы була. Никахтан соң бу хак бетә, балага әти-әнисен кайгырту бурычы йөкләнә.

Безнең халыкта бер ялгыш фикер яши, киленне кайнана белән кайнатага хезмәт итәргә бурычлы дип саныйлар. Ләкин алар аны тудырып үстермәгән, киленнең аларга бурычы юк. Хөрмәт йөзеннән булышса, савап була, булышмаса, гөнаһ түгел. Ул үз әти-әнисенә генә бурычлы. Ләкин атна саен бездә бул дип шарт кую дөрес түгел. Баланың хәзер үз гаиләсе бар, һәм үз гаиләсен кайгырту да аның бурычы бит. Монда тигезлек кирәк.

Белгеч фикере




Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

Моны шарт кую дип әйтү дөрес үк булмас, килешү дисәң, дөресрәктер. Ә аны үзгәртергә мөмкин. Моның өчен үзара килешә белергә кирәк.

Ял көннәрендә әти-әнинең улларын үзләренә чакыру таләбе кайдан килеп чыкканын ачыклау мөһим. Бәлки, үз әти-әниләренә ярдәм кирәк булганга, аларда шундый гадәт урнашып калгандыр. Шунлыктан үз уллары да ял көнен алар янында уздырырга тиеш дип саныйлардыр. Әмма улларының инде үз гаиләсе бар, һәм аның балалары да ялларын әтиләре янында үткәрергә мохтаҗ. Бу очракта килен кешегә үз ихтыяҗларын дөрес итеп белдерергә кирәк. Әгәр аларны белдерергә өйрәнмибез икән, без үз-үзебездән корбан ясыйбыз. Әле монда киленнең генә түгел, балаларның да ихтыяҗы бар бит. Бу хәл аларның да тәрбиясендә чагылачак.

Бәлки, ике гаилә, үзара килешеп, бер атнаны яшьләр кунакка барса, икенче атнаны әти-әниләр үзләре килер. Гадәтләрне үзгәртергә була, аның өчен 21 көн вакыт җитә. Өлкәннәргә ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтү балалар өчен дә яхшы үрнәк булачак. Иртәме, соңмы, игелек орлыгыннан миһербан шытып чыга.



ҖИЗ КЫҢГЫРАУ, КӨМЕШ МОҢНАР...

Менә ничә еллар инде Илфак Смаковның көмеш тавышы минем күңелемдә көмеш кыңгырау шикелле һаман чыңлап, бертуктаусыз яңгырап тора. Күңелемне иләсләндереп, моңландырып, үткәннәремне, бигрәк тә яшьлегемне сагындырып чыңлый. Аның яңгыравыклы тавышы, оптимистик хисләр белән сугарылган дәртле җырлары һич кенә дә картаерга ирек бирми, күңел кылларын тибрәндереп җибәрә, җанга яшьлек рухы, яшьлек дәрманы өстәп тора...

Мин аны беренче тапкыр якыннан 1968 елны үзебезнең Илеш районы үзәге Югары Яркәйдә күрдем. Февраль ае иде микән, Илештә әдәбият һәм сәнгать көннәре узды. Мин ул чакта район газетасында корреспондент булып эшләп йөрим. Районыбызга бик күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләре килгән иде. Алар башта төрле төркемнәргә бүленеп, авылларда халык белән аралаштылар, очрашулар уздырдылар. Безнең илешләр шартын китерә белә инде: кунакларыбызны авылдан авылга чигүле сөлгеләр белән бизәлгән, кыңгыраулар таккан шәп атлар җигелгән кошевкаларга гына утырып йөрттеләр. Кайда да бәйрәм тантанасы, бәйрәм рухы, ниндидер иҗади күтәренкелек!.. Бөтен район шушы дулкында!

Иң соңгы көнне район мәдәният йортында йомгаклау кичәсе булды. Менә шунда беренче тапкыр атаклы «Җиз кыңгырау моңнары» яңгырады инде. Кунаклар арасында ул елларда ук иң популяр шагыйрьләребезнең берсе, сәхнәгә чыгып басу белән тамашачыны авызына каратып тота торган Әнгам Атнабай, ул чакта иң күп җырлана торган «Раушания» җырының авторы – үзешчән композитор Васил Хәбисламов

Җиз кыңгырау моңнары

Урап-урап карлар күмә
Кышның озын юлларын,
Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.

Җиз кыңгырау, көмеш моңнар
Уйлата синең хакта,
Синең хактагы уйларым
Яшьлеккә алып кайта,
Уйлата синең хакта.

Җиз кыңгырау моңнарында
Үткәннең тавышлары,
Очрашулар, кавышулар,
Аерылу сагышлары,
Үткәннең тавышлары.

Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.
Кая алып бара икән
Кышкы озын юлларым?

Җиз кыңгырау тагып кына,
Атларда чабып кына,
Килер идем яшьлегемнән
Тик сине алып кына,
Атларда чабып кына.

та бар иде. Алар Илеш авылларында тик кенә йөрмәгәннәр, кунак булудан тыш, өр-яңа шигырь һәм өр-яңа көй дә чыгарырга өлгергәннәр икән. Сөн, Агыйдел буйларын иңләп, Кыргыз авылыннан күрше Ябалакка, ягъни «Агыйдел» колхозыннан «Искра» җирләренә карлы юллардан кыңгыраулы атларда юыртканда, шагыйрь, илһамланып, «Урап-урап карлар күмә / Кышның озын юлларын» дип кабатлый, композитор күңелендә инде җиз кыңгырауның көмеш моңнары чыңлый башлый. Шул шигырь белән көйнең бергә кушылу мизгеленең шаһиты булырга, өр-яңа «Җиз кыңгырау моңнары» җырының беренче тапкыр яңгыравын ишетергә насыйп булды миңа. Әле дә хәтеремдә: иң элек Атнабай кызыклы комментарийлар белән үзенең яңа шигырен укып җибәрде. Шигырьне укый белә иде инде! Зал алкышларга күмелде. Аннары Вәсил Хәбисламов баянда үзенең яңа көен сыздырып җибәрде. Шуннан соң сәхнәгә Илфак Смаковны чакырдылар. Ул инде, яшь булуына да карамастан, халыкның иң яраткан җырчыларының берсенә әйләнгән иде. Башкортстан радиосыннан аның җырлары яңгырамаган көн булмагандыр. Концертларына тамашачы зал тутырып килә. Илфак җырны башта әле кулына Атнабай тоттырган кәгазьдән карый-карый гына җырлады. Ул җырлап бетерүгә зал тагын алкышларга күмелде. Алкышлар тиз генә тынмады, шуңа күрә җырны ул икенче тапкыр башкармыйча булдыра алмады. Дөресрәге, тамашачылар сорап җырлатты. Халыкның да, авторларның да, әлбәттә инде, Илфакның үзенең дә күңеле булды. Бу – Илфак өчен генә язылган җыр кебек иде. Бу – татар һәм башкорт эстрадасында өр-яңа үлемсез җыр туган тарихи минутлар иде...

Шул ук елны мин Казанга укырга киттем. «Җиз кыңгырау моңнары» җитезрәк булып чыкты. Мин барганда радиодан, сәхнәләрдән ул бөтен көчкә яңгырый иде инде. Һәм ул безнең, студентларның, иң яраткан җырына әверелде. Ә мин инде, җае чыккан саен, дус-ишләремә ул җырның туу тарихын, аның беренче тыңлаучысы булуым турында зур горурлык хисләре белән сөйләргә ярата идем.

Дүртенче курсны тәмамлаганда, укытучыбыз, шагыйрь Мостафа Ногман безне, бер төркем студентларны, практика узарга дип Үзбәкстанга алып китте. Ташкентта, Сәмәркандта, Бохарада булдык, тарихи истәлекләр белән танышып йөрдек. Ләкин минем өчен иң истә калганы – Илфак Смаков белән очрашу, якыннан танышу булды. Нәкъ без Ташкентта йөргән көннәрдә Башкортстан филармониясе артистларының гастрольләре иде анда. Бөтен Ташкент буенча аларның игъланнары эленгән. Мин инде, якташлар да булгач, ничек тә шул концертка бару ягын карадым. Сабакташларны да, җитәкчебез Мостафа аганы да күндердем: ничектер керү җаен да таптык, соңыннан сәхнә артына кереп, якташларга рәхмәт тә әйтеп чыктык. Ә концерт барыбызга да ошады. Илфакның бигрәк тә «Җиз кыңгырау моңнары»н башкаруы күңелемә май булып ятты. Аның белән якташларча җылы итеп күрештек, җырларын күптән яратканымны да җиткердем, «Җиз кыңгырау моңнары»н ничек итеп беренче тапкыр җырлавын да исенә төшердем. Ул да бик канәгать булып калды булса кирәк. Шушы очрашудан соң сабакташлар алдында минем абруй тагын да күтәрелеп китте, билгеле. Ә инде Ташкент дәүләт университетының тулай торагына кайткач (безне шунда урнаштырганнар иде), концерт турында бик озак сөйләшеп утырдык, «Җиз кыңгырау моңнары»н да бергәләшеп җырлап утырдык. Ерак Үзбәкстанда үзебезнең милләттәшләребезне күрү, үзебез радиодан тыңлап хозурланган җырчыларыбыз белән очрашу, әлбәттә инде, күңелләрдә матур хисләр уяткан иде...

Моннан берничә ел элек Башкортстан авылларында очрашуларда йөргәндә Тәтешле районындагы Иске Күрдемгә – Атнабай туган авылга да кердек. Машинада авылга якынлашканда, юлдашларыма «Җиз кыңгырау моңнары»ның туу тарихын сөйләдем. Арабызда Илшат Сибгатуллин дигән яшь җырчы да бар иде. Ул искиткеч тавыш белән яраткан җырыбызны җырлап җибәрде...

Заманында җырны Сөләйман Йосыпов, Илһам Шакиров кебек мәшһүр җырчыларыбыз да яратып башкарды.

Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең Илфак Смаков башкарган җырларны, шул исәптән, «Җиз кыңгырау моңнары»н яратып тыңлаганын белә идек инде. Үзенең 80 яшьлек юбилей тантанасына Минтимер Шәрипович хатыным Клара белән мине дә чакырды. Филүс Каһиров анда җаннарны айкап, күңелләрне кузгатып, әлеге үлемсез җырны башкарды.

Ярты гасыр элек язылган булуга карамастан, җыр һаман яшь, ул һаман популяр.

Роберт МИҢНУЛЛИН,
Татарстанның халык шагыйре.

«ХӘЯТЕМ...»



Мин нигәдер бу тарихны алар яшәгән фатирның балконында тыңлармын дип уйлый идем. Әнкара күгендә ай йөзә, кайсыдыр күршенең ачык тәрәзәсеннән әкрен генә төрек көйләре яңгыраганы ишетелеп тора, ел әйләнәсе балконнарын яшеллеккә күмеп утырган гөлләренең берсе чәчәк аткан... Өстәлдә хуш исле үлән чәе. (Мәтрүшкә дә кушканнар түгелме?) Әйе, әйе, нәкъ менә шулай булырга тиеш иде. Әмма Казан белән Әнкара арасы алай ук якын түгел: бер сөйләшү өчен генә чыгып китеп булмый. Аннан вакыт та уза! Төркия башкаласына юлларым кайчан төшәр, анысын белмим, үз ярын көтеп яшәгән күпме җаннарда исә өметне бүген үк уята алам бит. Шуңа күрә башлыйм...

Гөлнур САФИУЛЛИНА

...Тормышта бернәрсә дә очраклы гына түгел. Бүген икесе беравыздан: «Гап-гади бер котлау иде ул», – дисәләр дә, иманым камил, алай булмаган. Күкләрдә сәгать суккан!

Фейсбукның, һәркем белән кайчан дуслашуыңны искә төшереп, елга бер котлап ала торган гадәте бар. Бигрәк тә ул кеше белән ара-тирә аралашкаласаң да. Ә аларның моңарчы «сөйләшүләре» бәйрәмнәрдә Төркия ягыннан котлаулар килүе, ә Гөлнараның аларга кыска гына итеп: «Рәхмәт!» – диюеннән узмый. (Дөрес, озынрак бер-ике җөмлә була булуын. Наил үзенә дуслык тәкъдим иткәч, Гөлнара: «Мин чит кешеләрдән, гадәттә, дуслык кабул итмим. Тик исемегез җәлеп итте бугай, сез татар түгелме?» – дип сорый. Наил: «Юк», – дип җавап бирә. Гөлнара кызы Бануның туй фотосурәтләрен куйган көнне, Наил: «Бигрәк матурлар! Бәлки безгә дә бирәр татар кызы насыйп булыр әле...» – дип яза. Гөлнара аның ни әйтергә теләгәнен аңламаганга сабыша. «Мин ун ел элек хатыным белән аерылыштым», – дип өсти Наил.) Фейсбук: «Дуслашуыгызга бүген бер ел!» дигән көнне дә Наил аңа: «Котлыйм!» – дип яза. Җавап озак көттерми: «Һай, бигрәк зур бәйрәм икән!» Бер сүз, ничектер сиздермичә генә, икенчесенә ялгана... Башлана!

– Гөлнараның Фейсбуктагы битендә Төркия фотосурәтләре бик күп иде. Иң элек шуңа игътибар иттем бугай. Нигә минем туган илемне бу кадәр ярата, якын итә икән дип уйлавым, сәбәбен беләсе килүем табигый бит...

Гөлнараның Төркиягә булган мәхәббәте безгә – аның дусларына беркайчан сер түгел иде, билгеле. Ул ел саен бер тапкыр булса да Истанбулга бара, көннәр буе аның урамнары буйлап йөри, Босфор ярында утыра, диңгез тавышын тыңлый, акчарлакларлар ашата... Төрек телен дә ул үзлегеннән өйрәнде. «Сәфәремнең иң беренче көнендә үк төрекчә китап сатып алам. Кире кайтып киткәнче, шуны укып чыгарга тырышам. Булыша!» – дия иде ул. (Казан дәүләт педагогика институтының чит телләр бүлеген тәмамлаган кешенең яңа телләр өйрәнергә сәләте булуы гаҗәп түгел инде анысы.)

– «Фейсбукның мессенджерында аралашу минем өчен җайсызрак. Ватсап номерыгыз бардыр бит, бәлки шуны бирерсез?» – дип язды Гөлнара беркөнне миңа. Аптырап калдым. «Телефон номерымны сорый... Димәк, ул мине дөрес аңламаган. Аңа карата бернинди ниятем дә юк бит», – дип уйладым. Берничә көн язмый тордым. Ә ул үзе башлап беркайчан язмый иде. Шушы бушлык вакытында нидер булды... Әчтә – күңелдә, җанда... Ике арага ничек күперләр салынганын – күңелләр тоташканын аңламый да калдык...

Бүгенге заманның ерак араларны якынайту мөмкинлекләре чиксез: башта Гөлнара белән Наил ватсап аша аралашалар, аннан телефоннан бер-берсенең тавышларын ишетәләр, скайп аша сөйләшүгә күчәләр...

Озак уйлансаң, бу адымны ясап булмый, **без тәвәккәлләдек.**

– Наил иртән эшкә кузгалганда: «Киттем», – дип яза, кич ишегән ачып керүгә: «Мин өйдә, кайттым», – дип хәбәр итә. Көндез эш белән кайда булган, кемнәр белән очрашкан, дуслары белән кая барганнар, туганнары гаиләсендә кайсысында нинди яңалык бар – барысын белеп торам. Кызык һәм сәер халәт иде бу... Без бит әле бар тапкыр да күрешмәгән!

Һәм болар барысы да нибары бер ай эчендә була!

Гөлнара ул елны да гадәттәгечә Истанбулга барырга җыена иде.

«Ә синең Әнкараны күргәнең бармы соң?» – дип ерактан сүз башлый Наил. «Юк», – дигәнне ишетүгә: «Ике кала арасы ерак түгел бит, бәлки, килерсең? Мин сиңа шәһәрне үзем күрсәтер идем», – дип дәвам итә.

– Кемдер минем ул чакта барырга ризалашуымны башсызлык дип тә уйларга мөмкин, – дип елмая Гөлнара. – «Бу яшьтә», диярләр. Чыннан да, читтән караганда, бәлки, җилбәзәк булып та күренәмдер. Әмма тормышта кайчак тәвәккәлләргә дә кирәк...

Наилнең ватсаптагы хәбәрләре рәсемнәр белән аралаша.

«Бу сөлгеләрнең сиңа кайсысы ошый? Нинди рәсемлесен алыйм?»

«Халат сайлый идем... Нинди төслесенә тукталыйм икән?»

«Люстра алырга чыккан идем... Менә монысы салонга матур булырмы?»

«Булыш әле... Блендерның менә бу зуррагы әйбәтме икән, әллә кечерәгеме?»

– Без якыннан аралаша башлаган көннәрдә, яңа фатирына күченеп йөри иде ул. Кая, нинди җиһаз алырга җыенса да, башта минем белән киңәшләшә: «Кайсысын сайлыйм?» – ди. Дөресен әйтәм, бу гадәте шактый гаҗәпләндерде. Нигә миңа бөтен тормышын күрсәтергә җыена соң ул? Мактанчыграк кешеме әллә дип тә уйлап куйдым. Алай дисәң, башка вакытта бу нәрсәне сизмим. Фатирына барып кергәч кенә аңладым... Нәрсә сатып алган, барысы да тартмадан да чыкмыйча мине көтә иде. Тау кадәр! Кәстрүлләр, савыт-саба, сервизлар... «Үзеңә ничек кирәк, ничек җайлы, шулай барысын да урнаштыр инде...» – диде ул. Һәммәсен минем өчен алган! Мин кулланыр, мин тотар дип...

Без Гөлнара белән аз гына алга киттек. Алар очрашкан мизгел бар бит әле.

– Мәскәүдән Истанбулга очтым, аннан Әнкарага. Иртүк килеп төштем. Мине каршылаучы күренми... Ун-унбиш минут көтеп басып тордым. Юк, күңелдә бернинди курку, «килмәс, каршы алмас» дигән шик юк. Соңга кала, ахрысы, дип уйлыйм. Аннан соң гына игътибар иттем: монда бит мине генә түгел, берәүне

Кәстрүл төште, капкачын тапты, ди төрекләр.



Очкычтан чыгуга, кафега симит ашарга тукталган чак. Бергә төшкән иң беренче сурәт... Аларның уртак селфилары шушы көннән башланды.

дә каршыламыйлар! Очкыч аланында андый хәл була алмый бит инде. Чыгу юлына таба киттем. Пыяла ишекнең теге ягында – халык! Димәк, каршылаучыларны нигәдер эчкә уздырмаганнар... Шул вакыт Наилне күреп алдым... Без ят кешеләр кебек очрашмадык. «Мин сине каядыр ялга озаткан булганмын да, хәзер сагынып каршы алганмын кебек», – диде ул миңа соңыннан. Мин дә шундый хисләр кичердем. Әйтерсең, каяндыр кайтып кына төштем...

Аэропорттан чыгуга, Наил кунагын... симит ашарга алып китә. (Төрекләрнең күп итеп көнҗет сибелгән бу күмәчен туристлар белә инде.) Онытмаган! Әле аралаша башлаганда ук Гөлнара аңа симит яратуын әйтә. «Әнкара симите Истанбулныкыннан аерыла. Безнеке юкарак, тәмлерәк, кетердәп тора. Һичшиксез яратырсың!» – ди аңа ир... Алар машинага утыруга, Наилгә абыйсының кызы шалтырата: «Гөлнара апаны каршы ала алдыңмы?» – ди. Тавышы борчулы! «Әйе! Ә нигә сорыйсың, ни булды?» – ди абыйсы гаҗәпләнеп. «Ишетмәдеңмени? Зур теракт булган бит. Бөтен аэропортларны япканнар. Интернет та эшләми. Бер-берегезне таба алмассыз дип курыктым...»

– Телевизор карау, яңалыклар тыңлау уема да кермәде шул... Иртән телефонда интернетым булмаганга бик аптыраган идем. Сәбәбен белергә теләп, әллә ничә тапкыр операторны җыйдым – эләгә алмадым... Аэропортта аймыл булсак, дигән курку миндә дә бар иде. Эчкә уздырмагач, куркуны шом алыштырды: «Әгәр хәзер ул аннан чыкмаса?» – дип уйладым. Гөлнара искә төшергән саен көлә: «Мин бит аэропорт эчендә кала алмый идем инде», – ди...

Икенче көнне Каппадокиягә китәргә планлаштырылган – иртүк юлга кузгалырга тиешләр. «Кайбер эшләремне төгәллисем бар. Син өйдә калып тор инде», – ди Наил Гөлнарага. Җавап аны хәзергәчә шаккаттыра: «Комачауламасам, машинада яныңда гына утырып йөрер идем...» «Минем эшләр сиңа кызык булырмы соң?» – ди ул аптырап. (Наилнең үз бизнесы, ул кафе һәм рестораннар өчен униформа тегү белән шөгыльләнә. Хатынының бу эштә үзенең уң кулына, ярдәмчесенә әйләнүенә ул әле хәзер дә ышанып бетә алмый.) Берничә ательега сугылалар, ә аннан Наил, алдан әйтми-кисәтми генә, Гөлнараны сеңлесе Нурсил янына алып керә. Телефондагы фотолар аша күргән бар – бер-берсен шунда ук таныйлар. «Минем абыйның кай җирен яраттың инде?!» – ди Нурсил уенын-чынын кушып.

– Бу сорау шундый көтмәгәндә яңгырады... Башта берничә мизгелгә югалып калдым. Беренчедән, аны яратаммы-юкмы икәнен әле үзем дә аңламыйм. Икенчедән, телне белмим. Дөресрәге, әйбәт белмим... Әйтергә теләгәнемне җиткерергә сүз байлыгым җитәрме? Аннан безнең татар төрекләрдән бу мәсьәләдә тыйнаграк, «яратам» дип кычкырып әйтми. Ходай ярдәм итте бугай – кулымны күкрәгемә куйдым. Сүзсез дә аңладылар... Шул чакта: «Күңелен яраттым», диюемне туганнар җыелганда әле дә еш искә төшерәләр. Иң ихлас җавап иде ул...

Гөлнараны бу юлы Төркиядә нинди очрашу көткәнен белгән берничә якыны арасында мин дә бар идем. Юлга җыенганда: «Ә чынлап торып ошаса нишләрмен? Мин бит бөтенләйгә китә алмыйм. Әти белән әни бар», – дип өзгәләнде ул. «Бәхетеңә берәү дә каршы төшмәс, аңларлар», – дип тынычландырырга тырыштым. Ләкин барысы да шулай тиз хәл ителер дип, беребез дә көтмәгән иде. Бигрәк тә ул үзе.

– Баштагы ике-өч көндә бәхет эчендә яшәдем. Дүртенче көнгә уйлана башладым. Нишләргә? Иң авыры шул чакта булды... Ә нииндидер бер карарга килгәч, сине инде берни дә куркытмый икән. Бу хәбәрне балаларга ничек әйтермен дип түгел, әти белән әнигә ничек җиткерермен дип кенә борчылдым. Иң элек кызыма әйттем. Миңа берни сиздермәде, ә үзе: «Әни еракка китә», – дип елаган икән. Бу хакта бер елдан соң гына ире сөйләде. Рәшит аны: «Минем әниләргә өч сәгать машинада кайтабыз, синекенә өч сәгать очасы – бер үк килеп чыга», – дип юаткан. Улым исә: «Ниһаять!» – диде. Алар икесе дә: «Кияүгә чык!» – дигән сүзне күптән әйтәләр иде.

«Минем урыным монда, Наил янында!» – дип, ул миңа да Әнкарадан ук шалтыратты. Хәер, аңа кадәр бармагына кигән яңа йөзекнең фотосын җибәрде әле. Рәсем астына бер сүз язмаса да, барысы да аңлашыла иде: Наил аңа тәкъдим ясаган!

– Без ул көнне гел бергә булдык. Озак кына кибетләрдә йөрдек. Шактый әйбер алдык. Соң гына кайттык. «Пакетларны үзең бушат инде», – диде ул миңа. Савыт-саба киптерә торган савытны зур гына

тартмага салганнар, пакеты да зур. Бушата башлагач, ул пакет эченнән тагын бер кечкенә пакет килеп чыкты. Монысын бергә алганны хәтерләмим – үзенә суздым. «Анысын да ач», – диде Наил. Ачсам, эчендә бәрхет тартма, ә тартмада шушы йөзек! Язуы да бар: «Мин сине ун ел көттем, башка көттермә, миңа кияүгә чык», дигән... Мин машинада Бану белән телефоннан сөйләшкәндә, «шәфталу алам», дип, кибеткә кереп киткән иде. Янәшәдә «алтын» кибете дә барына игътибар да итмәдем, ә ул өлгергән...

Гөлнара һәм Наил Шаһбазларның никахлары Казанда, ә туйлары Әнкарада узды. Абыйсы белән җиңгәсен, сеңлесен алып, Наил Татарстанга кыз сорарга килде. (Армиядә ул Искешәһәрдә хезмәт итә. Ә анда, белгәнебезчә, милләттәшләребез дә байтак. Димләп, чактан гына татар кызына өйләндермиләр аны ул чакта. Тик язмышыңнан кача аласыңмы?!)

Ике ялгыз язмыш шулай кавышты. Гөлнараның Мәскәүдәге менә дигән эшен ташлап читкә китеп барасына берәү дә ышанмаган иде. Ә ул ике дә уйламады! Хәер, Наилдән дә туганнары бу адымны көтүдән туктаган булган инде.

– Беренче хатыным белән аерылышканыма ун ел иде. Безнекеләр мине өйләндерергә ничек кенә тырышып карамады. «Башка берәүне дә күрсәтмәгез», – дигәч, соңгы елларда гына туктадылар. «Акылыма, күңелемә, йөрәгемә күрә берсен бир», дип, гел Аллаһы Тәгаләгә дога кылсам да, инде үзем дә башка өйләнмәм дип уйлый башлаган идем. Болай ерактан аласын күз алдыма да китермәдем. Гөлнараның самимилеген күргәнче шулай булды... Мондый хисләрне беренче тапкыр өйләнгәндә дә кичермәдем. Минем хакта үземнән дә күбрәк уйлаган, борчылган башка кешене таба алмас идем. Туйга ул башта каршы булды. Мин: «Ясыйбыз!» – дидем. Кына кичәбез дә булды әле. Үземне, чыннан да, беренче тапкыр өйләнгән кебек тойдым. Тормышымның мәгънәсе барлыкка килде. Һәр көнем бертөсле иде – ялгыз кешенең шулай бит инде... Төннәрне бөтенләй яратмаска өйләнгән идем. Ә ул килде дә, көнемне дә, төнемне дә, өемне дә, рухымны да яктыртты...

Хатынымны беренче көннән үк әни дә, туганнарым да бик яратып кабул итте. Бу да бик мөһим... Беренче килгәндә үк аны улым белән дә, кызым белән дә таныштырдым. «Әни булмасаң да, син аларга апа булырсың, ә мин синекеләргә – абый», – дидем. Мәрвә кызым туебызда булышып йөрде. Гөлнараның кызы белән кияве төрекчә белә – рәхәтләнеп аралашабыз, Казанга килгәч, Рәшит белән бергә мәчеткә, җомга намазына барабыз.

Ун ел ялсыз эшләдем. Ялгызың сәяхәт итү күңелле түгел бит, шуңадыр. Гөлнарага Төркиянең иң матур җирләрен күрсәтергә телим. Машинага утырабыз да, икәү чыгып китәбез. Юлда каядыр туктап, иртәнге ашны ашыйбыз... Бу сәяхәтләр безгә уртак хатирәләребезне баету өчен дә кирәк.

Икәү бергә хәсрәтләр кичерергә дә өлгердек. Башта көтмәгәндә Гөлнараның әтисе вафат булды, аннан, унбиш көннән соң, минем әни... Хатынымны әни күреп калды – шуңа сөенәм.

Икесе ике гаиләдә үскән кешеләр кушылганда да төрле аңлашылмаучылыклар килеп чыга. Ә монда ике ил, ике милләт... «Бер-береңне аңлаганда, проблемаларны чишәргә була. Яшебез дә бар, шуңа бер-беребезнең кадерен, кыйммәтен тагын да ныграк тоябыз», – ди алар.

«Хәятем...» Наилнең Гөлнарага бик еш шулай дәшкәнен беләм. Бер-берсе өчен зур бер дөнья булудан беркайчан туктамасын иде алар.

P. S. Наил дә Казанны инде яратырга өлгерде! «Татарстан, Казан турында белмәүчеләр Төркиядә байтак: җай чыккан саен сөйлим. Тыңлыйлар да, килергә, күрергә телиләр», – дип елмая ул. Татар теле дә аңа инде ят түгел – тәрҗемәчесез аңлашырга да озак калмады!



Гөлнараның исеме Наилнең телефонында, беләсезме, ничек язылган? «Хәятемнең аты». «Тормыш мәгънәмнең исеме» ягъни.

PRESSA

«СОРЫ ТАҢЫБЫЗНЫҢ ЧУЛПАНЫ...»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН,
шагыйрь;
гаилә стажы – 6 ел ярым;
балалары – Идел (5 яшь).

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Һич таныш булмаган хатын-кызны иң беренче күргәндә... ул үзе күрсәтергә теләгән өлешенә күз төшерәсең, билгеле. Бу – табигать тарафыннан салынган оеткы, һәм ир-ат өчен моның һичнинди гаҗәбе дә, ояты да юк. Ә хатын-кыз ул кай төшен чыгынкырак итәргә, кай төшен яшеребрәк куярга икәнен бик яхшы белә. Шәхсән минем өчен бу сыйфатлар беркайчан да җитди мөнәсәбәтләр өчен нигез булмады.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Тормышымның шундый чорына кереп барам, күрәсең: басынкыланып, тынычланып, һәрнәрсәгә фәлсәфи карарга, «бу – тормыш, ә без кешеләр генә, ә тормышта кешеләр мең төрле хәлләргә юлыга» дип яшәргә тырышам. Байтак дин белгече, Аллаһы Тәгалә кыямәт алдыннан Иблисне дә кичерәчәк, дигән фикердә. Чөнки ул рәхмәтле, рәхимле. Ул безгә дә сүрә-аятьләр аша: кичерү сорагыз, һәм мин кичерермен, дигән. Шулай булгач, минем, җан өрелгән гап-гади балчык кисәгенең, кемнедер (бигрәк тә соры таңыбызның Чулпаны булган хатын-кызны!) нәрсәдәдер гаепләргә, гафу итмәскә ни хакым бар?

3 Нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Алдагы җавабыма каршы килмәсәм ярый инде (*елмая*). Мәхәббәткә хыянәтне гафу итү кыендыр, мөгаен. Төрле сәбәпләр аркасында җандагы ут сүнеп, бер-береңнең күзендә боз булып утырган битарафлыктан гайре һични күрмәгәндә, уртак тормыш кара-каршы утырып бәрәңге ашауга гына кайтып калган очракта бер хәл әле. Мин, мәсәлән, Анна Каренинаны аңлыйм. Һәм аны кабул итәм. Ләкин мәхәббәттә хыянәтне кичерү – үзеңдәге шул хисне мәсхәрәләүгә, аңа аяк сөртүгә, ахыр чиктә, аны үтерүгә бәрабәр, минемчә. Хәер, бусы да булмаслык хәл түгел.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Мин беркадәр аңлаешсызрак, катлаулырак, сәеррәк кеше. Моңа Игезәкләр йолдызлыгында тууым да тәэсир итәдер, дип акланам. Сәгать буе авыз ерып утырырга, шаярырга, көләргә, аннары, кинәт, балтам суга төшкәндәй, каш җыерып, уйларым белән бөтенләй бу дөньядан китеп олагырга мөмкинмен. Бүген мин кояшка куанам, аның җылысыннан ләззәтләнәм; иртәгә, көем киткән чак туры килсә, күзне чагылдыра, дип, аны каплап куяр хәлгә җитәргә мөмкинмен. Шуңа күрә «минем хатын-кыз» булып гомер кичерү дә авырдыр. Чөнки мин аның бер үк вакытта алиһә дә, хуҗабикә дә, сердәшем дә, тәнкыйтьчем дә, ярдәмчем дә, балама әни дә, үземә сөяркә дә булуын телим...

5 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Мондый сорау тугач, ихтимал, була аладыр да. Өздереп әйтәсем килми.

Шайтан – башка, җен – башка, диләр. Шуңа күрә хатын белән дус-иш арасында, уртак яклар күп булуга карамастан, ихтимал, аерма тагын да күбрәктер. Хәер, савыт-саба шалтыраганнан соң, ак әләм күтәреп килгәндә, үзем: «Әйдә, дуслашабыз?» – дип ялварам.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Уникенче елның апрель азагы иде ул. Башта Тинчурин театрына барып спектакль карадык. Аннары җәяүләп кенә метрога юнәлдек. Салкынча матур кич иде. Казан тулы яз! Йөрәк тулы сөю хисе! Җир асты юлыннан чыгып барышлый гына розалар алып бүләк иттем. Мондый хәл яңалык булганга, Миләүшә шактый каушап төште. Кафега кереп урнаштык. Анда җылы, рәхәт иде. Бит очлары тагын да алсуланды. Йөрәгем ягында басып торган Тукай һәйкәленнән фатиха алып, сөйгәнемә күңелдәгесен әйтеп бирдем: сиңа зиннәт-байлык та, затлы тормыш та вәгъдә итә алмыйм, чиксез мәхәббәтемнән кала, миндә берни дә юк, дидем, әгәр шуңа риза булсаң... Яңаклары буйлап тәгәрәп төшкән яшьләре әле дә күз алдымда.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Һәрхәлдә, безнең очракта шулай булган кебек ул: үзем дә сизмәстән, гомерлек юлдашым итеп әниемдәй чибәр, йомшак һәм саф күңелле, инсафлы, ихлас, иҗади, балалары өчен җан аткан, кешегә һичкайчан начарлык теләмәгән... хатын-кызны сайлаганмын. Аларның исемнәре дә бер үк булып чыкты.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Ир баш булып, хатын-кыз еш кына муен ук булып та җитмәгән традицион татар гаиләсендә үскәнгә күрә, мондый мәсьәлә буенча фикер йөртү шактый кыен миңа. Йортка кергәнче утка кер, ди безнең халык. Ә мин халкыбызның сыналган мәкаль-әйтемнәренә ышанам. Ләкин бу шәхси очрак кына. Җирдә миннән башка 7 миллиардтан артык кеше яши. Ир-ат хурланмаса, кимсенмәсә, хатыны аннан разый булып, чөкердәшеп яшәсәләр – кемгә ни зарар? Аннан, кемдә кемнең эше бар? Бәхетле булсыннар.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Кеше язылган һәм язылмаган кануннар буенча (хәтта Конституция буенча да) үз фикерен белдерергә хокуклы.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Төрле хатын-кызлар булган кебек, аларның да төрлесе төрле якка игътибар итәдер инде: кемгәдер янчык кадерлерәктер, кемгәдер, шагыйрь әйтмешли, «киң күкрәкле, тимер бәдәнле» булуы, катлаулы программаларны аягүрә генә башкаруы, төнге күктә Кассиопея йолдызлыгын таба белүе... Шулай да, иң элек, ир-атның ышанычлы булуы игътибарны җәлеп итмиме икән?

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта...

– Кеше, гадәттә, билгесезлектән курка. Әлбәттә, артык чибәр һәм көчле хатын-кыз белән ике арада ниндидер киртә күтәрелми калмый. Ләкин куркумы икән бу? Артык чибәрлек, күп очракта, килбәтсезлек сыман ук, бәхетсезлекнең бер төре. Ир-ат, шушы чибәрлектән кала, хатын-кызның башка бик күп матур сыйфатларын (тәмле ашарга пешерү, рәсем сәнгате белән мавыгу, сабый күңелле булу һәм башкалар) күрмәскә, алар белән санлашмаска мөмкин. Кем үзен курчак сыйфатында гына кабул итәргә теләсен инде? Көчле дигәндә дә. Аның көчлелеге нидән гыйбарәт соң? Беркайчан да еламыймы? Ләкин хатын-кызның яшь түкмәве көчлелек билгесе түгел бит. Тормышта әллә нинди хәлләр була. Һәм ул барыбер елый. Күз яшен чыгармаса да... Табигать хатын-кызны нечкә күңелле, игътибарга, иркәләүгә, яратуга мохтаҗ итеп яраткан. Һәрбер чибәр, көчле, хәтта усал, тәкәббер хатын-кызның (Тонька-пулеметчица кебек сирәк, ләкин гаять куркыныч затлардан кала, билгеле) сылу гәүдәсе эчендә яратырга һәм яратылырга теләгән нәзик җан бәргәләнә.

12 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар сезнеңчә бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Ир-ат, нигездә, эчемлек салынган җамны яртылаш тулы, хатын-кыз – яртылаш буш, ди. Чынлыкта, һәрвакыт җам яртылаш тулы да, яртылаш буш та була.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Ул, тора-бара, һич гаҗәпләндерми торган, хәтта бик табигый күренешкә әверелә башлый икән. Без еш кына, мәсәлән, миңа чалбар алырга барган җирдән, «онытылып», хатынга күлмәк алып чыгабыз.

14 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Гүзәл затлар, үзара елмаешып, «ир-ат белән бәхәсләшеп торудан мәгънә юк, хатын-кыз аны барыбер җиңә», диләр. Мин бу аксиомага тулысынча ышанган килеш, беркатлылыгым беләнме, киреләнеп, үҗәтләнеп, барыбер үземнекен расларга, үземчә эшләргә тырышам. Әмма бу гамәлем һәрвакыт «әйттем югыйсә!» җөмләсен ишетү белән тәмамлана.

15 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Андый хәлгә беркайчан да тарыган булмады әле. Табын корып өлгермәслек булса, ул алдан ук кисәтеп куя. Калганын вазгыятькә карыйсың инде. Алар да өйгә кайтып җитмәсәләр, бергәләп берәр кафега кереп, мохитне алыштырып, җилләнеп һәм бер уңайдан тукланып та чыгабыз.

Студент елларын тулай торакта уздырган кеше буларак, үзем дә пешеренергә тартынып тормыйм. Мәсәлән, гап-гади йомырканы унбишләп төрле әзерләү рецептын беләм: болгатып кыздыру, ике яклап кыздыру, суган белән кыздыру, помидор салып кыздыру, тәбә итү, йомры килеш пешерү, кабыгыннан әрчеп тозлы суда пешерү... Миләүшә язгы ямьле бер көндә улыбыз Иделне тапкач, бәби табу йортына тавык шулпасын үзем пешереп китергән идем.

16 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Чүпрәк кибетенә яисә башка берәр шундый кызыксыз, күңелсез урынга барганда мин үзем дә, улым да байтак вакыт оешып бетә алмыйча, үшәнләнеп йөрүчән. Андый чакта хатын иң элек Иделне әзерләп киендерә, аннары мине. Соңыннан без икәүләп, «кайчан әзер буласың инде», дип, аның үзен көтәбез.

17 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Бу, гомумән, иң авырткан урыным. Бүләкне сайлый да, бирә дә белмим. Төрле бәйрәмнәр белән исәпләшеп, һәрдаим нәрсәдер эзләргә, табарга, шактый баш ватарга туры килә, билгеле. Андый чакта бөтенләй талчыгып, ялыгып, йөдәп бетәм. Әкияттәге сыман, һаман бер бүре башын да чыгарып салып булмый бит әле! Ә календарь – мәкерле: андагы ике битнең берсе кызыл төскә буялган. Алар арасында безнең гаилә өчен мөһим даталар да күп.

Үзем шундый булганга, башкалардан бүләк көтмим дә. Миңа ни кирәген үземнән дә яхшырак белүче юк барыбер. Җаным теләгәнне барам да алам. Боларның барысын да истә тотып, җәмәгатем, гадәттә, үзем беркайчан да кызыксынмаган, кирәксенмәгән, үзем акча туздырып юнәтергә җыенмаган кирәк-ярак (юк-бар димим инде) алып бирә: хушбуй, кием-салым, аксессуарлар...

Бүләкнең кадере, минемчә, сумнарда исәпләнми. Эштән арып кайтканда ишек төбендә елмаеп каршы алсалар – шул да искиткеч бүләк бит.

Фото: Гөлназ Гыймадиева



Томау гына димәгез

Борын тирәсе куышлыкларының ялкынсынуы югары тын юллары чирләре арасында беренче урында тора. Урта Европада яшәүче халыкның 5 проценты хроник синуситтан интегә. Табиб-оториноларинголог, Казан дәүләт медицина университетының оториноларингология кафедрасы ассистенты Диләрә ШӘКҮРОВА безгә гайморит, аның билгеләре, дәвалау чаралары һәм гайморитны булдырмый калу өчен ниләр эшләргә кирәге хакында сөйли.

Кискен гайморит – казналык өсте куышлыгының лайлалы тышчасы ялкынсыну ул. Сәбәбе: тын юллары аша анда патоген микрофлораның үтеп керүе. Кайчакта тын юлларындагы анатомик җитешсезлекләр дә сәбәп булырга мөмкин. Кискен яки озакка сузылган ринит (томау), аденоидлар, полиплар да ялкынсынуга китерә ала, чөнки болар борын яны куышлыкларына җыелган сыеклыкның агышына комачаулый.

Ялкынсынган казналык өсте куышлыкларын тикшергәндә күп очракта патоген бактерияләрдән пневмококк, гемолитик стрептококк, эчәклек таякчыгы булуы ачыклана. Сирәк кенә катнаш инфекция, вируслар, гөмбәчекләр дә очрый.

Билгеләренә килсәк, башны алга игәндә баш авыртуы көчәю һәм авырлык тою, борыннан үлекле лайла килү, авыртуның чигәгә бәрүе яисә битнең авыртуы гайморит билгеләре булырга мөмкин. Гомуми симптомнардан артык зур булмаган температура, хәлсезлек, баш авырту күзәтелә.

Дәвалау беренче чиратта борын куышлыгын үлектән арындыруга һәм ялкынсынуны бетерүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Физиотерапиянең дә нәтиҗәсе бар. Борын куышлыгындагы үлекле лайланы суырту да яхшы нәтиҗә бирә. Мондый процедураны 5-8 тапкыр ясарга кирәк. Консерватив дәва чараларының беренче тәүлектән үк файдасы булмаса, табиб казналык өсте куышлыгына пункция ясап, 7-8 көн буе антисептиклар белән юдыра һәм антибиотик препаратлар кертә. 8 тапкыр юдырганнан соң да үлек килүе бетмәсә, хирургия алымнарын кулланырга туры киләчәк.

Ничә яшьтә булса да, баланың томалаулап торуын игътибарсыз калдырырга ярамый. Яңа туган балаларда әле гаймор куышлыклары формалашмаганлыктан, аларда гадәттә рәшәткәчел лабиринт куышлыгы ялкынсыну – этмоидит күзәтелә. Гаймор куышлыклары исә 3 яшькә генә формалашып җитә.

Ата-аналарның күбесен баланың гаймор куышлыкларына пункция ясату кирәк булу ихтималы хафага сала. Ул консерватив дәваның нәтиҗәсе булмаганда гына билгеләнә. Ләкин хәзер заманча методлар да бар, һәм аларны кулланганда пункция ясарга кирәкми. Мәсәлән, «синус катетеры ярдәмендә борын куышлыкларын антисептик сыеклыклар белән юдырырга һәм дарулар кертергә мөмкин.

Күп кенә ата-аналарда бер тапкыр пункция ясатсаң, аны гел кабатлап торырга туры киләчәк, дигән фикер яши. Бу – ялгыш фикер. Баланың гайморит белән еш авыруы пункция ясатуга түгел, ә борын төзелеше, борын кимерчәгенең кәкрәюе, борын куышлыкларында полиплар булу-булмауга, еш салкын тидерүгә һәм иммунитетның торышына бәйле.

Сәбәбе нәрсә генә булса да, гайморитны дәваламый калырга ярамый. Борын куышлыкларының ялкынсынуы өскәрәк үтеп, маңгайдагы куышлыкларның ялкынсынуына – фронтитка китерергә мөмкин. Фронтит урта борын юлы белән 1,5-2 см озынлыктагы нечкә генә канал аша тоташкан. Маңгай куышлыкларының ялкынсынуы хәтәр. Вакытында дәваламасаң, ялкынсыну процессы баш сөягенә һәм күз чокырына күчәргә мөмкин.

Гайморитны мунчада дәвалап буламы, дип сорыйлар. Болай эшләргә ярамый. Беренчедән, югары температурадан борын эченең болай да шешенгән лайлалы тышчасы тагын да зураячак, һәм ул эчтәге сыеклыкның тышка агып чыгуына комачаулаячак. Икенчедән, гайморит инфекцияләр тәэсирендә барлыкка килгән чир. Андый чакта мунча тыела. Мунча ул тернәкләнү чорында әйбәт.

Табиб киңәше

■ Беренче һәм мөһим кагыйдә: салкын тигән вакытта барлыкка килгән томауны игътибарсыз калдырмагыз. Профилактика чаралары гади генә: көненә берничә тапкыр тозлы эремә белән борынны юдыру, грипп вакытында кеше күп җыела торган чараларга бармый тору, салкын тиеп авырганда борынга кан тамырларын тарайтучы тамчыларны дүрт көннән дә озаграк кулланмау. Бүген күп кенә сырхауханәләр каршында эшләүче көндезге стационарларда борын яны куышлыкларының ялкынсынуын булдырмас өчен профилактика чаралары уздырыла. Боларга махсус препаратлар белән баланың борын эчен юдыру һәм борын яны куышлыкларына физиодәва билгеләү керә.



Цистит хатын-кыз чиреме?

Цистит белән барлык хатын-кызларның 40 проценттан артыгы таныш. Аның белән яшь кызлар да, өлкән апалар да авырый. Шуңа да күпләр аны хатын-кыз чире дип кенә саный. Әмма ул ир-егетләрдә дә булырга мөмкин, тик аларда сирәк очрый. Тынычлыкны ала, гел борчып тора торган бу чирнең билгеләре, сәбәпләре һәм дәвалау алымнары белән безне югары категорияле табиб-уролог Артем МАКАРОВ таныштыра.

Цистит – гади генә итеп әйткәндә, бәвел куыгының ялкынсынуы ул. Аның белән ешрак хатын-кызлар, һәм, нигездә, кияүдәге ханымнар җәфалана, чөнки хатын-кызларның бәвел юлы кыска һәм киң. Шунлыктан инфекция бәвел куыгына тиз барып җитә, үзенең мәкерле эшен башлый. Әмма аның белән ир-егетләр дә авырый. Тик бәвел куыгына барып җиткәнче, инфекция аларның мәни бизен – простатаны зарарлый, һәм ир-егетләрдә күзәтелгән цистит икенчел чир булып санала.

Циститның төп сәбәбе – инфекция. 90 процент очракта туры эчәктән уретра яки тире аша үтеп кергән эчәк таякчыгы була ул. Аякны туңдыру, салкын җиргә утыру, көне буе утырып эшләү, авыр эшкәртелә торган ризыклар белән туклану – организмда яшәгән инфекцияне уятып җибәрергә бер этәргеч бирә. Хатын-кызларда очрый торган җенси авырулар да бәвел куыгы ялкынсынуын китереп чыгара ала. Бәвел куыгындагы төрле кимчелекләр дә кайчак бу чир башлануга сәбәпче була.

Шулай ук гигиена таләпләрен тиешенчә үтәү дә бик мөһим. Тәнне кысып торган синтетик кием-салым, даими төстә көндәлек аслыклар куллану, күрем вакытында тампоннарны һәм аслыкларны сирәк алыштыру, юынганда арттан алга таба юыну, бәдрәфкә сирәк йөрү дә цистит кузгатырга мөмкин. Бәвел куыгын көненә биш тапкырдан да кимрәк бушатырга ярамый.

Циститның ике төрле формасы – кискен булганы һәм хроник төсмер алганы очрый. Кискен формасы эчнең аскы ягы авырту, бәвел юлы һәм бәвел куыгы әчетү, еш кысталу, әмма бәвелнең аз булуы белән башланып китә. Кайчак тән кайнарлана, бәвелдә кан да күзәтелергә мөмкин.

Кискен циститны терапевт дәвалый. Гадәттә, бәвел куыгындагы инфекцияне юдырып чыгару өчен уросептиклар билгеләнә. Дөрес дәваланганда, пациент инде икенче көнне үк җиңеллек тоярга тиеш. Ә чир үзе 6-7 көндә чигенә. Цистит белән авырганда тәнне җылыда тоту, тынычлык мөһим, шуңа да вакытлыча хезмәткә яраксызлык кәгазе бирелә. Мүк җиләге, турак уты яфрагы (толокнянка) төнәтмәләре дә булыша. Коры эссенең дә шифасы бар. Ләкин чирнең кискен вакытында парлы мунчага керү тыела, чөнки дым белән инфекция тагын да таралачак кына. Әрнүе бик каты булганда, авыртуны баса торган препаратлар да кулланырга мөмкин, ләкин бу дәва чарасы түгел, ә хәлне вакытлыча җиңеләйтү.

Бәвел куыгының ялкынсынуы ике айдан артык дәвам итсә, ярты елга – ике яки бер елга өч тапкыр кабатланып торса, монысы инде хроник цистит билгеләре. Хроник чир вакытында авырту алай ук кискен булмый, әмма аның сәбәпләрен инде башкадан эзләргә туры килә. Бу очракта терапевт урологка юллама бирә. Чирне китереп чыгарган сәбәпләрне ачыклар өчен анализлар алына, башка төрле дәва билгеләнә. Ир-егетләр исә авыруның беренче билгеләре башлануга ук урологка күренергә тиешләр.

Циститка, үзе үтәр әле, дип кенә карамаска кирәк. Дәваланмаган очракта ялкынсыну процессы бөерләргә дә үтеп, пиелонефрит башланырга мөмкин. Анысы инде күпкә катлаулырак чир.

Табиб киңәше

- Цистит булмасын өчен шәхси гигиенаны төгәл үтәргә, тәнне, аеруча аякларны туңудан сакларга кирәк.
- Җенси партнерның сәламәтлеге һәм тәртипле җенси тормыш алып бару да бик мөһим. Саклык өчен, мөнәсәбәтләргә кергәнче үк, уросептик препаратлар белән профилактика ясарга була.
- Цистит билгеләре башланса, бәвел кудыргыч үзлеккә ия үлән төнәтмәләре, аеруча мүк җиләге сыгынтысы бик булыша. Беренчедән, алар бәвел куыгындагы инфекцияне юдырып чыгара, икенчедән, андагы С витамины күзәнәкнең тышчасын ныгыта.
- Чирнең кискен чорында парлы мунчага керми торыгыз. Ә менә эчнең аскы ягына коры эссе әйбер куеп торырга була.



Чәй эчәргә шекере



Февраль санybызның кунаклары – удмурт күршеләребез. Татарстанда алар 23 мең кеше тирәсе. Удмурт авыллары, нигездә, республиканың Балтач, Кукмара, Мамадыш якларында күпләп урнашкан. Каяндыр килеп утырган авыллар түгел ул, удмуртлар монда электән үк яшәгән.
Бу халык гомер-гомергә игенче булган. Бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре дә җир эшкәртү белән бәйле. Июнь аенда, сөрү эшләре тәмамлангач, Гырон быдтон бәйрәм ителә. Аны бөтен республика белән бергәләп бәйрәм итү инде күптән матур бер традициягә әйләнде. Питрау бәйрәме дә үзгә бер әзерлек белән, зурдан кубып уздырыла. Бу көнне корбан чалына. Удмуртларның ышанулары буенча, Питрауга кадәр Җир-анабыз йөкле санала, үләннәрне өзеп, җирне казып, аны тынычсызларга ярамый. Питрау җитми торып яшь бәрәңгедән дә авыз итмиләр.
Мари халкы белән бергәләп үткәрелә торган Симык бәйрәмнәрен дә беләбез. Анысы инде мәрхүмнәрне искә алу йоласы. Өйдә ризыклар пешереп, ул көнне әрвахларның мәңгелек йортына кунакка баралар. Урак тәмамлангач, Арам быдтон уза.
Һәр милләтнең үз теле, үз йолалары булган кебек, үз милли ашлары да була. Удмурт халкының милли кухнясы артык купшылыгы белән аерылып тормый. Төп ризык – ярмалар, терлек ите һәм камыр ашлары. Урман сые – балан, кура, каен җиләге, бөрлегәннән төрле кайнатмалар, кесәлләр ясыйлар.
«Хатын-кыз галәме»нең бүгенге хуҗабикәсе – Татарстан Республикасы Удмурт милли-мәдәни автономиясенең башкаручы директоры Марина ИВАНОВА «Сөембикә» укучыларын шекере дип аталган милли ризыклары белән таныштырачак. Шекере – бәйрәм сые, аны кунак-төшем вакытында десерт буларак әзерлиләр. Безнең чәкчәккә охшаш, пешерү тәртибендә генә аерма бар.



Кирәк
- 500 г чамасы он;
- 4 йомырка;
- тәменчә тоз;
- 200 г үсемлек мае;
- 200 г сөт.

Ширбәт өчен:
- 300 г бал;
- 200 г шикәр комы.



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Онны тирән эчле савытка иләп, йомырка сытабыз, сөт, үсемлек мае һәм тәменчә тоз салып, катырак итеп камыр басабыз. Ул пилмән камыры кебегрәк булырга тиеш.

■ Әзер камырдан кечерәк кенә бер өлеш өзеп алып, бау сыман итеп тәгәрәтәбез. «Бау»ның калынлыгы бармак калынлыгы кадәр булсын.

■ Үткен пычак белән әлеге «бау»дан 1 см чамасы зурлыгындагы шакмаклар – бавырсаклар кисәбез. Аларны кечерәк яисә чак кына зуррак итәргә дә мөмкин.

■ Бавырсакларны пергамент кәгазе җәелгән коры табага тезеп, 180 градустагы мичкә куябыз. Алар алланганчы пешәргә тиеш. Якынча 15 минут чамасы вакыт китә. Бавырсакны тирән эчле берәр савытка бушатабыз.

■ Плитәгә сулы кәстрүл утыртып, кайнатып чыгарабыз. Аның эченә иkенче бер савытны урнаштырып, бал салабыз. Болгата-болгата балны эретәбез.

■ Эрегән балга шикәр комы кушып, ширбәт кайнатабыз. Ширбәт куера башлагач, савытны судан алып, тиз генә бавырсак өстенә коябыз, кашык белән барысын бергә бутыйбыз. Ширбәт бик тиз ката, шуңа күрә тиз-тиз эшләргә кирәк. Әгәр дә бутап өлгерә алмасагыз, савытны кабат кайнар суга утыртып алырга мөмкин.

■ Шекерене матур савытка салып, чәй табынына чыгарабыз. Бавырсакны ширбәт белән катырмыйча, коры килеш кенә сыйлансаң да тәмле – кетердәвек печенье кебек була.

Выль кен пыртон йоласы

Борынгы йолаларның берсе – кыз урлау гадәте удмурт халкында әле бүген дә гамәлдә. Элек кызкыркынны бер белмәгән егеткә дә урлап алып киткән булсалар, хәзер ул яшьләрнең үзара килешүе белән генә эшләнә. Әмма йола буенча, кыз кеше барыбер тартышырга, көрәшергә тиеш. Кызны урлагач (бу эш төнге уникедә башкарыла), кыз өенә вәкил китә: «Танагыз бездә», – ди ул. Кызыгыз дип әйтергә ярамый. Өч сәгать эчендә кызларын барып алып кайтырга хакы бар ата-ананың. Ләкин егет өендәге җиңгәчи (өлкән килен) аның башына яулык бәйләп өлгерсә, ул инде шушы йортның килене исәпләнә. Өч көн аңа кияү өеннән беркая да чыгарга ярамый. Аннары инде атасы йортына кайтып, туйга әзерләнә. Егетне ошатмаса, кыз яулыкны бәйләтмәс өчен тартыша. Удмурт халкының ышануы буенча, кешенең үз гомерендә өч туе була: туганда, гаилә корганда һәм үлгәндә.

ПЕРЕПЕЧ – удмурт халкының иң атаклы милли ризыгы. Төрле-төрле эчлек салып, төче камырдан пешерелә ул. 150 г арыш һәм 450 г бодай онына 200 мл сөт һәм тәменчә тоз салып, каты итеп камыр басыла. Камырны вак-вак кисәкләргә бүлеп, һәрберсе 8-9 см зурлыгындагы түгәрәк итеп җәелә. Кырыйларын өскә таба бөреп, «кәрзин» ясала һәм кайнар мичкә тыгып, аз гына пешереп алына. Эчлек өчен 300 г фарш һәм 230 г туралган кәбестә, 70 г суган алына. Кәбестәне вак итеп турап, суган белән бергә табада кыздыралар, шуңа фаршны кушалар. Эчлек әзер булгач, «кәрзиннәргә» салып, өстеннән сөт белән туглаган йомырка агызыла. Перепечләр 180 градус кызулыктагы мичтә 20–25 минут пешә.

ШУ КИСАЛЬ – балан кесәле. 2 стакан юылган, чистартылган баланны 1 стакан шикәр комы һәм аз гына су белән катнаштырып, сүрән утта яки җылы мичтә 5-6 сәгать пешерәбез. Җиләкләр йомшарып, саргылт-көрән төскә кергәч, 8 аш кашыгы арыш оны һәм 8 аш кашыгы солод яки коры квас, 1 литр кайнар су кушып туглыйбыз. Кесәл куергач, димәк, әзер. Ул кайнар килеш тә, суык килеш тә бик тәмле.



Фото: Анна Арахамия

Бетчә – бетмәс чир түгел

Борын очына чыккан кечкенә бетчә үз-үзенә ышанган хатын-кызның да кәефен төшерә кайчак... Әледән-әле көзгегә карап аласың, махсус кремнар белән яшерергә тырышасың. Ә хәзер яшүсмерләрне искә төшерик! Җитлегү чорында күпләренең бите бетчәгә бата. Оялалар, уңайсызланалар. Әле генә дөньяга ачыла башлаганнар кабат ябылырга да күп сорамый. «Мин матур түгел», дип, үсмерләрнең үз бәяләрен төшерүгә дә нәкъ шул сыткычлар гаепле бугай. Бетчә аркасында үзеңә ямьсез дип карар чыгару дөрес түгел. Ул вакытлы күренеш кенә. Аны дәваласаң, җиңеп булачак. Яшүсмерләр белән утырып сөйләшергә генә кирәк. Бу бик тә җитди сөйләшүдә (үсмерләр өчен ул аеруча мөһим тема: күңелнең иләсләнеп, беренче тапкыр гашыйк булып йөргән чаклар бит!) табиб-дерматолог, косметолог Эльвира ШӘРИФҖАНОВА ярдәм итәр.

Бетчә – яшүсмер организмында үзгәрешләр башланган чорда тире авыруларының киң таралган төре. Кеше тормышы өчен куркыныч тудырмаса да, бик күп газапларга дучар итә. Бу вакытта яшүсмерләр болай да үзләренә тәнкыйть күзлеге аша карый. Бетчәләр чыгып, рухи халәтләрен тагын да катлауландыра. 12–24 яшьлекләрнең 80 проценты шуның белән җәфа чигә. Үсмерлек чорында кызларга да, егетләргә дә бетчә бертигез дәрәҗәдә чыкса, үскәч, әлеге проблема хатын-кызларны күбрәк борчый.

Акне (бетчә чыгу) – нәселдәнлек авыруы. Мәсәлән, үсмернең әтисенә дә, әнисенә дә сыткыч чыккан булса, аның авыру ихтималы икеләтә арта. Дерматологиядә ул тиренең хроник авыруы дип карала. Май бизләре секретының липидлары артык эшләү йә тигезлеген саклый алмау нәтиҗәсендә, бит тиресе ялкынсына.

Алар берничә төргә бүленә:

БЕТЧӘ (УГРИ) — башы үлекле кызыл төерләр. Алар тиренең өске катында чыга;

КОМЕДОННАР — тире күзәнәкләрендәге кечкенә кисталар. Алар тиредә кара төрткеләр кебек. Каралу – пычрак түгел, ул җыелган бактерияләр, үлгән күзәнәкләр, оксидлашкан майлар;

ПАПУЛЛАР – авыртып торган кечкенә шешләр. Томаланган куыкчыкка (фолликулга) инфекция кереп, ялкынсынудан чыга;

КИСТАЛАР – тирән, үлек белән тулган бетчәләр.

Үсмерлек чорында бөер өсте бизе эшләп чыгаручы җенес гормоннары тәэсирендә май бизләре эшчәнлеге активлаша. Ул үз чиратында тире маен тиз чыгара башлый. Шунлыктан май бизләре секреты куера һәм каналларны томалый, бу тире өслегендәге мөгез катламының артык калынаюына китерә. Нәтиҗәдә, бит тиресе кытыршылана, вак кызыл бетчәләр, тимгелләр чыга, ялкынсыну күзәтелә. Май бизләре каналлары томаланып, микроб таралуга уңай шартлар туа. Бу вакытта үлекле сыткычлар чыга башлый. Вакытында дәваланмасаң, биттә акнедан соң кызыл таплар, хәтта җөйләр калырга мөмкин.

Аны дәвалау җиңелләрдән түгел. Косметологик алымнар яки чаралар, бигрәк тә чирнең авыр формасында, вакытлыча гына дәвалый. Шуңа күрә табиб-дерматологка мөрәҗәгать итү мөһим. Төрле препаратлар кулланып дәвалану үз нәтиҗәсен бирми калмый. Ләкин препаратларны берничә ай даими рәвештә кулланырга кирәк.

Бу очракта бит тиресен махсус дерматологик косметика белән генә тәрбияләргә кирәк. Майлы бит тиресен чистарту өчен эпидермисның өске катламын һәм pHның табигый дәрәҗәсен бозмый, аллергия бирми, тирене корытмый һәм ярсытмый торган косметологик чаралар кулланырга киңәш ителә. Алар составында парабеннар, агрессив кислоталар, спирт һәм сабын булмаска тиеш. Әйе, сабын белән битне юарга ярамый! Чөнки май бизләре тагын да күбрәк май эшкәртеп чыгара башлый. Бетчәле тирене дымландыру өчен майлы кремнар сөртмәгез. Алар комедоннар хасил итә һәм эпидермисның мөгез катламын тагын да калынайта. Сайланган крем тиренең табигый дымлануын гына тәэмин итеп калмыйча, май бизләре эшчәнлеген дә җайга салырга тиеш. Күпләр бетчәләрне сытып, бу хәлдән үзләренчә чыкмакчы була. Ялгыш фикер! Һич тә кагылырга ярамый! Инфекция кереп, тиредә ялкынсыну артачак кына.



Эльвира Шәрифҗанова, табиб-дерматолог, косметолог

Анализ нәтиҗәләре буенча, бетчәләрне дәвалау өчен һәр үсмергә индивидуаль курслар билгеләнергә мөмкин. Ул май бизләренә андроген гормоннарның тәэсирен, микробларны киметүгә юнәлтелә.

Артык күп бетчә чыккан яшүсмерләр кайчак депрессиягә дә бирелә. Күчеш чорында балаларга һәрвакыт игътибарлы булырга киңәш итәм. Барысын да җайлап аңлатыгыз, үз белдегегез белән дәваланмагыз, бергәләп дерматологка барыгыз. Психологка бару да комачау итмәс.

Диета

Дөрес туклану – бетчәләрне дәвалаганда комплекслы терапиянең аерылгысыз өлеше. Диета натураль азык-төлектән торырга тиеш:

- Майлы балыклар, диңгез продуктлары, чикләвек, үсемлек майлары составында булган Омега-3 май бизләренең эшчәнлеген нормальләштерә, тирене яхшырта, гормоннар эшчәнлеген көйли;
- Клетчаткаларга бай азык-төлек (җиләк-җимеш, яшелчә, кузаклылар) – витамин һәм минераллар чыганагы. Алар эчәклекне токсиннардан чистарта. Ә ул тирегә уңай тәэсир ясый. Ашказаны-эчәк тракты эшчәнлегенә игътибарлы булу кирәк. Эч кату да бит тиресе начарлануга китерә;
- Майлы булмаган ит;
- Пробиотик культуралар белән баетылган, майлылыгы аз булган сөт продуктлары;
- Тәүлек дәвамында кимендә ике литр су эчәргә кирәк. Суны аз куллану күзәнәкләр яңаруны, тиредәге майларны чыгаруны акрынайта;
- Май бизләре эшчәнлеген яхшырту өчен фосфор, цинк, кальций, магний һәм калий микроэлементлары файдалы.



Тиз, җиңел, файдалы

Иртәнге ашка нәрсә генә әзерләргә? Бу сорауны үзегезгә еш бирәсезме? Файдалы да, туклыклы да биш төрле иртәнге аш рецепты тәкъдим итәбез. Үзегезгә ошаганын сайлап алыгыз. Аларның һәркайсы – менә дигән энергия чыганагы. Шул ук вакытта форманы сакларга да булышалар.

СОЛЫ КОЙМАГЫ

Аны исемлек башына куюыбыз юкка түгел, чөнки бу коймакны теләсә нинди ризык белән яраклаштырырга була.

Тирән эчле савытка 2 аш кашыгы солы лавачы (геркулес), 1 йомырка һәм 3 аш кашыгы кефир (яки сөт) салып туглыйбыз да, бер-ике тамчы май тамызылган табага агызабыз. Капкач белән томалап, уртача утта 5 минут пешерәбез. Коймак пешеп чыккач, өстенә уылган сыр сибәргә була. Сыр эреп беткәнче бераз томалап кына торырга кирәк. Коймакка эремчекле сыр ягып, өстенә тозлы кызыл балык телеме куйсаң да тәмле. Баллыны яратсагыз, коймак өстенә бананлы эремчек яисә арахис пастасы яга аласыз.

ЯЛКАУЛАР БОТКАСЫ

Иртән ботка пешереп торырга вакытыгыз булмаса, бу ботка нәкъ сезнең өчен инде. Кечтән пыяла банкага яисә зуррак касәгә солы лавачы, яраткан чикләвекләрегезне, кипкән җиләкләр, туралган банан салып, ряженка яки катык кушып болгатыгыз да, капкач белән каплап, иртәнгә кадәр суыткычка куеп калдырыгыз. Файдалы ботка иртәнгә инде әзер! Салкын дисәгез, СВЧ мичендә җылытып алырга була.

БРОККОЛИЛЫ ТӘБӘ

Гади тәбәдән ялыксагыз, икенче төрлесен әзерләп карагыз әле! Туңдырылган брокколины табага салып кыздырабыз. 2-3 йомырканы яхшылап туглап, кечерәк табага яки утка чыдам формага салабыз да, брокколины өстәп, мичкә тыгабыз. Тәбә әзер булуга, өстенә уылган сыр сибеп, беразга кабат мичкә тыгып алабыз. Сыр эреп бетүгә, тәбә әзер.

ЙОМЫРКАЛЫ АВОКАДО

Авокадоны җайлап кына икегә бүлеп, төшен алабыз. Төш урынына берәр кисәк тозлы кызыл балык куеп (мәҗбүри түгел), сак кына берәр йомырка сытабыз. Тәменчә тоз, борыч сибеп, йомырканың агы пешеп җиткәнче 100–150 градуслы мичтә тотабыз.

КҮЗИКМӘКТӘГЕ ЙОМЫРКА

Тирән эчле табага күзикмәк («әрмән ләвәш»е) җәеп, туралган помидор, яшел үләннәр салабыз, 2 йомырка сытабыз, өстенә уылган сыр, тәменчә тоз һәм борыч сибәбез. Күзикмәкне җайлап кына конверт сыман итеп төреп, астын өскә әйләндерәбез. Табаны капкач белән каплап, сүрән утта һәр ягын җидешәр минут кыздырабыз. Бик тәмле һәм туклыклы ризык килеп чыга.

Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА әзерләде.

Кучкар. Бар да үз җаена гына бара торган тыныч чор башлана. Зур үзгәрешләр көтелми кебек. Илһам чыганагы – гаиләгез һәм якыннарыгыз. Күңел тоемыгыз искиткеч, ул алдатмас.

Үгезбозау. Рухи күтәренкелек, үзегезгә ышаныч – менә ниләр көтә сезне бу айда. Сез җиңә алмаган киртәләр юк, теләсә нинди мәшәкатьне җиңел генә хәл итәрсез.

Игезәкләр. Уңышлы һәм бик эшлекле ай. Гаҗәеп идея бөтереп алыр. Тырышлыгыгыз җитеп, шул идеягезне тормышка ашыра алсагыз, әҗере куандырыр. Айның беренче яртысы яңа танышлык һәм күңелле очрашулар белән истә калыр.

Кысла. Язмыш яңа мөмкинлекләр әзерли, кулдан ычкындырмагыз! Үзгәрешләр эштә генә түгел, шәхси тормышта да көтелә. Күп кенә мәсьәләләрне хәл итәргә туры киләчәк. Сабырлык һәм үҗәтлек булса, барысына да ирешерсез.

Арыслан. Яхшы нәтиҗәләр чоры. Моның кадәр энергия ташкынын күптән инде тойганыгыз булмагандыр. Бу көчне тиешенчә файдаланып калыгыз: яңа белем үзләштерү, һөнәргә өйрәнү, яңа кешеләр белән танышу өчен искиткеч вакыт.

Сөмбелә. Әлегә активлыкны бераз киметеп торып, үз тойгы-кичерешләрегезне алга куегыз. Яңа мөмкинлекләр дә, кыю планнар да булыр, дөрес юнәлеш алсагыз, әҗере дә озак көттермәс. Ай башында ук абруегызны арттыра торган гамәл кылырсыз.

Бизмән. Уйларның тиз арада чынга ашар мәле. Астрологлар бу айда үзегезгә комачаулый торган танышлардан арынырга өнди. Буш урынга шунда ук нindидер яңалык урнашачак.

Чаян. Мөһим мәсьәләләр чишәрсез һәм шуның белән финанс ягыгызны да җайларсыз. Ай урталарында элеккеге якын дусларыгыз белән очрашу ихтималы зур. Гомумән, моңарчы сузылып килгән эшләрне төгәлли алырсыз.

Укчы. Вак-төяк мәшәкатьләр булыр. Тормыш авырлыкларына җиңелрәк карасагыз, тиздән барысы да җайланачак. Аның каравы, тәҗрибәгез һәм зирәклегегез артыр.

Кәҗәмөгез. Сезне зур эшләр көтә. Әлбәттә, алар көчегезне аз алмас, шуңа да баштан ук бар энергиягезне сарыф итеп бетермәскә тырышыгыз. Холкыгыздагы тәвәккәллек тагын да көчәер.

Сукояр. Тотрыклылык ае. Астрологлар бу чорда агымга каршы йөзмәскә чакыра. Сабыр булыгыз, язмыш үзе тиешле урынга китереп җиткерер. Уйларыгызны тәртипкә китерер өчен яхшы вакыт.

Балык. Ияләнгән тормышыгызга үзгәрешләр килеп керер. Алар барлык өлкәләргә дә кагылачак. Йолдызлар сезгә хәерхаһлы булган чорда мөһим эшләрегезне башкарып калырга тырышыгыз.

ӨЧ ХАТЫН-КЫЗ

Ир-ат тормышында бары тик өч хатын-кыз гына иң мөһим рольне уйный. Аларның нәкъ менә өчәү булуы ир кешедән чын ир ясый. Өченчесе, бәлки, булмас та, ләкин беренчесе һичшиксез булачак. Аның белән ул мәңгегә бергә калачак. Үзен күрмәсә дә, күңелендә, уйларында йөртәчәк. Алар арасындагы мөнәсәбәтләр – мәңгелек. Ул ярату да булырга мөмкин, кайчак хәтта нәфрәт тә. Ләкин ни генә булмасын, ир кеше бу дөньяда бары тик шул беренче хатын аркасында гына яши. Ул аннан чын-чынлап аерыла да, баш та тарта алмый. Ул – аның тормышындагы иң беренче һәм иң мөһим хатын-кыз.

Икенче хатын-кызны да ул бик яратырга, аннан башка яши алмаска мөмкин. Ләкин «сине яратам, синсез тора алмыйм, син – бердәнберем», дип, нинди генә вәгъдәләр бирсә дә, икенче хатын берничек тә беренчесенең урынын яулый алмаячак, ул фәкать икенче генә булачак. Аның кебек икенче хатыннар бу ирнең тормышында, бәлки, берничә дә булыр. Ләкин икенчесе булмаса, аның тормышында өченче хатын-кыз да булмаячак.

Өченчесе өчен ир кеше, гадәттә, җанын ярып бирергә, кирәксә, утка-суга сикерергә, дөньяларның астын өскә әйләндерергә әзер. Кайчак исә барлыгын да белми яшәргә мөмкин. Яратса, ул аны иң саф, иң садә хисләр белән яратачак, бар җиһаннан көнләшәчәк. Аның янында узган гомер аңа бер мизгел генә булып тоелачак. Ул аны башкаларга биреп җибәрсә дә, гомере буе көтеп яшәячәк.

Һәрбер ир-атның да диярлек шундый өч хатын-кызы бар. Аларның беренчесе – газиз әнисе, икенчесе – сөекле хатыны, ә өченчесе – яраткан кызы.

* * *

■ Яхшы ир – чукрак, ә яхшы хатын сукыр булырга тиеш.

Француз халык мәкале.

■ Яхшы ир кичтән беренче булып йокларга ятмас, иртән иң соңгысы булып уянмас.

Оноре де Бальзак (1799–1850 елларда яшәгән француз язучысы).

■ Мәхәббәт турында оста сөйләүче ир чын-чынлап яратмый.

Жорж Санд (1804–1876 елларда яшәгән француз язучысы, хатын-кыз).

■ Һәрбер ирдә уйнарга яраткан бала яши.

Фридрих Ницше (1844–1900 елларда яшәгән немец философы, шагыйрь).

■ Ир-атны кешеләрнең алар турында ни уйлавы, ә хатын-кызны – ни сөйләүләре борчый.

Теодор Гиппель (1741–1796 елларда яшәгән немец язучысы).

■ Хатын-кызның вак-төяк кимчелекләрен кичерә белмәүчеләр аларның яхшы якларын да күрә алмаячак.

Хәлил Джебран (1883–1931 елларда яшәгән ливан язучысы, рәссам).

зирәк кешедән зирәк сүз

Фото: www.pixabay.com







УЛ БИТ ҮЗЕ «САРЫ ИЛГИЗӘР»

Руслан Ахунов картиналары турында Достоевскийның мәгълүм гыйбарәсен бераз үзгәртеп, «алар барысы да Малевичның «Черный квадрат»ыннан чыккан», дип әйтер идем. Әнә карагыз: җете төсләрдән күзләр камаша...

– Мин төсләрнең күп, ачык, җете булуын яратам. Төсләр гармониясен... Гәрчә беренче эшем – «Сары илгизәр» (1995) графика техникасында язылган, монохром. Күргәзмәләрдә дә нәкъ менә шул зур булмаган, тыйнак кына картинам игътибарны күбрәк җәлеп итә. Күрәсең, әлегә аның энергетикасы кешеләргә күбрәк килешәдер. Әмма мин кабатлану яклы түгел. Минем өчен иң мөһиме: энергетика!

Россия һәм Башкортстан рәссамнарының иҗади берлеге әгъзасы, «Башкортстанның яраткан рәссамнары» бәйгесе лауреаты Руслан Ахунов белеме буенча – нефтьче, һөнәре буенча – җитештерүче, күңеле белән – иҗат кешесе. Мәктәптә, институтта шаржлар белән генә мавыккан җиреннән, еллар узгач, сукмагы Уфаның иң абруйлы рәссамы Борис Домашников остаханәсенә килеп чыга. «Киндер, майлы буяу» техникасыннан кала, бу ике рәссам арасында уртаклыклар юк кебек...

– Бар. Әлеге вакытта мин Борис Федоровичның фатирында яшим, аннан калган палитраны кулланам, – дип, шаяру катыш өсти Руслан Ирек улы. Чынбарлыгы да шул: кайчандыр Домашниковның остаханәсенә өйрәнчек буларак кына килеп йөргән Руслан, карт рәссам вафат булгач, аның фатирын сатып ала. Бу вакытта әле рәсем сәнгате аның өчен – хобби, төп эше – бетон җитештерү заводы. Остаханә дә дачага күчкән чак.

Рәсем сәнгате аны дистә елдан соң гына «үзенеке» итә. Күргәзмәләр, иҗади берлекләр, бәйгеләр, фестивальләр соңрак башлана. Остаханә янә фатирга кайта: хатыны Зәлиянең «кышкы бакчасы» урынына... Һәм гитара, авыз гармуны, чаранга белән янәшә яши башлый. Әйе, Руслан Ахунов бер үк вакытта музыкант та. Музыкант буларак кантри, блюз стилен ярата.

Рәссам буларак, кемдер аның картиналарында абстракционизм күрә, кемдер сюрреализм, дип билгели. Обывательләрчә фикер йөрткәндә, абстракционист рәссам предмет сурәтләми, формалардан кача, чынбарлык объектларыннан баш тарта. Сюрреалист исә чынбарлыкны бозып чагылдыра, тормыштагы объектларны парадоксаль рәвештә янәшә урнаштыра, төштәге кебек тәэсир калдыра.

Һәрхәлдә, XX йөзгә кадәр барлыкка килгән әлеге юнәлешләрнең безнең гасырга шактый трансформацияләр кичереп килеп җитүе дә гаҗәп түгел. Хәзерге заман сәнгать күргәзмәләреннән: «Мин дә болай булдыра алам», – дип кайткан кешеләрне күргән бар. Руслан Ахунов эшләренә карап, алай дип әйтү мөмкин түгел. Шәхсән миннән булмавын төгәл беләм. Шуңа да бу картиналар янында туктыйм да әллә кайда – аң төпкелендә чәчелеп яткан уйларымны тәртипкә сала башлыйм. Бу тәртипкә салу – Ахунов иҗатының үзенчәлеге. Рәссам үзе моны «энергетика» һәм «прет или не прет» дигән сүзләр белән бәяли. «Прет» бит?

Ландыш ӘБҮДӘРОВА





РУСЛАН АХУНОВ



Фон.
Тышкы дөнья.
Дивардагы җете тап.
Карта.







«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ **П2204**

Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар **73002**

1 февральдән 31 мартка кадәр
2019 елның икенче яртыеллыгы өчен газета-журналларга алдан язылу башланды.
Республикабызның барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин



Сайтта: www.syuyumbike.ru
ВКонтактеда: vk.com/suumbike
Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда :
http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып)
язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала. Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+

РЕКЛАМА